

Заһид МӘХМҮДИ



# ӘЧЕ БАЛАН

*Кыйссалар, хикәяләр, фәлсәфи уйланулар*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2003

УДК 820/89(470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-4
М12

**Мәхмүди Заһид**

Ì 1 2 Әче балан: Кыйссалар, хикәяләр, фәлсәфи уйланулар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. — 206 бит.

Җыентыкка кергән кыйссалар, хыялый хикәяләр, фәлсәфи уйланулар һәм үзенчәлекле шигырьләр тормышның үзенә, андагы вакыйгаларга нигезләнеп язылган. Аларда безнең бүгенге көнебез, кеше һәм җәмгыять арасындагы мөнәсәбәтләр, һәркайсыбызны нык борчыган наркомания, хөсетлек, икейөзлелек кебек проблемалар сурәтләнә.

ISBN 5-298-01312-0
© Татарстан китап нәшрияты, 2003

*Бу китабымны унтугыз яшендә наркоман кулыннан һәлак булган Миңнегалиева Альбина Равил кызының якты истәлегенә багышлыйм*

# БЕР УРАМНЫҢ ИКЕ ОЧЫ

Әле генә «өметле каләм» дип йөртелгән егетләрнең дә, кырыкны түгәрәкләп, гомер тавыннан түбән төшеп барышлары икән. Бу ноктадан дөнья башкачарак күренә. Тау итәгендәге зәңгәрсу томан әле генә кайнап торган уйларны уйчанландыра, офык кыршавы да янәшәдән, хәтта синең йөрәгең аша үтә сыман.

Узган гасыр башында кырыктан узган каләм әһелләрен «карт язучы» дип атаганнар. Без әле, шөкер, һаман яшьләр рәтендә. Чөнки безне карт язучы дип атарлык артта бүтән яшьләр юк…

Шигърият яшьлекне яратса, чәчмә жанрда исә, минемчә, утызкырык яшьтә язучы өлгереп кенә җитә әле. Үз яшьтәшләремнең иҗат юлларына күз ташлагач, мин бу фикергә янә ышандым. Дөрес, М.Шолохов егерме яшендә үк «Тын Дон»ның беренче китабын язган, диләр. Ләкин ул дөнья әдәбиятында да бердәнбер феномен булса кирәк. Шуңа аның авторлыгын шик астына алучылар да булды.

Заһид Мәхмүди иҗатын мин күптәннән күзәтеп киләм. Хәер, күзәтергә мәҗбүрмен дә — аның барлык әсәрләре дә диярлек мин эшли торган «Идел» журналында дөнья күрде. Ул беренче адымнарыннан ук үзенең сәерлеге, импрессионистик алымнары белән игътибарны җәлеп итте. Заһид, гомумән, безнең яшьтәшләр арасында аерылып тора. Югыйсә сиксәненче елларда әдәбиятка килгән егетләр арасында үз юлыңны, кояш астындагы үз урыныңны табуы җиңел түгел. В.Имамов, Ф.Яхин, З.Хәким, Г.Гыйльманов, Ф.Әмәк, З.Хөснияр, Р.Сәгъди… Мин монда беренче роман-кыйссаларын укучы хөкеменә тапшырган буындашларны санадым. Болар турында безнең тәнкыйтьтә иркенләп сөйләшү булмады әле. Хәер, кемнәрнеңдер бәя бирүен көтеп тә тормаска кирәктер…

Әлбәттә, әсәрләрнең кимәле төрлечә. Әмма шундый исемнәрнең булуы күңелдә әдәбиятыбызның киләчәгенә карата күпмедер өмет тә уята.

Заһид үзенең «Тәмуг чәчәге» бәяны белән әдәбиятта исемен белдерде булса кирәк. Үз фантасмагориясе, гайре табигый хәлләрне Латин Америкасы язучылары сыман әсәрнең тукымасына сеңдерә белүе аны бүтәннәрдән үзгә бер яссылыкка куя иде.

Заһид пакусны киң алырга ярата. Аның бер үк әсәрендә әллә ничә агым берләшеп-буталып, ниндидер шарлавык хасил итәргә мөмкин. Тормышта да без шундый түгелме соң? Бигрәк тә экспрессив, хисчән кешеләр… Ярсыйсың, үз җаныңны талыйсың, дөньясыннан, хәтта үз якыннарыңнан да каһкаһәләп көлеп аласың, аннары күңел талчыгып үз ярларына кайта, мыштым гына йөрәкне сызлатып кыенсыну килә… Уйчанланасың, кайчакта төшенкелеккә биреләсең…

Сирәк кенә Заһид безнең редакциядә күренә. Ул тиз йөри: кайдадыр коридорның теге очында аяк тавышы ишетелеп кенә ала да, менә инде ул ишекне киереп ачып, синең бүлмәңә дә килеп керә. Күрүгә үк кесәсеннән үтеңне сытарлык тәмәкесен алып ирененә ябыштыра.

Аннары сөйли башлый... «Яңа кыйсса язам бит әле», — дип әсәрен тәфсилли. Әллә инде язган, әллә язарга җыена. Ул сөйләгән өзекләрне кайчагында, чыннан да, сүзен-сүзгә әсәрдә очратасың... Язасы әсәрен шулай сөйләп йөреп шомарта, ахрысы.

Аның миен дә һәр язучыны борчыган сораулар бимазалый: «Мин төннәр буе язам. Ни өчен? Мин-минлек чире инде. Бөек әсәр иҗат итәм, дөньяны шаккатырам, имеш. Үлгәч, синең исемеңне телгә алсалар да, алмасалар да барыбер түгелмени? И Ходаем, бер хикмәт бар бу адәм баласында. Нигә ул тиздән туфрак буласын белә торып, маңгай тирен түгә, тырмаша. Теге дөньяда яшәргә әзерләнүеме аның бу?! Без кемгә кирәк? Нәрсә кирәк? Нәрсә өчен? Бәлки, Илаһи Атабызның җиде көнлек хезмәтенә бәя бирү өчен кирәктер без? Ул бит һәрьяктан камил. Ә камил нәрсә мактауга, бәя биреп торуга мохтаҗ түгел. Бәлки, Ул юктыр? Канда тагын Иблис уяна...»

Язучының бөтен иҗаты шул үз эчендәге Иблис белән көрәш түгелмени?

Яшәү мәгънәсе... Үлем... Мәңгелек... Шушы бөек фәлсәфи төшенчәләр Заһидка да тынгылык бирми. Ул шушы бәргәләнүен әсәр каһарманнарына да күчерә. Аның бомжы да хәтта кайчагында Шопенгауэр сыман яшәешнең мәгънәсезлеге хакында фәлсәфи фикерләр әйтеп ташларга мөмкин.

Туксанынчы елларда милли үзаңның татар миендә дә кымшанып куюы нәтиҗәсендә тарихыбызга карата да игътибар арткан иде. «Идел» журналы берничә ел рәттән тарихи хикәяләр бәйгесе дә игълан итте. Шул бәйгедә катнашырга Заһид та әсәренеп алды. Гадәтенчә, бүлмәгә кереп, тарихи фантазияләрен бездә дә сынап карады. Мәрхүм Фәиз Зөлкарнәйгә аның тел чарлавы ошады. «Син моны зуррак әсәр итеп яз», — дип котыртты ул Заһидны. Күп тә үтмәде, Мәхмүди, үзенә хас өлгерлек белән, «Калканлы Идел» дигән бәянын күтәреп тә килде. Фәиз, аны тиз генә укып чыкты да, хаталарын төзәткәләп, янәдән эшләргә бирде. Тик төзәтелгән вариантын гына укырга өлгерми калды.

Заһидның тарихи әсәре дә үзенчә язылган. Заһидча! Бәянны Заһид нәкъ үзенчә тәмамлый. Мәлгунь планетасы хакиме Уммер Утыз Икенче 200000115 елда, Кызыл елан аеның 63 нче көнендә галәмгә телеграмма юллый: «Казан кальгасын саклап һәлак булган әрвахларның күкнең җиденче катына күтәрелү юлында провокацияләр белән шөгыльләнмәскә. Кичекмәстән иманга килегез. Кылган гөнаһларыбыз өчен Аллаһы безне ярлыкый күрсен!»

Вәт! Тик хәбәр В-2 дулкынында тапшырылган шул. Гади кешенең колагы аңа көйләнмәгән. Мондый дулкыннарны Заһид Мәхмүди генә ишетә ала.

Нинди генә гомумиләштерү көченә ия булмасын, нинди генә фантасмагорик алымнардан файдаланмасын, язучы әсәргә үзе күргәннәрне, үзе кичергәннәрне күчерә. Заһид урыс армиясенең бөтен ачысын-төчесен татыган кеше, шуңа аның «Сары каеш — сары

сагыш» бәяның укыгач, чын-чынлап тетрәнәсең… Ялангач хакыйкать шулай тетрәндерә. Бу әсәрне хәтта автобиографик бәян дип атасаң да дөрес булыр иде.

Заһид Мәхмүдинең әсәрләре бер тын белән укыла. Бер тын белән язылганга күрәме икән әллә? Аның әсәрләре ялыктыргыч түгел, Заһид Америка киночылары яраткан «экшн»ны, бөтен хасиятен белеп, әдәби әсәрдә куллана. Ләкин аның каһарманнары кызык эзләп китап актаручы укучы кәефе өчен марионеткалар сыман хәрәкәткә килмиләр. Алар — тере кешеләр. Тирә-ягыбызга игътибар беләнрәк күз салсак, без аларны бик тиз танып алырбыз.

«Әче балан», «Чокыр да такыр» кыйссаларында автор бүгенге куркыныч чынбарлыгыбызны сурәтли. Наркомания тозагына эләгеп кешелеген җуйган, соңыннан этисенең гомерен өзгән Альбертлар, комсызлык, җенси тотнаксызлык аркасында җинаять эшләүдән дә тартынмаган Филатовлар безнең арада яши түгелме соң? Күпме язмышларны сындырган Рәсәй чынбарлыгы… Моны Заһид яхшы белә. Чөнки ул үзе Ерганак урамында яши… Шушы тормыш пычрагыннан сакланыр өчен иман китергән, беренче тапкыр изге Коръәнне кулына алган шагыйрь Илфак — автор үзе түгелмени? Тик ул әсәр ахырында сәер генә юкка чыга… Ә урам үзенчә яши бирә. Әнә Чечняда бердәнбер улын җуйган ананың акылдан язуын Заһид нинди коточкыч куәт белән сурәтли… Рафис белән Айсылуның аянычлы да, якты да мәхәббәтләренең шәүләсе, бәлки, бу урамны яктырта алыр? Ләкин… «Акрынлап урамга төн пәрдәсе төште… Бетон баганаларга эленгән люминесцент лампалар тирәсендә бөтерелеп карлар оча, тимерчыбыклар гүелди. Салкынайтып җибәргәнгә шулай итә. Кайбер йортларда ут юк, Айвазовский урамында автокран баганадагы чыбыкны өздергән. Бер урам булса да, монда электр уты ике якка ике җирдән килә».

Ерганак урамында яшәүчеләрнең язмышы аша З.Мәхмүди безнең җәмгыятьнең бөтен эчен актарып ташлаган. Бу урамның инде киләчәге юк, анда яшәүчеләрне шәһәр читенә күчерәләр, иске агач йортларын ут төртеп яндыралар. Китәргә теләмәүчеләр әҗәлләрен дә шунда таба. Без хәтерләгән иске Казанны тарих чүплегенә түгәләр. Зур ташпулатларның җиңүле ябырылуы дәвам итә. Безгә шуны битараф рәвештә күзәтергә генә кала.

Яңа гына ишеттем — Заһидка да шәһәр читеннән фатир биргәннәр икән. Әле аңа таш диварлар артына поскан җаннарның да язмышын сурәтләргә насыйп булыр. Ә бүген ул Ерганак урамы белән, шунда үткән яшьлеге белән хушлаша. Тиздән аның бакчалы, мунчалы иске агач йортын бульдозерлар килеп туздырып ташлар.

Тик ул урам бөтенләйгә юкка чыкмас… Мәхмүди әсәрләрендә без аңа әледән-әле тап булырбыз.

Һичшиксез.

Чөнки һәр урамның ике очы бар…

*Ркаил Зәйдулла*



# ӘЧЕ БАЛАН

## Аучылар аптыраштa

Таң беленеп килә иде. Урман авызына чабып килеп кергән ана бүре утрау-утрау булып үсеп утырган абагалар арасына сеңде. Аның артыннан ук бөтен киек-җанварны уятып, мылтыклы өч адәм заты төялгән бишекле мотоцикл күренде. Алар мотоциклдан да төшеп тормыйча, сүгенә-сүгенә һәр тарафка утлы ядрә яудыра башладылар. Әле монда, әле тегендә чәрдәкләнгән нарат ботаклары сыгылып төшә, өлгерә башлаган күркәләр шабыр-шобыр җиргә коела.

Мылтык тавышыннан бүренең тыны кысылды, колаклары тонды. Инде чыдар әмәле калмыйча сикереп торам дигәндә, якындагы чикләвек куагы астыннан кечкенә генә шәүлә сикереп чыкты да, чыелдап, аның сыртына ауды. «Син каян килеп чыктың әле, имгәк!» — дип уйлады ул гасабиланып. Аннары, тынынны да чыгарасы булма дигәндәй, ырылдап куйды. Алгы тәпиеннән чыжылдап кан аккан мәхлук бүредән курыкмады, киресенчә, аннан яклау сорагандай, тагын да якынрак елышты. Бу ана бүрегә бик сәер тоелды. Аучылар киткәч тотып ашар дип тә курыкмый. Бүренең яраланган хайванга тимәгәнен яхшы белә, димәк. Бу — алар өчен язылмаган канун. Үзен хөрмәт иткән бүре үлем хәлендә яткан корбанын һәрвакыт әйләнеп узар. Ул каты колакның канлы тәпиен яларга керешге. Хәлсезләнә бара, бичара, озак яшәмәс.

Дуамалланып аргач, аучылар, тәмәке кабызып, бытыр-бытыр сөйләшә башлады:

— Качты, мәлгунь!

— Ата бүрене бик җиңел эләктергәннәр иде, ә бусы хәйләкәр. Адәм акыллары бар үзендә. Дүрт сарыкны буды бит.

— Менә замана, бүре үрчесә, илгә афәт килә, дигән борынгылар.

— Күптән килде инде безгә ул афәт, Горбачевың, Ельцинның белән бергә килде.

— Хак сүз әйтәсең, агайне. Хәзер көн туды исә — фаҗига. Бер тарафта конституцион тәртип урнаштырабыз дип чечен халкын кыралар, икенче тарафта балалар утырган самолет җиргә кадала. Тәртип бетте илдә.

— Теге Останкино манарасын әйтәм, көпә-көндез Мәскәү уртасында янып бетте бит! Инде Кремльгә генә ут төртәселәре калды.

— Янса янсын, ачуым килмәгәе. Ул манараның януына минем бер дә исем китми. Гөнаһлы сүз булса да әйтим, агайнеләр, бераз сөенеп тә куйдым мин бу хәлгә. Бөтен кабих нәрсә менә шул манарадан килә инде. Балалар барында телевизор кабызып булмый хәзер, тәмам шайтан тартмасына әверелде.

— Ә минем күптән телевизор караганым юк. Теге реклама дигәннәре белән канны эчтеләр-эчтеләр дә беркөнне, чыгырымнан чыгып, тәрәзәдән үк томырдым. Көчләү бит бу, җәмәгать, турыдан-туры көчләү. Затлы телевизор иде, анасын. Акчасы жәл. Күпме ит әрәм булды. Аны сатып алыр өчен ике бозау суйган идем бит мин. Хатын тәмам канны эчте, ваткансың икән, яңасын сатып ал, ди.

— Балаларыбызны үзебез саклап кала алмасак, дәүләт аларны берничек тә саклап кала алмас. Хәзер аның бөтен белгәне адәм баласын төрмәгә утыртудан гына гыйбарәт. Заманы шундый, ул үзе юлдан яздыру белән шөгыльләнә хәзер. Аңа ятимнәр дә, гариләр дә, яхшы балалар да, начар балалар да, сугыш ветераннары да, хезмәт ветераннары да кирәк түгел. Халык үзенчә, ул үзенчә яши, вәт!

— Әйтмә дә инде, тормышыбыз буталчык, киләчәгебез буталчык, аңнарыбыз да тәмам буталып бетте. Кемгә ышанырга белмәссең. Соң, ул телепрограммаларны шул ук ата-аналар оештырмыймыни?

— Аларның балалары безнекеләр кебек телевизор янында акаеп утырмый, Америкада белем ала.

— Әй монафикъ дөнья!

— Сызды безнең ана бүре, — диде аучыларның берсе, сүзне икенчегә борып. — Кайтыйк булмаса, егетләр. Тиздән яп-якты булачак. Телсез Василийны уятыйк та тагын килик. Ул бер генә бүренең башына җитмәде инде. Рексны да үзе белән алса...

— Бик дөрес. Иртән бүренең өнен табуы җиңелрәк. Бүре чыклы үлән өстендә эз калдыра.

Аучылар фара яктысында якын-тирәдәге куаклыкларны тагын бер кат айкап чыктылар да үз тарафларына юл тоттылар.

Мотоцикл тавышы тынгач, бүре шыңшып куйды. Ботын ядрә сыздырып узган икән. «Явызланды адәм баласы, — дип уйлады ул. — Бу кабих зат урмандагы киекне кырып бетермәгән булса,

без шундый ач булыр идекмени? Безнең дә ашыйсыбыз, җирдә үз дәвамыбызны калдырасыбыз килә. Без бу фани дөньяга бүре булып килүебез белән бәхетсез, ә ул адәм булып килүе белән. Үз койрыгын тешләп өзгән елан ул. Күпме афәт алып килде җиргә! Урам этләре авыл башындагы чүплектә актарынып йөри — кыяфәтләренә карап торырга куркыныч. Кайсында тимрәү, кайсы борчалы, кабыргалары гына күренеп тора. Алар шундый мескен язмышка лаекмыни? Эт токымы гомер бакый адәм баласына тугрылыклы хезмәт итте. Ә ул, кирәге калмагач, аны урамга чыгарып ыргытты. Адәм баласы хәзер үзе дә чүплектә казына. Тук заман булса да, ачлар заманы җитте. Ә бүреләр кешегә беркайчан да ышанмады да, хезмәт тә итмәде. Ул бүген дә бүре, ул үзенең бүрелегенә хыянәт итмәде».

Җан бирә башлаган каты колакның тәне тартыша башлады. Бик яшь иде әле ул. Җәйнең рәхәтен күрә алмады, бичара. Аны бераз күзәтеп утыргач, бүре таныш сукмак исен алып, аксаклыйаксаклый, үз өненә юл тотты.

Күк йөзе инде шактый яктырды. Бүрекәйләр дүрт күзләп көтә булыр. Ау барып чыкмады, үзе дә ач ана бүре. Имчәкләрендә азмы-күпме сөт бар әле, кичкә кадәр чыдарлар. Бүре түземле булырга тиеш. Бүген төнлә ул яңадан ауга чыгачак. Аучылар озак көттермәс, тагын эзләп чыгулары ихтимал. Шуңа күрә өнне алыштырып өлгерергә кирәк. Араларында теге телсез адәм дә булса, эшләр харап. Бик күп бүренең башына җитте ул. Ата бүрене дә ул үтерде. Тиресен бакча башына — колгага элеп куйды, хаин. Ана бүре бүген аның бөтен сарыкларын буып чыгарга тиеш. Эте дә бик гаярь телсезнең, бүре исен бер чакрымнан сизеп ала.

Алдагы төндә ана бүре төш күргән иде. Имеш, ата бүрене чебеннәр сарып алган. Чебеннәр, адәмчә сүгенә-сүгенә, аның күзләрен чокыйлар. Ата бүре бәргәләнә, чәбәләнә, ана бүрене ярдәмгә чакыра. Ярдәм итә алмады, әллә каян болыт булып кара козгыннар очып килделәр дә ата бүренең эчен актарып ташладылар. Менә шуңа күрә дә ул бүген телсезгә генә түгел, бертуктаусыз тешләшкән кигәвеннәрдән алып, агач башларында сайраган кошларга да ачулы һәм нәфрәтле иде.

Шактый озак барды ана бүре. Тирән ерганакка якынлашкач, иснәнә-иснәнә, тирә-юньгә күз салды. Абай булу зыян итмәс. Бер елны адәм затлары аларны өннәре янында саклап торганнар. Көчкә качып котылдылар. Тик әле яңа гына йөрергә өйрәнә башлаган дүрт балалары харап булды. Ана бүре аксап калды, ядрә аның алгы тәпиен чәрдәкләгән иде. Соңрак яшь бүреләрне эзләп килделәр алар. Барысын да пычак белән суеп киткәннәр иде. Менә шуңа үч итеп, алар ата бүре белән колхоз фермаларындагы һәм шәхси хуҗалыклардагы сарыкларга һөҗүм итә башладылар.

Якында гына шикле җан әсәре күренми. Яр буенда үсеп утырган артыш куагы яныннан мыштым гына керпе узып бара. Аны

болай гына тешләп булмас, кечкенә генә булса да, батыр хайван. Куркыныч килсә, туп кебек йомарлана да, мыш-мыш килеп, борынга энә белән төртә башлый. Ерганак астында чишмә суы ага, шунда төртеп төшерсәң, ул шундук биреләчәк. Бер генә керпене суга тәгәрәтмәде инде ана бүре. Аркасы суга тиюгә үк корсагы белән әйләнеп ята, ахмак. Ашардай әллә ние юк инде, итенә караганда мәшәкате күбрәк була. Алай да буш кул белән кайту түгел.

## Бала күңеле далада

Кунак бүлмәсендәге стена сәгате иртәнге икене сукса да, Баязит йокыга китә алмады. Юкса авылдан бик арып кайткан иде. Анда аның сиксән яшьлек карт әнисе яши. Атна буе печән чапты, түбәдәге шиферны алыштырды. Картайгач, йокы кача икән ул. Кайвакыт бер төндә әллә ниләр уйлап бетерәсең. Пенсиягә чыккач, Әлфиясе белән авылда яшәргә хыяллана иде Баязит. Тик бу хыял инде беркайчан да тормышка ашмаячак. Җиде-сигез ай элек Әлфиянең күкрәгеннән яман шеш таптылар. Иртәрәк килгән булса, котыласы булган икән. Ә хәзер вакыты узган. Нинди генә табибларга мөрәҗәгать итмәделәр, ләкин кайда да хөкем карары бер: «Хатыныгыз өметсез, күп булса, ике-өч ай яшәр!» Кырык ел бергә гомер иткән хатыныңның тиздән үләсен белеп яшәү яман икән. Иң якын туганына караганда да кадерлерәк аның Әлфиясе. Икәүләп тыныч картлык турында хыялландылар бит, һәм менә сиңа! Уллары Альбертны күпме акча түгеп медицина институтына урнаштырдылар. Ике генә ел йөреп калган «Жигули»ен да, буяу цехын да сатарга мәҗбүр булды Баязит. Ләкин малай укымады, урамда җил куып йөрде. Икешәр-өчәр көн кайтмый. Бүген дә күренми. Язын армиягә китәргә тиеш иде Альберт. Ләкин Әлфиясе, малаеңны Чечняга җибәрүләрен телисең мәллә, дип теңкәгә тигәч, Баязит, хәрби комиссариатка барып, таныш-белешләре аркылы Альберт өчен отсрочка алды. Хәзер Әлфия үзе дә үкенә. Болай йөрсә, малайлары, һичшиксез, төрмә белән бетерәчәк. Унунбиш көн элек берәү исемен әйтмичә генә: «Улыгыз төнге клубларда бутала, наркотиклар сата, сутенерлык белән шөгыльләнә», — дип шылтыраткач, Баязит ышанмаган иде. Өйдән Әлфиянең алтын балдаклары юкка чыга башлагач кына, шиге калмады. Сөйләшеп тә караган иде, ыжылдап каршы әйтә башлый: «Не учи, я уже совершеннолетний!» — дип, авызны гына каплап куя. Кыскасы, эт токымыннан булды бу малай. Әлфия үлеп котылыр, ә Баязитка нәрсә эшләргә?

Ничек шулай килеп чыкты соң әле? Альберт менә-менә үсеп җитәм дигәндә генә, бер-бер артлы командировкалар башланды. Торгынлык елларында ул экологик яктан чиста буяу уйлап тапкан иде. Шуның өстенә җил дә, яңгыр да, кояш та алмый үзен. Бер

буядың исә, йөз ел тора. Инде егерме еллап вакыт узды, Кәчемир авылында ул буяган мәчет манарасы бүген дә әллә каян кычкырып тора. Илдә яңа җилләр исеп киткәч, буяугa патент алырга теләде, юл куймадылар. Исең китәр, үз ачышын Кытайга кадәр барып сатты. Алдылар бит, акчасын да шәп түләделәр. Озакламый безнекеләр бу буяуны Кытайдан сатып алачак. Буяуның даны еракларга таралды, Татарстанда гына түгел, аннан читтә яшәүче татарлар да сорап килә башлады. Шуңа күрә Баязит буяу җитештерә торган махсус цех ачты. Буяуны ул мәчетләр өчен генә җитештерде, аларны да үзе генә буяды. Туган авылындагы яңа мәчет манарасын да буярга уйлаган иде, тормышлар кыек китте. Эш белән мавыкты шул, кирәгеннән артык мавыкты. Ә бала, акчага тилмермәсә дә, әтисез үсте. Хәзерге акылы булса, аны бер генә минутка да ташламас иде. Казанда гына түгел, район үзәкләрендә дә унике-унөч яшьлек балалар сыра эчә башлаган заман бу. Аракы белән тәмәкесе дә шунда. Тумас борын тәмәке тарталар, тумас борын аракы чөмерәләр хәзер яшьләр. Чак кына күздән ычкындырдыңмы, балаңны югалттым дип уйла. Казандагы мәктәпләрнең берсендә әнә өченче класс баласы дәрескә исереп кергән. Балалар дәрес барганда да кәрт сугып утыралар. Имеш-мимеш түгел, чынбарлык бу. Балаңны урамга чыгарырга куркып торган кара чынбарлык. Җинаятьчел төркемнәрдән котылса, наркоман итәләр, наркоманнардан котылса, үтереп китәләр. Күрше Әхәт зарланып торды, балаңны урамга чыгарып җибәргәндә сугышка озаткандай буласың, ди, ул кайтып җиткәнче, йә инфаркт аласың, йә бөтенләй аягыңны сузасың, ди. Үзгәрде ил. Ичмаса, демократик җәмгыять төзибез дип мактанмасыннар иде. Өч яшь кешенең берсе наркоман булган дәүләтнең нинди киләчәге булсын! Мондый җитәкчеләрне тотып атарга кирәк. Хәер, халкы нинди, җитәкчесе дә шундый. Лаек без үзебезнең җитәкчеләргә.

— Атасы... Атасы дим! — Әлфия тавышы. Ыңгыраша, бәгырь.

— Әү, җаным?

— Укол кирәк... Үләрмен инде мин.

«И бәгърем, әле кайчан гына нинди матур идең бит син! — дип уйлады Баязит, хатыны янына чүгәләп. — Менә нишләтә яман шеш, тәмам бетерендең, әбигә әвереледең».

Аның сабый кебек кычкырып елыйсы килә башлады, ләкин... елый алмады. Бәгырь таш булып катты дигәннәре шул буладыр инде. Тонык кына янган торшер яктысында хатынының йөзендә улы чалымнарын күргәч, анда хәтта ачу һәм үпкә хисе кузгалды. Балага бер сүз дә әйтергә ярамады шул. Кычкыра башласа, Әлфия аннан да уздырып кычкырды, каешка алынса, ата белән бала арасындагы низаг ана белән ата арасындагы низагка әверелде. Альбертны татар мәктәбенә бирәм дигәч тә каршы килде. Имеш, урысча укысын, татар теле белән беркая да барып булмый. Нәти-

җәдә, ата-анасын санга да сукмый торган маңкорт үсеп җитте. Иман дигәннәре сөт белән генә түгел, тел белән дә керә икән ул. Туган мохитеннән аерылган баладан бик сирәк кенә кеше чыга — менә шундый ачы хакыйкатьне аңлады Баязит. Кем әйткән әле, маңкорт үз милләтен теләсә нинди кан дошманга караганда да күбрәк күрә алмый дип?

Бервакыт Мәскәүдән поезд белән кайтып килгәндә, шундый маңкорт белән сөйләшеп барган иде Баязит. Әңгәмәдәш шактый олы яшьләрдә, Воркута якларында шахтада эшләгән. Роберт исемле иде бугай. Бер кәлимә татарча сүз белми. Сораша, Татарстанда тормыш ничек тә татарлар нигә мөстәкыйльлеккә омтыла? Аңлата алган кадәресен аңлатты Баязит, ләкин ул һич кенә дә аңларга теләмәде. Русиядән башка сез ачтан үләсез бит, ди. Белми ул Татарстанда күпчелек урыс авыллары булган җирдә алабута үскәнен. Хәзер авыл хуҗалыгында туксан тугыз процент татарлар эшли ләбаса.

Гәпләшә торгач, маңкорт кинәт сорап куйды:

— Карале, Волга аша күпер салганнар дип ишеткән идем, дөресме бу?

— Бар андый күпер.

— Волга дигәннән, сез дә аны Волга дип атыйсыздыр инде?

— Юк, без аны Идел дибез.

— Булмас, ниткән исем бу тагын? Волга элек-электән урыс елгасы булган. Аның татарча атамасы юк. Шыттырасың, брат!

— Бар, абзый, аның татарча атамасы, бар! — диде Баязит, аның наданлыгына шаккатып. — Ә Волга дигән атаманың каян килеп чыкканын беләсеңме соң син?

— Белмим.

— Елга дигән сүздән килеп чыккан ул. Шулай булгач, Волганы урыс атамасы, урыс елгасы дип әйтеп буламы?

Үпкәләде маңкорт. Мыгырдый-мыгырдый, тамбурга тәмәке тартырга чыгып китте.

— Националист! — Соңгы сүзе шундый булды аның.

Баязит укол кадагач, Әлфиягә бераз җиңел булып китте. Хәер, әфьюн тудырган ялган халәт бу.

— Нигә йокламыйсың, картым?

— Авылда бүреләр барлыкка килгән, шуны уйлап ятам, — дип алдашты Баязит. — Телсез Василий бишесен аткан инде. Берсен һаман да тота алмыйлар. Ана бүре булырга тиеш, дип сөйләшәләр. Фермада ике сарыкны буып салган.

— Бүре — куркыныч хайван.

— Дүрт аяклы бүредән курыкма син, хатын. Илдә ике аяклы бүреләр дә ишәйгәннән-ишәя бара. Көн дә үтереш, көн дә талау. Гәзиттән укыган идем, Идел судан бер хатынның туракланган гәүдәсен тапканнар. Малае үтергән, наркоман булган, ди.

Баязит, шундук улын искә төшереп, тынып калды. Тагын боза бит Әлфиянең йөрәген.

Хатыны янә ыңгырашып куйды:

— И замана-а!.. Альберт кайтмадымы?

— Кайтмады шул, анасы, кайтмады-ы, — дип көрсенде Баязит, иңнәрен сикертеп. — Алып узды тәки.

Әлфиянең күзләреннән яшь тәгәрәде.

— Ана күңеле балада, бала күңеле далада... — дип уфтанды ул. — Балда-майда гына йөзде шул... Бала дигәннәрен табасы гына түгел икән.

— Тынычлан, әнисе, — диде ир, аның башын сыйпап. — Улыбыз балигъ яшьтә, үз юлын үзе карасын инде.

— Әйтүе генә җиңел. — Әлфиянең тавышы калтырап куйды. — Мин хәзер күбрәк синең өчен борчылам, атасы. Беләм мин Альбертның нинди юлда йөргәнен.

Баязит имәнеп китте.

— Каян беләсең?

— Бүген иртән, син авылда вакытта, бакча күршесе Кадрия керде, ул сөйләде... Картым, бәлки, соң түгелдер? Әллә милициягә мөрәҗәгать итәсеңме?

— Исәп бар иде... Ләкин наркоманнан кеше ясап булмый, хатын. Андый кешенең ике генә юлы бар. Берсе — төрмә, икенчесе — кабер.

Әлфия үксеп-үксеп еларга тотынды.

— Шулай белә торып балабызны юк итәбезмени?

— Ярый, иртәгә наркология диспансерына барып сөйләшермен. Тик моның өчен аның үз теләге булу кирәк, анасы. Аның белән хәзер бөтенләй сөйләшеп булмый.

— Сөйләшергә тырыш инде, картым, сөйләшергә тырыш. Кайткач, үзем дә сөйләшеп карармын.

Авыр тынлык урнашты.

— Балабыз өчен дә куркам, синең өчен дә куркам, — диде Әлфия, янә телгә килеп. — Мин үлгәч...

— Юкны сөйләмә, Әлфия, Алла боерса, терелерсең. — Теле шулай дисә дә, Баязит аның тереләчәгенә инде ышанмый.

— Мин үлгәч, шәһәрдә калма, — дип дәвам итте Әлфия. — Фатирыбыз зур. Аны алыштыр да авылдан йорт сатып ал. Баланы ташлама. Өметсез шайтан гына була. Аннары сиңа тагын бер сүзем бар, картым. Тик, зинһар, үпкәләмә.

— Үпкәләмим, әйт сүзеңне.

— Мин үлгәч... Кадриягә өйлән.

— Нәрсә? — Баязит бу сүзләрне ишетергә һич тә әзер түгел иде. Аһ, бу хатын-кызны! Каян сизгән аның Кадрияне ошатканын? Ошатса да, аңа өйләнергә дигән уе юк иде.

— Син ни сөйлисең, хатын? Андый сүз буламыни?

— Була икән шул, картым, була. Кадрия әйбәт хатын, аның

белән югалмассың. Аннары ул балага да күз-колак булып торыр. Ә хәзер утны сүндер, әтисе, мин бик ардым.

Баязит, торшерны сүндереп, ашханә бүлмәсенә узды. «Прима» тәмәкесен кабызгач, ул тәрәзәгә караган хәлдә уйга чумды. «Кадрия... Чыннан да, уңган-булган хатын. Ирсез булса да, бакчасында бер дигән коттедж салдырды. Һәм нинди акчага диген? Хастаханәдә нянька гына булып эшли бит үзе. Юк, юк, Кадрия турында уйларга иртәрәк. Турысын гына әйткәндә, Әлфиягә карата намуссызлык, хыянәт бу!»

Шулай уйланып утырганда, ишектә кыңгырау яңгырады. Баязит, суыткыч өстендәге будильникка күз салып, кашын җыерды. Иртәнге сәгать өч. Альберт бу! Әнисе авырып ятканны да аңламый, мәртәт!

Ишекне ачуга, башына күн куртка кигән Альберт, чак кына әтисен төртеп екмыйча, ашханә бүлмәсенә атлады.

— Уф, умираю, ашыйсым килә! — диде ул, газ плитәсе өстендә торган кәстрүлнең капкачын ачып. — У-у, голубцы! Кем пешерде?

— Кадрия апаң ясап калдырган, пешерүен үзем пешердем.

Альберт әтисенә күтәрелеп тә карамыйча, кәбестә яфрагына төреп пешерелгән итле дөгене тәлинкәгә тутырды да өстәл артына килеп кунаклады. Күзләре — кып-кызыл. Димәк, тагын нидер җиффәрткән.

— Кайда булдың? — диде Баязит, гасабилануын сиздермәскә тырышып.

— Кайда булыйм инде, дискотекада, конечно.

— Төнге дискотекага йөрер өчен акча кирәк, ә син беркайда да эшләмисең. — Бу юлы Баязит инде тавышын күтәрә төште. — Туктатырга кирәк бу төнге йөрүләрне, юкса...

— Син нәрсә, мине юкка өстерәлеп йөри дип уйлыйсың мәллә? Малость подрабатываю инде.

Шул мәлне ишектә тагын кыңгырау яңгырады. Альберт сикереп торып ишеккә атлады.

— Ну, сколько можно тебя ждать, Альберт! — Хатын-кыз тавышы.

— Не ори, отец услышит! Сейчас выйду.

— Деньги достал?

— Откуда?

— Ты же обещал.

— Ух, черт тебя носит!

— Смотри, эти ребята не шутят.

— Знаю. Подожди еще чуть-чуть.

Төнге кунакны чыгарып җибәргәч, Альберт янә өстәл артына килеп утырды. Ашау онытылды.

— Әти, өч йөз тәңкә одолжи, пожалуйста, — диде ул, тәлинкәне читкә этеп.

— Аның кадәр акча миндә юк. Булса да бирмәс идем. Кем иде ул?

— Бер таныш хатын шунда, — дип мыгырдады Альберт. — Күрше подъездда тора, Светлана исемле. «Арена»да кассир булып эшли. Может, күргәнең дә бардыр әле... Өч йөз тәңкә... Бәлки, әнинеке бардыр, ә?

— Оятыңа көч килмәсме? Авыру әниеңә син үзең акча алып кайтырга тиеш.

— Да, хәлләр кәкәй... Кем уйлап тапкан бу акчаны, ә? Сиңа төкерек кенә бит инде ул. Иртәгә мин аны сиңа алты йөз тәңкә итеп кайтарып бирәм.

— Әфьюн сатыпмы?

— Нәрсә? — Альберт, күзләрен зур итеп ачып, әтисенә карады. — Син ни сөйлисең, әти?

— Күрсәт әле беләгеңне!

— Ә нигә мин аны сиңа күрсәтергә тиеш? Син нәрсә, мине чыннан да наркоман дип уйлыйсыңмы?

— Куркасыңмы? Нигә күрсәтмисең?

Альберт комач кебек кызарып чыкты.

— Ярый, бу турыда башка көнне сөйләшербез. Ә хәзер миңа өч йөз тәңкә акча кирәк.

— Сиңа дәваланырга кирәк, улым.

— Әкият сөйләмә әле! Миңа акча кирәк. Синең өчен төкерек кенә бит инде ул, әти.

— Элек төкерек кенә иде, ә хәзер минем өчен дә зур акча. Син миндә әндри казнасы бар дип белдеңме?! Сине укырга кертәм дип, мин буяу җитештерү цехын ябарга мәҗбүр булдым. Институтны ташлап, атаңның йөз кырык мең сумын суга салдың син! Хәзер мин эшсез, аңладыңмы?! Бар, анаңның хәлен белеп чык!

— Бирмисең, значит?! — диде Альберт, кызганнан-кыза барып.

— Иплерәк сөйләш! Мин сиңа иптәш малай түгел!

— Ә-ә, шулаймы? Алайса, мин киттем!

— Син беркая да китмисең!

Альберт, әтисен этеп-төртеп диярлек, ишеккә таба атлады.

— Не злись, озак тормыйм, тиз кайтам.

Үзгәрсә дә үзгәрә икән адәм баласы. Кара син бу тәрене! Әрәмтамак! Гәүдәләре лепердәп тора, эшлексезлектән икенче ияге үсә башлаган. Юк, бу инде элекке Альберт түгел.

Ишек шап итеп ябылгач, Баязит, идәнгә төкереп, үз бүлмәсенә кереп китте.

Йокы кермәде аңа. Ирексездән әллә ничек кенә үзенең яшьлек елларын искә төшерде.

**Әтидән баш тартырга?**

...Илле икенче елның июнь ахыры. Бер атнадан Свердловски шәһәренең медицина институтында диплом тапшырырга тиешләр.

Әмма ректор күрсәтмәсе буенча, бүген төштән соң унсигезенче группаны комсомол җыелышына җыйдылар. Юкка түгел инде бу, димәк, нидер булган. Чөнки менә-менә таралышабыз дип торган бер мәлдә, комсомол җыелышы оештыру барысына да гайре табигый хәл булып тоелды. Кемгәдер, ни өчендер, диплом бирмәячәкләр икән, дигән имеш-мимеш тә таралып өлгергән иде студентлар арасында.

Җыелышка институтның комсомол секретаре Порфирий Рыков белән ректор Василий Янович та керде. Утырышны ректор башлап җибәрде. Чыгышы белән ул яһүд. Студентлар җитмешне узып барган бу профессорның лекцияләрен аеруча яратып тыңлыйлар. Һәм аларның аны беркайчан да мондый басынкы, агарынган кыяфәттә күргәннәре юк иде.

— Иптәшләр, — диде ректор, кашын җыерып. — Бүген безнең институтта ЧП. Калганын сезгә комсомол секретаре җиткерер.

Аннары ул, Порфирий Рыковның колагына нидер әйтеп, авыру кеше сыман чайкала-чайкала чыгып китте.

Комсомол секретаре — баскан эзеннән ут чыгардай зур гәүдәле урыс егете — бу юлы бик җебеп кенә сүз башлады:

— Бер сүз белән әйткәндә, егетләр, безнең арада утыручы ике студентка диплом бирелмәячәк.

Әлеге хәбәрдән студентлар бер мәлгә тынып калды. Аннары аяк тыпырдату, сызгырыш башланды.

— Беспредел!

— Анысы нәрсә өчен тагын?

— Ха-ха-ха! Биш ел черәшеп укыганнан соңмы?

— Кемнәр алар?

Комсомол секретаре, тирләгән маңгаен пиджак җиңе белән сыпырып, ишетелер-ишетелмәс кенә җавап бирде:

— Хәзер әйтәм. Алар... Баязит Сафин һәм Әлфия Шәмукова.

Аудиториядә үле тынлык урнашты.

—Во дают!.. Медалистка диплом бирмиләр!

—Нәрсә өчен?

—Моразум!

Тагын аяк тыпырдату, сызгырыш башланды.

— Туктатыгыз тәртипсезлекне! — дип кычкырды комсомол секретаре, өстәлгә йодрык сугып. — Башта тыңлап бетерегез, аннары хет... МГБның нәрсә икәнен барыгыз да беләсездер инде?

— Һе, кем белми аны? Министерство госбезопасности!

— Дө-рес, бик дөрес! — дип дәвам итте комсомол секретаре. — Бүген иртән МГБдан сигнал килде: унсигезенче группа студентлары Баязит Сафин белән Әлфия Шәмукова, безнең югары уку йортына документлар тапшырганда, анкеталарын дөрес тутырмаганнар.

— Туган елларын бутаганнар микәнни?

— Ха-ха-ха!

— Көлмәгез, көләргә әле иртәрәк. — Комсомол секретаре бармагы белән артта утырган ике студентка ишарә ясады. — Сафин, басыгыз! Сез дә басыгыз, иптәш Шәмукова!

Имәнеп калган егет белән кыз теләр-теләмәс кенә торып бастылар.

— Мин дөресен сөйлимме? — Комсомол секретаре йөзен чытып куйды.

Тегеләр җавап урынына иңнәрен генә сикерттеләр.

— Нигә җавап бирмисез? — Рыков кызып ук китте. — Әтиләрегез халык дошманы булуын нигә анкетага теркәмәдегез? Комсомол кешегә алдашырга ярамый.

Тагын тынлык. Беренче булып Баязит телгә килде:

— Минем әтием халык дошманы түгел.

— Димәк, синеңчә, безнең дәүләт куркынычсызлыгы органнары ялгышкан? — Рыков каһкаһә белән елмаеп куйды.

— Әйе, ялгышкан шул, — дип мыгырдады Баязит. — Бик беләсегез килсә, анда да безнең кебек үк ике аяклы, ике куллы кешеләр эшли.

— Телеңә салынма. Ә син, Шәмукова, нәрсә әйтерсең?

— ...

— Телеңне йоттыңмәллә? Җавап бир!

Әлфия җавап бирмәде. Аның зырылдап башы әйләнә иде.

— Ярый, буласы булган. Һәрхәлдә, мин үзем сезне чын комсомолеңлар дип саный идем. Әтиләр өчен балалар җавап бирми. Шулай да сез бүген, менә шушы җыелышта, әтиләрегездән баш тартырга тиеш. Күрсәтмә шундый. Юкса дипломны төшегездә дә күрмәячәксез.

— Ничек, ничек? — Баязитның күзләреннән яшь бәреп чыкты. — Әтидән баш тартырга?.. Үз әтиемнән?.. Минем әтием халык дошманы түгел!

Ул арада Әлфия, елап җибәреп, аудиториядән йөгереп чыгып китте. Моны күреп, Баязит та аңа иярде.

Чыгышы белән Чиләбе өлкәсеннән булган озын кара толымлы бу кыз Баязитның йөрәген инде беренче курстан ук җилкендерә иде. Әмма оялу хисе һәрвакыт җиңеп килде. Ничәмә-ничә тапкыр омтылып карады ул аңа мәхәббәттә аңлашырга, тик берничек тә булдыра алмады. Ниндидер сәер көч телен бәйли дә куя! Хәер, Әлфия аның өчен матурлыгы белән генә түгел, башка ягы белән дә чын идеал иде. Алдынгы комсомолка, отличница! Ә ул кем? Халык дошманы малае. Укуы да уртача гына. Шуларны уйлый да кимсенә, бетеренә, үзен аңа лаексыз дип хис итә иде Баязит.

Әлфияне зур гына ерганак аша салынган асылмалы күпер өстендә куып җитте ул. Бу юлы — гаҗәп! — оялып тормады, җайлы гына сүз башлады:

— Әлфия, син борчылма. Ул дипломны тозлап куймаслар бит инде, быел бирмәсәләр, икенче елны бирерләр.

Чем-кара күзләрен аска юнәлткән кыз инде еламый иде. Юка иреннәрен тешләп, кырыс кына җавап бирде:

— Минем әтием халык дошманы түгел. Ул завод директоры иде. Парторгны кулга алгач, Сталинга хат язды. Берничә көннән үзен дә алып киттеләр.

— Мин ышанам сиңа, Әлфия. Син дә миңа ышан. Минем әтием дә халык дошманы түгел. Район газетасы редакторы иде ул. Газетаның бер санында Сталинград дигән сүзнең «р» хәрефе төшеп калган да Сталин гад дигән сүз килеп чыккан. Шуның өчен утырттылар.

Әлфиянең хәзер беркеме дә юк икән. Әтисе кулга алынгач, әнисе бу хәсрәткә чыдый алмыйча асылынган. Озакламый Әлфияне фатирыннан да куып чыгарганнар. Свердловскида ул әнисенең сеңлесендә яши иде.

Нинди генә фаҗигале булса да, ул көнне Баязит һәрвакыт сагынып искә ала. Беренче кочаклашу, беренче үбешү, беренче елашулар... Ул йолдызлар әле дә күз алдында тора. Андый серле, якты, матур йолдызлар күк йөзендә инде беркайчан да булмас... Алар өчен булмас.

Иртәнге якта Әлфиянең апасына кайтып чәй эчтеләр. Аннары институтка бардылар. Тагын үгетләү, тагын куркыту.

Шулай кабинеттан кабинетка йөри торгач, бер атна вакыт узып китте. Дипломны тәки бирмәделәр. Дөрес, Свердловски медицина институтында укыганлыклары турында белешмә бирелде бирелүен.

Өметләр өзелде. Икәүләп Чыбыклыга — Баязитның әнисе янына кайтып киттеләр. Анда озак тормадылар, ике-өч көнгә җитәрлек азык-төлек алдылар да Казанга юл тоттылар.

Әлфия мең бәлаләр белән булса да, шундагы хастаханәләрнең берсенә шәфкать туташы булып урнашты. Баязит 22 нче заводта слесарь ярдәмчесе булып эшли башлады.

Аннары илдә шактый үзгәрешләр булып алды, властька башта Хрущев, соңыннан Брежнев килде. Әлфиянең дә, Баязитның да әтиләрен реабилитацияләделәр. Ни гаҗәп, Свердловски медицина институтыннан, инде шактый күп вакыт узган, сезгә диплом бирә алмыйбыз, дигән җавап хаты килде. Шулай итеп, Әлфия хастаханәдә элеккечә шәфкать туташы булып калды, ә Баязит Казан химия-технология институтына укырга керде.

Яши торгач, Альберт дөньяга килде. Авыр еллар иде. Кешедә фатирда яшәделәр. Хезмәт хакы ашауга гына җитеп бара. Ләкин акрынлап барысы да җайлана төште. Институтны тәмамлагач, Баязит фәнни-тикшеренү институтында эшли башлады. Башта тулай торактан бер бүлмә бирделәр. Уңайлыклары булмаса да, барыбер үз куышың бит. Аннары Баязитны бүлек мөдире итеп куйдылар. Көнне төнгә, төнне көнгә ялгап эшләде. Берничә ачышы өчен ак-

чалата премия белән дә бүләкләделәр. Әмма алар өчен иң зур бүләк — ике бүлмәле фатир булды.

Менә шуларны искә төшереп ятты да Баязит трамвайлар йөри башлагач кына йокыга китте. Дөресрәге, черем итүе генә иде бу аның. Чөнки уе тиз кайтам дип чыгып киткән улы Альберт янында иде.

## Наполеон һәм бүре

Шарт-шорт итеп мылтык ата башлагач, ерганак янында үскән биек имән агачыннан бер адәм егылып төште. Фәкыйрь генә киенгән, яше утыз-утыз бишләр чамасы булыр. Альштай зур гәүдәле булгангамы, ул килеп төшкәч, хәтта җир селкенеп куйды. Шул ук агач куышында юынып утырган борындык, төне буе үз-үзе белән сөйләшеп чыккан сәер бәндә белән нәрсә булганын күрергә теләгәндәй, башын чыгарып аска карады. Әйе, бигрәк сәер бәндә шул, табигатьтә җәй башы, ә ул колаксыз иске күн бүрек, ертылып беткән телогрейка һәм резина итек кигән.

— Буталдым мин, буталдым, — дип бытырдады егет, ике кулы белән башын тотып. Үзе бертуктаусыз чайкала, әйтерсең бишектә бала тибрәтә. — Әллә бутадылармы?.. Нәрсә калган иде миңа ул тауларда?.. Ничек инде нәрсә?.. Рәхәтләнеп кеше үтердем! Ха-ха-ха...

Егет, сикереп торып, автоматтан аткан рәвеш китерә башлады:

— Тра-та-та-та-та! Берәү... икәү... өчәү… — Аннары җиргә капланды да кычкырып еларга, үкерергә тотынды. — А-а, мин сезне ишетмим, иптәш өлкән лейтенант!.. Ишетмим! БТР яна, тизрәк чыгыгыз! А-а!

Борындыкка кызык, ул һаман сәер бәндәне күзәтә.

Ниһаять, егет кычкырып җырлап җибәрде:

Без авылдан чыккан чакта
Күтәрелде тузаннар.
Яз кайтмасак, көз кайтырбыз,
Сау булыгыз, туганнар!

Җырны шаркылдап көлү алыштырды:

— Ха-ха-ха! Кайттык шул, кайттык! Тәмугтан тәмугка кайтып кердек. Их, абый, аңламадың мине-е... Мин бит мунчачы түгел, мин — Наполеон. Синең кебек өч тиенлек адвокат кына түгел мин, гаскәремә бер генә фәрман бирәм, шундук синең Кармагышыңны сытып китәчәкләр! Үзем дә юләр инде, шундый бөек полководец булып, сине сәнәк белән дөмектерә яздым. Асарга гына кушасы калган. Кунакларыңны да үзең белән асарга кирәк иде шунда. У-ух, кеше түгел син, абый! Эт токымнарын яклыйсың бит. Адвокатларның барысын да атып үтерер идем мин. Әлегә мин

моны булдыра алмыйм. Минем гаскәр, Мәскәүдән чигенгәндә, зур югалтуларга дучар булды. Әнә һаман атышалар булыр. Ишетәсеңме мушкет тавышын? Күтеп тор, тиздән мин Кармагышка яу белән киләм. Минем өчен салдырган резиденциянә ут төртәчәкмен. Андый җимерек йортлар белән бөтен Рәсәй тулган. Франциядә –Парижда минем матур сараем! Хәер, мин инде җиңелдем. Мине тиздән Изге Елена утравына озатачаклар. Сау бул, урман!

Әллә авылга кайтып әни белән хушлашыргамы? Аллам, ул бит үлде. Ә әти янына кайтмыйм. Ул мине тагын тилеләр йортына салачак. Тиле, диләр мине... Сез үзегез тиле!

Буталдым мин, буталдым! Дөресрәге, бутадылар! Нигә җибәрдегез мине тауларга?! Мин бит кеше үтерергә теләмәдем. Интернациональ бурыч, имеш. Әнә хәзер минем кебек интернационалистлар Чечняда кеше үтерә! Нәрсә кирәк бу кешегә, һич аңламыйм! Ул бер-берсен үтермичә яши алмый. Үтермичә яшәү аның өчен үлем белән бер. Без барыбыз да үтерүчеләр! Үтерүче үтереп ләззәт ала, үтерергә мөмкинлеге булмаганнар үтергәнне карап ләззәт ала. Аһ!.. Авызда кан тәме! Кулларда кан! Әччәч!

Сәер адәм тагын җыр сузды:

— Яшь гомер бер узга-ач, кайтмый ул яңада-ан... Минем яшьлек тә узып бара, Фәниякәй. Ничек яраттым мин сине! Мин гаеплемени сугыштан Наполеон булып кайтканга? Генерал булырга хыялланмаган солдат начар солдат, дип әйтә иде безнең командир. Тик үзе генерал була алмас инде, теге дөньяда ул хәзер. Җирдә Кызыл Йолдыз ордены гына калды. Хатыны белән баласы да җирдә калды. Хәзер ул оҗмахта, яисә тәмугта генераллык итәдер. Кансыз иде шул. Үз башын һәм безнең башны саклап калу өчен, дошман йортына тәрәзәдән «лимонка» гына тәгәрәтә иде. Күп күрдем мин өзгәләнеп беткән хатын-кыз, бала-чага гәүдәсен. Без туздырып киткән авылларда үләксә ашый торган шакаллар гына кала иде.

Егет, акылына килгәндәй, кинәт тынып калды да, тезләрен кочаклап, күзләрен бер ноктага текәде. Нәрсәнедер исенә төшерергә тели кебек.

Әйе, исенә төшерде. Илдарның Казан педагогия институтында, рус һәм татар теле бүлегендә укыган чагы иде ул. Матур гына шигырьләр язгалый, спорт белән шөгыльләнә иде Илдар. Шигырьне Фәния белән танышкач яза башлады. Татар кызы булса да, чәчләре бөдрә һәм сап-сары булгангамы, дус кызлары аңа Француженка дигән кушамат такканнар иде. Тешләре, мин сиңа әйтим, мәрҗән кебек җемелдәп тора!

Фәния белән кичләрен Кабан күле буенда йөрергә яраталар иде. Очрашу урынына соңга калып килгәнне бер дә яратмады. Үзе дә гел төгәл булды. Шуңа күрә Илдар ун-унбиш минутка алданрак килергә тырыша иде. Алай да беркөнне свиданиегә вакытында килә алмады. Апаларына барган җирдә лифтта бикләнеп кал-

ды. Икенче көнне, гаебен юар өчен, аңа бер дигән чәчәк букеты алып килде ул. Букет эчендә Фәниягә багышланган шигырь дә бар иде. Ләкин ачуы чыккан кыз букетны чүп савытына томырды да, тырт итеп, тулай торакка йөгереп кереп китте. Соңыннан дуслаштылар дуслашуын. Шул көнне Илдар үзенең иң матур шигырен язды. Тик... никтер күрсәтергә оялды. Үпкәләр дип курыкты, ахры.

Өченче курста Илдарны армиягә алдылар. Ярты ел чамасы учебкада булгач, аларның ротасын Әфганстанга озаттылар. Менә шунда хат белән җибәрде ул үзенең шигырен.

Синең өчен кулга каләм алдым,
Синең өчен аны сындырдым.
Раббы биргән бүләк иде бит ул,
Һәм мин аны җиргә тондырдым.
Тик син гөнаһлырак, син ул төндә
Шигыремне минем яндырдың.

Фәния берсеннән-берсе назлырак хатлар язды. Что син, герой бит аның Илдары! Әфган тауларында үзенең изге бәйнәлмиләл бурычын үти! Ул чакта солдат хатының кадерен белә иде кызлар.

Дембельгә нәкъ өч көн калгач, Илдар йөрткән БТР засадага юлыкты. Аннары контузия, госпиталь. Озак ятты, ләкин баш авыртуы бетмәде. Күпме дару ашаганын үзе генә белә Илдар.

Больницадан чыкканда, акылында иде әле. Дөрес, көн дә дару эчеп торырга куштылар. Кыяфәт юк иде. Көзгегә күз салгач, үзүзеннән коты очты. Аннан егерме ике яшьлек Илдар урынына ап-ак чәчле бер абзый карап тора иде. Шуннан соң аның көзгегә карağаны булмады.

Канатланып Фәния яшәгән район үзәгенә килде. Ул анда инде укытучы булып эшкә урнашкан иде. Капка төбенә чыкты чыгуын. Әмма бераз сөйләшеп торгач, бүтән килмәскә кушты. Менә шуннан соң ычкынды инде Илдар. Бик каты эчә башлады. Ә аңа бер тамчы да аракы ярамый. Шизофрения — табиблар куйган соңгы диагноз шундый булды.

Әнисе исән булганда, берәү дә рәнҗетә алмады Илдарны. Авылдашлары да башта кызгана иде, ләкин соңыннан көлә, мәсхәрәли башладылар.

Ел саен бер саташып ала Илдар. Бу юлы исә бераз озаккарак сузылды. Яздан бирле ята инде ул бу урманда. Һәрбер куак, һәрбер агач төбендә өзгәләнеп беткән кеше гәүдәләре аунап ятадыр сыман тоела аңа. Китәргә тели, ләкин китә алмый. Чөнки үзенең кем булуын, кайдан булуын онытып җибәрә. Вакыты-вакыты белән аңына килгәндәй була, нәрсәнедер исенә төшергәч, тагын саташа башлый.

Нинди мылтык тавышы бу? Әллә аны эзләп чыкканнармы?.. Аһ, тагын баш әйләнә! Әллә алар да Илдар кебек урманда бәхет

эзләп йөриме? Юк, мылтык белән бәхет эзләмиләр. Мылтык — ул үтерү коралы. Димәк, алар кемне дә булса үтерергә чыкканнар.

Янә үз-үзе белән сөйләшә башлаган адәм баласын күзәтә торгач, борындык арды. Аңа инде җим эзләргә вакыт, ояда дүрт кечкенә борындык ашарга сорый.

Илдар ерганак астындагы чишмәгә төшеп китте. Инде иелеп су эчәм дигәндә генә, куе әрәмәлек эченнән ырылдаган тавыш ишетелде.

— Кем бар анда? — диде Илдар, юләр күзләрен чекерәйтеп.

Әрәмәлек эченнән бүре карап тора иде.

— Кем син?.. Этме, бүреме?

Бүре, җаны да чыгып бетмәгән керпене җиргә куеп, Илдарга таба килә башлады. Кеше табигате белән куркак, ул моны яхшы белә. Хәзер бу адәм баласы да үкчәсен ялтыратачак.

Ерткыч ялгышты. Адәм баласы качарга уйламады да. Киресенчә, елмаеп басып тора. Мондый самими елмаюны ана бүренең күргәне юк иде әле.

— Исәнме, бүре! — диде салам кибәнедәй сап-сары башлы адәм, бүреген салып. — Таныш булыйк, мин — Наполеон! Син миннән курыкма, минем бүреләргә тигәнем юк. Мин кеше генә үтерәм. Дөресрәге, үтердем дип әйтергә була. Мин әшәке кешеләргә генә тиям. Әле күптән түгел генә абыйны сәнәк белән үтерә яздым. Хәзер хастаханәдә ята булыр. Начар кеше ул. Безнең бистәдә берничә түрәнең малае сигез яшьлек кызны көчләп үтерде. Ә абый аларны яклады, акчага ялган шаһитлар сатып алды. Мунча гына ягып торсам да, мин барысын да беләм. Мин аның колы, бүре-бүрекәй. Шуның өчен ул миңа җимерек кенә бер йорт сатып алып бирде. Мунча йортка караганда затлырак... Син нәрсә, минем Наполеон булуыма ышанмыйсыңмы? А, нинди генә Наполеон идем әле мин! Аустерлица янында җиңелгәч, мунчачы иттеләр мине. Ярый, Изге Елена утравында яту түгел инде, шулай бит? Яхшы ерткычлар сез, бүреләр. Сез бер-берегезгә тимисез. Ә без тиябез. Адәм балалары бер-берсенең бугазын чәйнәп өзәргә әзер. Их, нигә мин бүре булмадым икән?!

Ана бүре, ырылдаудан туктап, җирдә яткан керпене тагын авызына алды. Адәм баласының зыянсыз булуын аңлады ул. Чак кына аңа текәлеп карап торды да үз өненә элдертте.

— Илдар!

Егет сискәнеп артына борылып карады. Анда аның ап-ак кәфенгә төренгән әнисе басып тора.

— Әнием, мин сине шундый сагындым! — дип кычкырды ул. — Син исән!!!

— Мин бик ардым, балакаем. — Ана кешенең күзләреннән яшь тәгәрәде. — Синең өчен борчылып, үземә урын тапмыйм.

— Минем өчен борчылма, әнием. Мин бит Наполеон. Бөтен дөнья минеке! Бу урман да минеке, әнием!

— Йөрмә болай мәсхәрәләнеп, өйгә кайт!

— Кайсы өйгә? Минем бит хәзер ике өем бар. Берсе абый сатып алып биргәне, икенчесе — төп йорт. Беренчесенә кайтсам, мине төрмәгә утыртачаклар, икенчесенә кайтсам, әти кыйный. Наполеон булганым өчен кыйный, әни. Ә моның нинди начарлыгы бар, әнием?!

— Сиңа дәваланырга кирәк.

— Дәваланырга? Соң бу җирдә бер мин генә Наполеонмыни? Һәркем үзенчә Наполеон бездә. Президент та, губернаторлар да, район башлыклары да, колхоз рәисләре дә — барысы да Наполеон. Аларның һәркайсына власть, акча, дан-шөһрәт кирәк. Ишетәсеңме, барысына да! Димәк, мин авыру икән, алар да дәваланырга тиеш! Минем абый да Наполеон. Ул миңа Кармагышта йорт сатып алды. Туган итеп түгел, хезмәтче итеп. Шуңа күрә дә мин аны үтермәкче булдым. Сигез яшьлек баланы көчләгән кечкенә үтерүчеләрнең ата-аналары да Наполеон. Хәзер аларның балалары чит илдә белем ала. Алар бай, шуңа күрә закон алар ягында. Бездәге законнарны да менә шундый кечкенә Наполеоннар уйлап чыгара, әнием.

— Син саташасың.

— Бәлки, саташамдыр да. Ләкин миңа монда рәхәт. Монда миннән берәү дә көлми. Бутадылар мине, әнием, бутадылар. Наполеон булырга теләмәгән идем мин. Солдат иттеләр дә Наполеон булырга куштылар.

— Син тынычланмыйча, мин тынычлык таба алмам, балам.

Әнисенең сурәте томан кебек таралып юкка чыккач, Илдар, чирәмгә йөзтүбән капланып, үкси-үкси еларга тотынды.

## Төш

Өненә шуышып кергәч, ана бүренең йөрәге рәхәт кысылып куйды. Монда бераз салкынчарак иде, кечкенә бүреләрнең юеш танавыннан сөт исе килеп тора. Әниләренең авызындагы керпене күргәч, йомгак кебек түп-түгәрәк җан ияләре, көязләнеп, иркәләнеп чинарга тотындылар. Ана бүре күз ачып йомарга да өлгермәде, нарасыйлары, ырылдый-ырылдый, керпене өзгәләргә керештe.

Керпене ашап бетергәч, бүреләр, бер-берсен этә-төртә, үзләрен күзәтеп яткан бәхетле ана бүренең имчәгенә тапланды. Ничек рәхәт бу нәниләренңне имезү! Аларның татлы кытыклавы җанга, тәнгә сихәт бирә. Ата бүре дә үлеп ярата иде балаларын. Ау шәп булган көннәрдә, алар белән бик озаклап уйный иде. Хәзер бөтен авырлык, бөтен җаваплылык ана бүре өстендә. Җәй урталарында ул аларны үзе белән вак-төяк киек артыннан ауга алып чыга башлаячак.

Аннары бүре шундук изрәп йокыга китте. Матур төш күрде ул.

Имеш, ата бүре биек тау башында айга карап улап утыра.

— Нигә шулай өзгәләнеп улыйсың? — дип сорый ана бүре. — Кайтыйк, бүрекәйләрең сагынып бетте үзеңне!

Ата бүренең җавабы моңсу:

— Ярамый миңа кайтырга.

— Нигә?

— Мин бит инде үлдем.

— Син үлмәдең, син тере. Кайтыйк, әйдә!

— Мине үтерделәр. Бу вафасыз дөнья гел үтерүдән тора. Үземә таныш булмаган болын буйлап чабып барганда, миңа бер бал корты очрады. Мин аны үтермәкче булдым. Тик ул шундук телгә килде, мине үтерү дигән нәрсәнең әхлакый ягын уйларга күндерде.

Аныңча, әгәр без, бүреләр, берәр җәнлекне тотып ашыйбыз икән, моның өчен безне сүгәргә дә, каһәрләргә дә ярамый. Чөнки без шул рәвешле исән калу, нәселне дәвам иттерү өчен көрәшәбез. Ә менә юлымда очраган бал кортын ашасам, минем тамагым туймас иде. Димәк, аны үтерсәм, мин кызык өчен генә үтерәм. Кызык өчен үтергәнне табигать гафу итми. Адәм баласы, никадәр генә югары интеллектлы саналса да, кызык өчен дә үтерә. Кызык өчен үтерүдән саклан, ана бүре. Кырмыскага да, үрмәкүчкә дә, бал кортына да тимә. Алар өчен үзең Алла бул!

Шушы урында ана бүре уянып китте. Тышта яңгыр коя. Ә аның имчәкләрен имеп арган яшь бүреләр, бер-берсенә елышып яткан хәлдә, йокымсырап киткән иде.

## Телсез Василий мылтык майлый

Рекс чылбырыннан ычкынырдай булып буыла-буыла өрә башлагач, Василий, мич артындагы караватыннан торып, эренләп беткән күзләрен уа-уа, ишегалдына күз салды.

Кемдер бар, эттән куркып, капкадан керергә генә җөрьәт итми.

— Василий! — Ниһаять, капкадан берәү башын тыкты.

Чыпчык Мансуры бу. Кәтүк кадәр генә булса да, тавышы каты чыга. Бирмәсә бирмәс икән Ходай адәм баласына: буе кечкенә булу өстенә, кыяр кебек озынча йөзен локатордай зур колак белән дә бизәп куйган. Карап торышка чын шәмәк инде менә.

Василий иренеп кенә болдырга чыкты, ишарәләр белән аның йомышын сорады.

— Синең ярдәм кирәк, Василий, — диде Чыпчык Мансуры, борын тартып. — Бүре фермада дүрт сарыкны буып чыккан. Артыннан куа чыккан идек, тотып булмады. Мылтык миндә булса,

кача алмас иде, кәнишне. Чулак Рәшитне беләсең бит, юкка гына чулак димәгәннәрдер инде, тидерә алмады.

Шул мәлне берәү аның күтенә типте, ахры. Мансур черек тешләрен ыржайтып көлеп җибәрде.

— Җә, җә, шаяртам гына бит мин, Рәшит, — диде ул капка артында торган иргә. — Ничек, Василий, барасыңмы безнең белән?

Василий, башын кашып торды-торды да, вакытым юк, үзегез генә барыгыз инде, дип ишарә ясады.

— Үзеңә кара, — диде Мансур. — Председатель кушуы белән йөрибез. Кара аны, көзен печәнсез кала күрмә!

Капка ябылгач, Василий, өйгә керец, укшый-укшый бер тустаган әче балны каплап куйды. Ишегалдында ярырга дип әзерләп куйган берничә бүкән бар, аларны бүген ярып булмас инде. Мондый махмыр вакытында башны күтәрмичә генә ятарга кирәк. Каты эчелде шул. Теге санинструктор кыз төннәр буе карават башында басып тора. Бер сүз дә дәшми. Акылдан язарсың бу хәлгә. Ничек иренми, ә? Үлгәнсең икән, ят инде тыныч кына теге дөньяда.

Яшьлек гөнаһысы газаплый Василийны. Немец Киевны алган чакта булды бу хәл. Калиновка авылы янында безнекеләр тагын чигенә башлады. Өстән «Мессершмитт»лар бомба коя, арттан артиллерия тетмәне тетә. Күп халык кырылды. Шунда снаряд кыйпылчыгы Василийның да балтырын яралады. Бомба хасил иткән тирән чокырга тәгәрәп төшмәсә, ул да бетә иде. Колаклар тонган, авыз-борын тутырык юеш балчык. Балтырдан сиптереп аккан канны күргәч, куркудан елый, акыра башлады.

Бермәлне чокырга яшь-яшь кенә санинструктор кыз тәгәрәп төште. Бинтлары беткән. Үзенең юбка итәген ертып, Василийның аягын бәйләргә кереште.

— Кость не задет, до свадьбы заживет, — диде кыз елмаеп.

Балтырдан кан килми башлады. Самолетлар һаман баш очында бөтерелә. Тик инде бомба ташламыйлар, пулеметтан гына сиптерәләр. Кызның шәрә ботын күргәч, әллә нәрсә булды Василийга. Унсигез яшьтә менә шулай кызлар үпмичә дә үлеп китәр микәнни? Ә сугышның башы-ахыры күренми.

Егет, үзе дә сизмәстән, кызны кочаклап алды. Мондый чакта терап атсалар да, берни уйламыйсың икән ул. Нинди төз, нинди матур ботлар!

Санинструктор чәбәләнә, каршылык күрсәтә:

— Убери руки, сволочь! Мне нужно к раненным!

Гаярь чагы иде Василийның, юбканы икегә генә аерды. Тешләшә башлагач, бер-ике тапкыр йөзенә дә сугып алды. Тапкан каршы килер вакыт, бөтен җирдә сугыш бара, көнгә меңәрләгән кеше кырыла, ә бу тиле гыйффәт пәрдәсен саклап йөри!

Барыбер көчләде. Кызлыгын югалткан санинструктор, беркадәр тузан болыты каплаган күк йөзенә карап, тып-тын ятты. Бит

алмаларыннан буй-буй булып яшь ага иде аның. Аннары аңына килде булса кирәк, чыелдап, егетнең яңагына сугып җибәрде:

— Мин сине трибуналга бирәм, кабахәт!

Югалып калды Василий. Элекке гаярьлектән җилләр искән. Сугыш вакытында моның өчен аталар. Ни эшләргә? Якын-тирәдә бер генә җан әсәре дә юк. Димәк...

— Аh ты, сука! — диде ул, бармакларын кызның бугазына батырып. — Төкердем мин синең трибуналыңа! Сталиныңа да, Лениныңа да төкердем! Аңладыңмы?!

Кыз җебеп төшә торганнардан түгел икән. Беләген шундый итеп тешләде, хәтта Василийның акырган тавышы «Мессершмитт»-лар гүелдәвен күмеп китте.

Аннары барысы да куркыныч төш кебек булды. Егет, кизәнеп, штыкны кызның күкрәгенә тыкты. Хәтфә үлән кебек матур яшел күзләр, бер мизгелгә акаеп, аңа текәлде. Матур булсалар да, куркыныч иде алар. Аннары кыз, берничә тапкыр гыжылдап алгач, соңгы сулышын чыгарды. Йөзендә ниндидер бер мыскыллы елмаю бар иде аның. Төнлә дә менә шундый кыяфәттә килә ул Василий янына.

Кыз чокырда калды. Безнекеләр янә атакага күчкәннәр икән. Василий да, ура кычкырып, исәннәр артыннан иярде.

Алла каргады Василийны. Берлинга кадәр барып җитте, ләкин аны бер генә пуля да, бер генә снаряд кыйпылчыгы да алмады. Юкса хыялында гел үлү генә иде. Дөрес, сугышның иң соңгы көнендә контузия алды ул. Каhәр суккан снаряд, үтермәде бит, үтермәде! Бусы да Ходай каргышы, күрәсең.

Шул көннән башлап, Василий телсез калды. Ишетүен яхшы ишетә иде үзе. Сугыштан кайтып керүгә, ул карт әти-әнисен күмде. Икесе дә бер көнне үләт авыруыннан китеп бардылар.

Василий Ленинград блокадасы вакытында күчеп килгән Маруся исемле бер кызга өйләнде. Ләкин бәхетләре булмады, Марусяның өч баласы да үле килеш туды. Василий эчте дә эчте. Моның Алла каргышы икәнен белә иде ул. Аннары Маруся, аны ташлап, Ленинградка китеп барды.

Озакламый авыл таралды. Яше дә, карты да шәhәргә күчеп китте. Якын-тирәдәге урыс авылларының да нигезе корыды. Татар авыллары, киресенчә, hаман үсә, зурая барды. Эш сөя татар кешесе, җиргә кендек белән береккән ул. Ә урыс hаман эчүен белде. Аңа шәhәр тормышы тансык.

Басу уртасында Робинзон кебек яшәп булмый, Василий да, җаен табып, күрше татар авылына күчеп утырды. Бүтән өйләнмәде.

Узган елларны ул сыер да асраган иде, быел аны бетерергә булды. Өйдә хатын, бала-чага булмагач, ул нигә кирәк? Бер тамакны ничек тә туйдырырга була.

Василий стенада эленеп торган мылтыкны өстәлгә алып куйды. Әтисеннән калган мал бу. Яшьрәк вакытта ул да ауга чыгарга

ярата иде. Ана бүре, иртәме-соңмы, аңа кунакка киләчәк. Ата бүренең гәүдәсен эзләп киләчәк ул. Шуңа да Василий бүре тиресен бакча башындагы биек колгага элеп куйды.

Картая башлагач, адәм баласы гел бала чагын искә төшерә икән. Мылтык чистартып утырган бер мәлдә, телсез дә балачакка кайтып төште.

**Кем алласызлар түгәрәгенә языла?**

Василийга сигез генә яшь иде әле. Әтисе аны, киндер ыштан киертеп, приходка алып килде. Анда кара сакаллы бер поп балаларга дин дәресләре бирә иде.

Беренче көнне поп аларны Тәүрат белән таныштырды. Ә икенче көнне дәрескә башларына кызыл яулык япкан апалар килеп керде.

— Исәнмесез, балалар! — диде аларның берсе. — Бүгеннән башлап, Совет власте сезнең өчен мәктәп ача. Мәктәп каршында алласызлар түгәрәге эшләячәк. Кем алласызлар түгәрәгенә язылырга тели, кул күтәрегез.

Берәү дә кул күтәрмәде. Киндер ыштанлы малайлар, моны шаярту гына дип уйлап, көләргә тотындылар.

— Мин шаяртмыйм, кем алласызлар түгәрәгенә йөрергә тели? — дип кабатлады хатын.

Тынлык урнашты. Әти-әниләре аларның алласызлар түгәрәгенә язылганнарын белсәләр, өйдә каеш эләгәчәк бит. Кечкенә генә шуклык өчен дә, «Алладан курык!» дип әйтә ич әти-әниләре. Ә бу апа Аллага каршы әйтә. Ю-ук, алласызлар түгәрәгенә язылмаячаклар алар!

Балалар берәм-берәм өйләренә шылдылар. Кызыл яулыклы апалар ишек янында торып та берни эшли алмадылар. Өлгермәгәннәре тәрәзәдән коелышты.

Өйләренә кайткач, балалар мәктәптәге хәлләрне бәйнә-бәйнә сөйләп бирделәр. Ата-аналар, әби-бабайлар бер чукынды, бер аһ итте.

Икенче көнне берсе дә баласын мәктәпкә җибәрмәде. Кичке якта кызыл яулыклы апалар, йорттан йортка йөреп, балаларны биленә наган аскан күн тужуркалы бер абый белән җыеп йөрделәр.

Берәр атнадан алласызлар мәктәбе тулы көченә эшли башлады. Дәрестән соң кызыл яулыклы апалар һәм киндер ыштанлы малайлар, быргы кычкыртып, барабан кагып, Аллага, патшага каршы шигарьләр күтәреп, авыл буйлап маршировать иттеләр.

Беркөнне Василийны бабасы чыбыркы белән каршы алды. Герман сугышында алган уң яңагындагы тирән җөе ачулы вакытында аеруча куркыныч төс бирә иде аңа.

— Кайттыңмы, алласыз?! — дип ыжылдады ул, Василийның аркасына сыдырып. — Хәзер күрсәтәм мин сиңа Аллага ничек каршы барырга икәнлекне!

Әй шәп эләкте Василийга! Әти-әнисенә дә эләкте. Ишегалдында давыл котыра дип уйларсың, бөтен нәрсә җимерелә, кырыла, оча гына, мин сиңа әйтим.

Элек әтигә каршы әйтү дигән нәрсә юк иде. Василийның әтиәнисе бакча башына сыздылар. Малай да качты.

Төне буе көл исе иснәп, мунча миче эчендә ятты ул. Уянып китсә, бабасы ишегалдында: «Кая китте икән бу шайтан, әллә Митәй әрәмәлегендә качып ятамы?» — дип сукранып йөри. «Кәҗәне таба алмыйлар, — дип уйлады Василий, пошаманга төшеп. — Болай булгач, тиз генә күренергә ярамас. Юкса тагын тотып ярачак». Йортта кәҗә өчен җавапны кеше ул. Бу юлы куркудан кәҗәне алып кайтырга оныткан. Бабасы дөрес әйтә, Митәй әрәмәлегендә ята аларның кәҗәләре.

Василий мунчада тагын бер төн кунды. Каян белгәндер, төш вакыты җитәрәк, әнисе өстерәп чыгарды. Баксаң, кәҗәне түгел, аны эзлиләр икән!

Бала икенче көнен мәктәпкә килми. Бу нинди хәл? Кичке якта Василийларның өйләренә авыл сәвитеннән берничә вәкил килеп җитте. Кызыл яулыклы укытучы апа да шунда. Баланың аркасында чыбыркы эзе. Кем суккан?

Бабай, кызып китеп, аларны өйдән үк куып чыгарды.

Ике-өч көннән бабайны Василий белән авыл сәвитенә чакырттылар. Сүзне биленә наган асып йөри торган күн тужуркалы бәндә башлады:

— Баланы кем кыйнады?

Бабай дәшми. Инде Василийга чират:

— Бабаң нигә кыйнады, Вася? Алласызлар түгәрәгенә язылган өченме?

Бабасыз калудан куркып беткән малай кычкырып елап җибәрде:

— Кыйнамады мине баба-ай... Кыйнаса да, әйтмәс иде-ем.

— Павлик Морозовтан үрнәк ал, братишка, — диде күн тужуркалы абзый үҗәтләнеп. — Дөресен сөйлә, алласызлар түгәрәгенә йөргән бала алдашырга тиеш түгел. Аркаңда нинди чыбыркы эзе ул?

— Читән аша сикереп чыкканда сыдырылды.

— Кемнән качтың шулай?

— Кәҗә артыннан кудым. Ул күршеләр бакчасына кергән иде.

— Ә нигә мәктәпкә йөрмисең?

— Эчем авыртты.

— Алдашасың, энем, ай алдашасың!

Утыра торгач, тегеләр дә арды, болар да арды. Василийның бабасын, оныгыңа тырнак белән генә чиертсәң дә, НКВД чакыртабыз, башың Себер җибәрәбез, дип куркыттылар.

Кайтып керсәләр, авыл сәвитеннән җибәрелгән вәкилләр Василийларның өр-яңа келәтен сүтеп маташа. Менә бит ничек хәй-

ләкәр эшләгәннәр, берәүләре авыл сәвитендә эш кырган булып утыра, ә болары тыныч кына кеше келәтен сүтә. Сыерны инде алып киткәннәр иде.

## Шомлы төн

Җиргә караңгы төшкәч, Василий бакча башына төшеп утырды. Ана бүре бүген барыбер киләчәк. Бүре кебек адәм баласы да ярата алмас. Алар бер-берсе өчен хәтта үлемгә бара. Бу ана бүре дә үлемгә барачак, әмма ул бик хәйләкәр.

Төнге сәгать уникеләр тирәсендә урман ягында бүре улавы ишетелде. «Ана бүре, — дип уйлады Василий. — Мин сине көтәм, матурым. Ата бүре дә юксынгандыр инде үзеңне. Аның тиресе бакча башындагы колгада эленеп тора булыр».

Аучы, үзе белән алып төшкән банкага авыз тидерүгә, чыраен сытып төкереп куйды. Әче бал урынына тозлы кыяр суы алып төшкән ләбаса. Инде әчеп, гөмбәләнеп беткән. Чак кына тамак төбен кызартып алсаң, комачау итмәс иде, кәнишне. Тик кире менәргә ярамый, түзәргә кирәк. Чөнки бүре аның монда качып ятуын сизәргә мөмкин. Куллары бизгәк тоткан кешенекедәй калтырый. Махмырдан түгел инде, нервлар шулай кылана. Болай булса, бүрегә тидерә алуың да бик икеле. Ә аны ычкындырмаска иде. Зыяны дүрт сарык белән генә бетмәячәк бүренең.

Озак көтте Василий. Бүре һаман күренми. Әле яңа гына күк йөзендә йолдызлар балкый иде, хәзер энә күзедәй вак яңгыр сибәли. Үзгәрүчән бу айда һава торышы. Унберенче майда юеш булса, бөтен җәй юеш була, дигән борынгылар. Быел унберенче май яңгырлы булды. Димәк, кояшлы көнне көтмә. Алай дисәң, сынамышларга да ышана торган түгел хәзер. Космоска спутниклар очыртып, табигатьне тәмам бозып бетерделәр. Җәй — көзгә, көз җәйгә охшап кала башлады.

Җил төньяктан, бераз суытып та җибәрде. Туңып-күшегеп утырган Василийның күзенә бер шәүлә күренде. Кем булыр бу?

Шәүлә һаман якыная. Хатын-кызга охшаган. Йа Ходай, теге санинструктор кыз ич бу!

Василий, мылтыкны күтәреп, үз-үзен белешмәстән, үргә таба чаба башлады.

— У-у-у! — Тагын бүре улый.

Аучы тыны кысылып туктап калды. Артка борылып карарга җөрьәт итми. Чөнки өрәкнең күзе куркыныч. Аны күрүгә, Василий таш кебек катып кала.

— У-у-у! — Урман ягыннан түгел, ишегалдыннан ишетелә бүре улавы.

Рекс үрсәләнеп өрә, чиный, ырылдый. Чит кеше кергәндә болай кыланмый ул, өрә генә. Ә менә бүрене сизсә, капка түбәсенә генә үрмәләми.

Аяк асты пычрак, Василий дүрт аяклап диярлек сарайга кадәр менеп җитте. Аннары сарай аша, көрәк-сәнәк ише нәрсәләргә абынып-сөртенеп, лампочка белән яктыртылган ишегалдына килеп чыкты да күзләрен акайтып басып калды. Бүре Рексның бер колагын өзгән! Муен тирәсе лычма кан! Ана бүре инде юк. Шулай үч алган ул телсездән. Адәм акыллары бар үзендә. «Икенчесендә ычкына алмассың, — дип уйлады Василий, тешен шыкырдатып. — Соңгы килүең булды бу».

Бу төнне йортлардагы утлар таңга кадәр бер янып, бер сүнеп торды. Василий да йокламады, офык йөзе яктырганчы, әле өйдә, әле ишегалдында болганып йөрде.

## Беренче чирканчык

Альберт иртәнге сәгать җидедә генә кайтып керде. Әтисе йоклый иде әле, әнисе генә үз бүлмәсендә ыңгырашып ята. Ул, мыштым гына кунак бүлмәсенә узып, диванга ауды.

Каян табарга алты йөз тәңкә? Светланага тагын әҗәткә керде бит. Героины әллә ни сыйфатлы булмады, элеккеләре кебек кәеф бирми. Бүген әҗәтне кайтарып бирмәсә, аның башын кисәчәкләр. Әллә берәр фатирны басып чыгаргамы? Шәһәрдә «Вихрь-антитеррор» операциясе бара, эләктерүләре мөмкин. Ярар, башта ял итәргә кирәк. Аннары күз күрер. Ух, чәчби, бу юньсез героинны кайдан тапты икән? Мухлевать итүеме әллә?

Боргаланып ята торгач, Альбертның башына бер дигән фикер килде. Лена... Менә кемнән акча сорарга кирәк! Аның егете белән алар бер мәктәптә укыганнар иде. Исеме — Илсур. Узган ел атасы аны, утыз мең доллар түләп, университетның юридик факультетына укырга кертте. Ә ул әтрәк-әләмдә уку кайгысы юк, йөри шунда урам себеркесе кебек. Кайчан карама, Ленасы белән төнге клубта буталалар. Альберт героинны беренче тапкыр Илсур белән иснәде. Лена — әнисенең бердәнбер кызы. Чибәрлеккә чибәр үзе. Әрәм мондый кыз Илсурга. Тайгак юлга алып кереп китәчәк ул аны. Инде алып кермәгән булса. Уянгач, Леналарга кереп чыгасы булыр. Апыгасы юк, ул күрше йортта гына яши.

...Альберт кичке сәгать дүрттә генә уянды. Ашап-эчеп тормады, ничек киенгән, шулай Леналарга чыгып чапты.

Кыздан башка өйдә бер кеше дә юк иде.

— Без Илсур белән сездә очрашырга сүз куешкан идек, — диде ул алдапып.

Лена гаҗәпләнеп сорап куйды:

— Ул Йошкар-Олага китмәдемени?

— Йошкар-Олага? Ул миңа бу турыда бер сүз дә әйтмәде. Бәлки, кире уйлагандыр?

— Ярый, үзе белә торгандыр инде, — диде Лена елмаеп. — Уз, әйдә.

«Илсурның Йошкар-Олада булуы әйбәт, — дип сөенде Альберт. — Ничек кенә кызгандырырга бу кызны? Ә үзе чибәр. Прәме кәнфит! Кыска кара чәч бигрәк килешә үзенә. Күзләре — кара күмер. Аяклары да төз, фотомодель дип белерсең».

Ленаның чәчәкле кызыл халаттан булуы Альбертны хисләндереп җибәрде. Кайчан да булса менә шундый кызга өйләнәчәк ул. Башын бетермәсәләр, кәнишне. Аннары, наркоманнар сәламәт бала да ясый алмый, дип әйтәләр бит. Нәрсә тапты икән Лена үзенең колгасында? Бусы инде чын табышмак, валлаһи.

Альбертның саф кызлар белән йөргәне юк. Чөнки мәшәкате күп. Бер үбәр өчен генә кызлар озатып йөрү аны ирендерә. Булса, минутында булсын, кем әйтмешли. Шуңа күрә ул күбрәк фахишәләр янында бутала. Берничә тапкыр чир дә эләктерде инде. Әлегә Ходай сифилистан коткарып килә. Хәзер бу авырудан да курыкмыйлар инде, ВИЧ дигәннәре күпкә җитдирәк. СПИД белән күбрәк наркоманнар зарарлана, дип әйтәләр. Аның энәгә утырганы юк әле үзе. Әмма энәгә утырган наркоман кызлар белән йоклаганы бар. Кем белә, бәлки, хәзер анда да СПИД бардыр?

Мәктәптә укыганда, Альберт үзләренең классында укыган Раушания исемле кызга гашыйк иде. Җиденче класска күчкәч, кызның гаиләсе Ленино-Кокушкино авылына күчеп китте. Өч ел хат алыштылар. Бераздан багланышлар өзелде. Күпме генә язса да, Альберт җавап хаты алмады. Медицина институтына укырга кергәч, ул Кокушкинога юл тотты. Имеш, Раушанияне шаккатыра. Юл буе хыялланып барды. Ләкин барып җиткәч, аның үзен шаккатырдылар. Раушания күчеп киткән елны ук үлеп киткән икән. Аның исеменнән сеңлесе Румия хат язып яткан. Шаяртып түгел, әлбәттә. Апасын исән итеп тоясы килгән аның. Әмма ул Раушания кебек матур түгел иде. Нәрсәдер өзелде шул вакытны Альбертның күңелендә.

Лена чәй кайнаткан арада, Альберт мыштым гына фатирны карап чыкты. Әллә ни бай яшәмиләр икән.

Чәй эчәргә утыргач, егет тамак кырып сүз башлады:

— Лена, миңа акча кирәк иде.

— Минем бер тиен дә акчам юк, — диде хуҗабикә, иңнәрен сикертеп. — Булганын Илсурга бирдем. Хәзер килә, дидең бит. Әгәр бик нык кирәксә, аннан алып бирермен. Сиңа күпме кирәк?

— Мең сум. — Альбертның кәефе китте. Димәк, акча булмаячак.

— Кайчан кайтарып бирәсең?

— Бер атнадан.

— Яхшы.

— Булмаган акчаны кайтарып бирү турында сөйләшү кызык түгел инде.

— Әйттем бит, Илсур килгәч бирермен дип. Аның акчасыз йөргәне юк. Тагын чәй эчәсеңме?

— Юктыр, ахрысы. — Альберт корсагын уып куйды. — Кара-ле, Лена, миңа акча хәзер үк кирәк. Бәлки, ломбардка салып торырдай берәр нәрсәң бардыр?

Лена авызын турсайтты.

— Син нәрсә, Альберт, мине кем дип белдең?

Шул мәлне телефон шылтырады. Лена трубканы алып колагына куйды.

— Алло! Илсур, синме бу?

«Беттем, — дип уйлады Альберт кызарып. — Сизә бу минем ялганны».

Ул шундук Ленадан трубканы тартып алды. Кыз башта аптырап китте, аннары кычкыра ук башлады:

— Ты что делаешь, ненормальный?!

— Акча тап! — дип ыжылдады Альберт, Лenaның бугазына ябышып. — Хәзер үк! Юкса үтерәм!

Менә шуннан соң мәхшәр башланды. Кыз акыра, Альберт аны яңаклый. Лenaның борыныннан инде кан китте. Канны күргәч, егет тагын да мәрхәмәтсезләнде, тагын да исәрләнде. Аңа наркотик кирәк, аның бөтен сөякләре, мыскаллары сызлый! Йөз тәңкә өчен дә кеше үтерә ала ул хәзер. Тагын сукты, тагын нидер акырды.

— Юк минем акча-а-м!!!

Лена ярдәм сорап кычкыра башлагач, Альберт тезе белән аның эченә типте. Акыра, барыбер акыра. Үз башына акыра! Аның күзенә өстәлдәге кара саплы пычак чалынып китте. Пычак... Үтерергәме?

Күзен кан баскан наркоман пычак белән Лenaның корсагына кадамакчы булды. Әмма Лена читкәрәк китеп өлгерде дә тәлинкә белән аның йөзенә бәрде. Альбертның кашы ярылды, бите буйлап кан ага башлады. Калганын ул хәтерләми. Барысы уникe тапкыр кадады бугай. Соңыннан Лена, еш-еш сулап, кунак бүлмәсенә үрмәләде. Бүтән тимәде аңа Альберт, күзәтеп кенә торды.

Кунак бүлмәсендәге диванга кадәр шуышып баргач, агарынган кыз башын шунда куеп калтырана, тартыша башлады.

Биш-ун минуттан кызның йөрәге туктады. Альберт берара өнсез калды, аннары, исенә килеп, өйнең астын өскә китерә башлады. Лenaның бармагындагы алтын балдактан башка нәрсә таба алмады ул. Пычакның сабын сөлге белән сөртеп куйгач, үтерүче, ни булса да шул булыр дип, түрдә торган «Samsung» телевизорын күтәреп чыгып китте.

## Наполеон бүре була

Телсез Василийның эте белән мавыгып, ана бүре балаларына бернинди дә киек алып кайта алмады. Яшь бүреләр, ашарга сорап, һаман пыңшуларын белделәр. Үзе дә ач иде ул. Тик бу минутта аның уе бөтенләй башка нәрсә турында иде. Урманга җитәрәк,

авыл ягыннан ап-ачык итеп бүре улаганны ишетте ул. Сәер, бик сәер. Гадәттә, ул бүре исен әллә кайлардан сизеп ала. Ә бу юлы сизмәде. Шуның өстенә, җил дә авыл ягыннан исә иде бит. Каян килгән?

Аннары ул бакча башындагы колгада эленеп торган ата бүре тиресен исенә төшерде. И, бигрәк явыз бу адәмнәр. Ул телсез аучыга бу вәхшилеген беркайчан да гафу итмәячәк.

Ана бүре йокымсырап китте. Көндез нәрсә дә булса уйлап табар әле. Ерганак өстендәге имән агачында бер борындык яши, аны сагалап карарга кирәк булыр.

Чү! Тышта аяк тавышы ишетелә. Аучымы? Эттән башка эзгә төшүләре бик шикле. Ә анда эт барлыгы сизелми. Шыңшыр иде, өрер иде ул. Түземсез, куштан, мактанчык хайван бит алар.

Каяндыр тавык исе килә. Әкият! Каян килсен монда тавык ите? Борын алдаша башлады соңгы вакытта, картаю галәмәте инде.

Болай ятып булмый, чыгып карарга кирәк. Аучы булса, ана бүре аны үзе артыннан ияртәчәк. Балалары яныннан мөмкин кадәр ераккарак алып китәчәк. Аннары күз күрер.

Ана бүре акрын гына өненнән шуышып чыкты. Инде яктырган. Яңгыр һаман да сибәли әле. Читтәрәк, зур гына ташка утырган таныш адәм, борын тартып, тавык йолкып утыра. Аяк астында тагын ике тавык ята. Аңа монда нәрсә калган?

Наполеон аны күрде.

— Ә-ә, уяндыңмы, бүре? — дип көлде ул. — Мин дә ауда булып кайттым әле. Ал бер тавыкны. Икесен алсаң да була. Миңа берәү җитә. Мин дә бүре булырга уйладым әле. Чыбыклыда таңга кадәр бүре булып улап йөрдем. Бүреләр арасында бүре булуың хәерлерәк. Авылда гына түгел, бөтен илдә бүреләр законы хөкем сөрә. Кем көчлерәк, шул җиңә. Хи-хи-хи! Колхоз рәисенең өч тавыгын чәлдердем.

Менә кем бүре булып улап йөргән алайса! Биргәндә алырга кирәк. Наполеон сөйләгәндә, ана бүре, койрыгын болгый-болгый, тавыкларны берәм-берәм өненә өстерәде. Койрык болгавы рәхмәт билгесе иде.

Яшь бүреләр комсыз иде. Тавыкларны шундук ботарларга, ит белән мамык-каурыйны да аермыйча, авызга эләккәннең барысын да тончыга-тончыга йотарга керештеләр.

Ана бүре, өненнән чыгып, янә Наполеонны күзәтүдә булды. Бүредән ким түгел бу адәм, тавыкны чи килеш кенә сыпырта.

Ашап туйгач, адәм сөякләрне ана бүрегә ыргытты.

— Мә, сыйлан, — диде ул. — Анда сиңа тавык эләкмәс. Дүрт бүре баласы өчен ике тавык күп түгел. Нәрсә аптырап карап торасың? Күрдем мин синең балаларыңны. Син аларны караштыргалап тор инде, өннәреннән чыккалап йөриләр бит.

Ана бүре аннан калган сөякләрне күз ачып йомганчы йотып

куйды. Адәм баласының корсагы сөяк эшкәртми, ә бүренекендә ул сары майга әверелә.

Наполеон һаман сөйләнүендә булды:

— Бүре мин хәзер. Тиздән, бәлки, синеке кебек койрык та үсеп чыгар. Юк, үсмәс, ахры. Авыл бүреләренең койрыгы юк бит. Ил башында утырган бүреләрнең дә койрыгын күргәнем юк. Алай да алар ике аяклы бүреләр. Бүреләрнең бүреләре! Әйдә, дустым, улыйк әле бер рәхәтләнеп! У-у-у!

«Рәвешен китерә, — дип уйлады бүре. — Тик без тамак тук вакытта уламыйбыз шул. Урынны алыштырырга кирәк. Адәмнәр, бигрәк тә телсез Василий, бу төнге һөҗүмне гафу итмәячәк. Аннары монда тавык йоны да күзгә ташланыш тора. Өнне зиратта казырга кирәк булыр. Анда тынычрак. Хәзер адәм аяк басмаган җир юк. Бүген үк казырга кирәк. Ә хәзер бераз черем итеп алу мәслихәт».

### Бәрелеш

Василий Рексны урманга алмады. Бер тапкыр бүрегә җиңелгән эт ышанычлы эт түгел ул. Ишегалдында өреп, кеше кергәнчыкканны белдертеп торса гына инде.

Көн матурланып китте. Күк йөзен томалап алган соры болытлар да чигенде, кояш чыкты. Хәтта бераз бөркү дә кебек.

Иртәнге сәгать тугыз. Ана бүре ял итәдер. Урманда тирән генә бер ерганак бар. Шунда булырга тиеш аның өне. Телсез урманны биш бармагы кебек белә. Башка җирдә оя булдырырдай аулак урын юк.

Басу буйлап барганда, Василий тургайлар тавышы ишетелмәгәнгә игътибар итте. «Минераль ашлама сибәләр, — дип уйлады ул көрсенеп. — Җирне агулап бетерделәр тәки».

Василий кечкенә вакытта басуда тургайларның исәбе-хисабы юк иде. Рәшәләрдә тирбәлә-тирбәлә, үзәкләрне өзеп сайрыйлар иде. Сугышка киткәндә, аны әти-әнисе белән басуда сайрап калган тургайлар озатты инде. Кайтканда да иң беренче булып тургайлар каршы алды аны. Тургайсыз басу басу буламыни?

Урманда да киек калмады. Элек төлке белән куянның исәбе юк иде. Хәзер бер куян атар өчен көннәр буе өстерәлеп йөрергә кирәк. Бүреләр дә хәтсез күп иде. Ихластан гына әйткәндә, Василий бүре кавемен хөрмәт итә. Аның кирәклеген дә белә. Бүреләр кырыла башлагач, башка төрле киек тә кырылды бит. Табигатьтә барысы да нык уйланылган, барысы да бер җепкә бәйләнгән. Бер дигән санитарлар иде бүреләр. Ә хәзер урманга бүре кирәкми. Чөнки анда үрчердәй кыргый хайван юк. Урманда киек булмагач, алар фермаларга, көтүләргә һөҗүм итә.

«Хәйләкәр кавем, — дип уйлады телсез, башын селкеп. — Мин ана бүрене бакча башында көтеп утырам, ә ул ике метрлы

койма аша ишегалдына төшеп, Рексның колагын өзеп чыга. Әле колхоз рәисенең кетәклегенә дә кереп өлгергән. Өч тавыкны чәлдергән бит. Бүрене атсаң, премия бирәм, дигән булды. Хәер, бер председатель генә түгел, бөтен авыл пошаманда».

Бүрене үтереп кенә җан тынычлыгына ирешсәң иде ул. Җирдәге һәр фаҗиганең башында адәм баласы тора. Хәзер этләр дә кешегә охшый башлады. Чыбыклыга күчеп килгәндә, Василийның Найда исемле кечкенә йонлач эте бар иде. Якын-тирәгә бердәнбер ана эт. Бөтен ата эт Василийларның капка төбенә җыела. Найда төннәр буе унбишәр эт белән уйнаш итә. Ата этләр явыз. Рәхәтлек алып туйгач, Найданың әле бер, әле икенче җирен тешләп, кыерсыта башлыйлар. Эт кайтып керүгә күбенгәнче су эчә-эчә дә ишек катында сузылып ята. Шыңшый, сызлана, яралы урыннарын ялый. Әмма табигате үзенекен итә, берничә көн өйдән чыкмыйча яткач, ул тагын, үрсәләнә-үрсәләнә, ишекне тырмый. Чыгармыйча булмый, төне буе йокларга ирек бирмәячәк.

Найданың үҗәтлеге бик кыйммәткә төште. Василий чәчүдә чакта ата этләр башта шаярганнар, аннары, рәхәтен алып туйгач, Найданы ботарлап ук ыргытканнар. Һәркайсы, үз калҗасын читкә алып китеп, тыныч кына ашап бетергән. Койрыгын гына калдырганнар ана этнең. Гайре табигый хәл бу. Әүвәле ата эт ана эткә зыян салмый иде. Ә хәзер ул да кешегә охшап бара: башта көчли, аннан үтерә. Их, адәм баласы! Этләр чит урамнан адашып килеп кергән маэмайны шундук ботарлый башлый — һәр төркемнең үз биләмәсе. Шуның кебек, кеше дә Җир шарын инде әллә кайчан бүлгәләп бетерде. Совет иле таркалгач, «зур урам» бик күп вак «урам»нарга бүленде.

Эт дигәннән, моннан өч ел элек Василий хатыны янына — Санкт-Петербургка барырга дип юлга чыккан иде. Казан вокзалында билетка чират торганда, ул җирәнгеч бер хәлгә тап булды. Ике сукбай хатын бөтен халык каршында чүп савытын целлофан капчыкка бушаттылар да андагы сохари, ипи кисәкләрен, консерва банкаларын, тәмәке төпчекләрен иске чүпрәк сумкаларына тутырып, әллә Ельцинга, әллә Горбачевка ләгънәт яудырып, үз юллары белән китеп бардылар. Коммунистлар вакытында мондый адәмнәр, эшләмәсәләр дә, чүп савытында казынмыйлар иде бит.

Адәм баласы кайда да бертөсле. Бу юлы Василийның Санкт-Петербургтагы тимер юл вокзалында поезд көтеп торган мәле иде. Бер әби чүп савытында актарынып маташа. Шешәләрне сумкага, ипи сыныкларын кесәсенә тутыра. Шул чакны моның янында нәкъ үзе төсле, әмма бераз яшьрәк бер марҗа пәйда булды.

— Син нигә минем чүп савытында актарынасың?! — дип, тегенең чәченә ябышмакчы.

Әби кеше дә төшеп калганнардан түгел:

— Синеке әнә тегендә, бусы минеке, — дип, тырнакларын тегенең йөзенә батырды.

Менә шундый уйлар бораулады Василийның баш миен.

Урман авызына килеп җитәрәк, борынга сыер тизәге исе килеп бәрелде. Көтү көтәрдәй җәйләүләр калмагач, урманны гаришли башладылар. Кая карама — утрау-утрау чебен өере.

Эчкәрерәк кергән саен, сулыш иркенәя бара. Монда әле мал кермәгән. Кайдадыр тукран «ту-тук!» итеп, агач кайрысын тукый. Инде чәчәк койган шомырт агачлары, кура җиләкләре тирәсендә бал кортлары, кигәвеннәр безелдәшә. Адым саен пәрәвез, баш очында — озынборын болыты. Кырмыска оясының чуты юк. Бер агачтан икенче агачка кунып сайраган кошлар гына ни тора! Гомере буе урманда йөреп, Василий да аларның исемнәрен белеп бетерми. Наданлана бара адәм баласы. Белсә, шул бер-ике балык, өч-дүрт үсемлек, биш-алты кош исемен беләдер инде.

Ерганак турысына килеп җитәрәк, Василийның колагына кеше тавышы барып ирешә. Таныш тавыш. Тик искә генә төшми.

Телсез үзенең биноклен тавыш килгән якка турылады. «Бәрәч, күрше Рәшитнең тиле малае ич бу!» — дип уйлады ул, тел шартлатып. Районнан милиция эзләп килгән иде аны. Кармагышта яшәүче абыйсын чәнечкән, дип сөйләделәр. Кем беләндер сөйләшеп утыра. Әһә, ана бүре белән сөйләшә икән. Ничек курыкмый? Әллә бу тиле аны кулга ияләштергәнме? Юк, мөмкин нәрсә түгел.

Аучы, шаккатып, Наполеон белән бүрене күзәтүен дәвам итте. Әмма ул тирләгән маңгаен сөртеп алган мәлдә, ана бүре юкка чыкты. Наполеон һаман ташта утыра. Бүре Василийны берничек тә сизәргә тиеш түгел. Чөнки җил ул басып торган якка исә. Кайткач милициягә хәбәр итәсе булыр. Урманда бала-чага да йөри бит. Тиленең башына ни килмәс?

Ниһаять, Наполеон да торып басты. Ерганак өстенә менеп бара. Кайда йоклый икән соң ул? Аңлашылды, имән агачы очында икән урыны. Болай булгач, тиз эзләп табачаклар.

Василий Наполеонга күренергә теләмәде. Бүре якында гына, куркып качуы бар.

Ерганакка төшкәч, ул әле күптән түгел генә бүре утырган урынга юнәлде.

Менә аның оясы! Таш астыннан казып кергән. Эләктең, ана бүре!

Аучы, мылтыгын корып, читкәрәк барып посты. Хәзер үзәккә үткән ерткычның чыкканын гына көтәсе кала.

Озак көттермәде бүре, чыкты. Нидер сизә, тынычсызлана, җилне исни.

Телсез мылтык көпшәсен бүренең нәкъ маңгай уртасына төзәде.

Раббым! Читтәрәк санинструктор кыз басып тора! Бу юлы гимнастеркадан түгел, өстенә озын итәкле ак күлмәк кигән. Озын сары чәч толымнарын җил уйната. Каты җил кузгала башлады шул, ерганак астындагы каеннар да сыгылып-сыгылып куя.

Кыз инде Василийга кул изи — үзе янына чакыра. Бүре онытылды. Ул анда юк та бугай инде.

— Ардым мин синнән, кызый, — дип мыгырдады аучы, мылтык көшәсен аңа турылап. — Күпме гафу үтенергә була синнән?! Яшәвем яшәү, ашавым ашау түгел синең аркада! Йә син, йә мин!

Мылтык гөрст итеп атыш җибәргәч, урман селкенеп куйды.

Кыз инде юк. Әмма артта җан өшеткеч ырылдау тавышы ишетелә. Бүре!

Борылуын борылып өлгерде Василий, әмма ул икенче тапкыр үтерергә теләгән зур ямь-яшел күзле санинструктор кыз, кылыч тешләрен ыржайтып, аның бугазына сикерде.

## Һәркемнең үз юлы

Көн кичкә авышкан иде. Кара канга баткан Василийны күтәртелгән юлга чыгарып салгач, Наполеон, хәлдән таеп, җиргә утырды.

— Яшисең болай булгач, Василий дәдәй, — диде ул, тилеләрчә елмаеп. — Бүреләргә бүтән тимә. Яхшы ерткычлар алар. Бездән яхшырак ерткычлар, аңладыңмы? Үтерәсе килсә, үтерә иде ул сине. Ләкин үтермәде, юләр. Ә син аны барыбер кайчан да булса үтерәчәксең, шулай бит? Син үтермәсәң, башкалар үтерәчәк. Үтерүчеләр без барыбыз да, үтерүчеләр.

— Мин кайда? — Василийның да күзләре акылсыз иде.

— Кайда булсын инде, юлда, кәнишне. Кешеләр һәрвакыт юлда. Юллары гына төрле була. Аларның кая барганнарын бер Алла гына белә.

— Су... су биреге-ез!

— Үземнең дә бик эчәсем килә, юк бит су.

— Кем син? — Василий, чыннан да, аны танырлык хәлдә түгел иде.

— Наполеон булам мин, Василий дәдәй.

— Наполеон? Нинди Наполеон?

Тиле бот чабып көләргә тотынды.

— Карале, Василий дәдәй, син элек телсез түгел идеңме?

Дөрестән дә, телсез Василийның теле ачылган иде. Тик бу могҗиза инде сөендермәс, чөнки акылы җиңеләйгән иде аның.

— Сау бул, Василий дәдәй! Мин үз юлымда, син үз юлыңда. Мылтыгыңны кочаклап ят, алып китмәсеннәр.

Шулай диде дә Наполеон басу буйлап урманга элдертте.

## Күченү

Тиле егет Василийны өстерәп алып китүгә, ана бүре яшь бүреләр белән урманның эчкәрерәк бер җирендә качып ятарга булды. Аннары алар зиратка юл тотачаклар.

Көнне яшен сугып еккан нарат агачы янында уздырдылар. Яшь бүреләр берни булмагандай мәтәлчек ата-ата уйнады. Ә ана бүре аларны читтән генә күзәтеп ятты.

...Ниһаять, төн. Күктә бихисап йолдызлар балкый. Бәхеткә, ай чыкмаган әле. Күтәртелгән таш юл аша исән-сау чыксалар, барысы да тәртип булачак. Яшь бүреләр әле сыек, тормыш тәҗрибәсе дә җитеп бетми. Шуңа күрә аларга өчләтә абай булу сорала. Машина фарасыннан курка ана бүре. Заманында ул үзе дә машина юлында харап була язган иде. Чөнки аны кояш яктысы дип уйлады. Әнисе өстерәмәгән булса, сытып китәләр иде үзен.

Башта барысы да ана бүре теләгәнчә барды. Куе әрәмәлекләр буйлап элдерттеләр. Күтәртелгән юлга килеп чыккач кына ялгыша яздылар. Урман ягындагы кискен борылышта бер машина пәйда булуга, юл уртасында калган яшь бүреләр, фара яктысына гаҗәпләнеп, хәрәкәтсез калдылар. Ана бүре, ырылдый-ырылдый, аларны борыны белән юлның икенче ягына төртеп төшерә башлады. Дүртенчесе куркаграк булдымы, бөтенләй кире якка титаклады.

Аның белән юлның бер читеннән икенче читенә йөгереп йөри торгач, җиңел машина, тормозларын сызгыртып, нәкъ борын төбендә килеп туктады. Ана бүре, муен йоннарын кабартып, кылыч төсле үткен, очлы тешләрен ыржайтты да таштай катып калды. Хәзер ул фара яктысында уч төбендәге кебек. Мылтыклары булса, качып котылу икеле. Яшь бүреләр ераккарак китеп өлгергәнче, игътибарны үзенә юнәлтергә кирәк. Бәхеткә, аның белән басып калган бүре дә, һушына килеп, шул якка элдертте.

Машинадагылар шаулаша башлады. Курыктылар. Шофер кинәт газга басып, ана бүре өстенә ыжгыртты. Ахмак! Алай гына бүрене сытып буламыни? Бүре тотам дип, машинаң белән юл читенә тәгәри күрмә!

Бүре бер сикерүдә юл читендәге әрәмәлек арасына кереп югалды. Моны күреп, кызып киткән шофер машинаны шул якка таба бастырып куйды да машинадагыларның берсенә кычкырды:

— Рәмис, тизрәк мылтыкны китер! Бүре атабыз хәзер!

Машинада хатын-кызлар да бар иде, чәрелди үк башладылар:

— Бүре, чын бүре иде, кызлар!

— Әччәч! Аллам сакласын!

— Нигә чыктылар? Ботарлый бит бүре!

Ирләр әрәмәлек арасына кереп сеңгән бүрене күпме генә күзләсәләр дә, абайлый алмадылар.

Ә бу вакытта яшь бүреләр инде зиратка якынлашып бара иде.

### Василий дәдәй аңына килә

Василий район үзәк хастаханәсендә генә һушына килде. Тик ул үзенең ничек шушы хәлдә калуын һич кенә дә исенә төшерә алмады. Амнезия — табиблар куйган диагноз шундый. Шунысы

кызык, саташып ятканда, ул никтер гел Франция императоры Наполеон Бонапарт исемен кычкырып яткан. Ә иң мөһиме, теле ачылган. Менә бусы инде чын могҗиза! Бу хәбәрне ишетеп, бөтен авыл шаккаткан.

Милициягә Наполеон исемен ишетү җитә калды. Кармагышта абыйсын сәнәк белән чәнечкән Айматов булырга тиеш ул.

...Икенче көнне урманны Эчке эшләр министрлыгы гаскәре чорнап алды. Эт тә бирергә тиешләр иде, ни сәбәпледер, министр моны кирәк дип санамады.

Боҗра кысылганнан-кысыла барды. Җинаятьче монда булса, аның кулдан ычкына алуы икеле.

...Ерганак янына җитәрәк, өлкән лейтенант Смирнов пышылдап кына рядовой Әхмәтовка сүз катты:

— Әхмәтов!

— Тыңлыйм, иптәш өлкән лейтенант!

— Күрәсеңме әнә теге биек имәнне?

— Ие.

— Бүтән бернәрсә дә күрмисеңме?

— Юк.

— У, күзле бүкән, яхшылап кара!

— Күрдем, иптәш өлкән лейтенант! Күрдем!

— Нишлибез?

— Соң, куян түгел бит, кача алмас. Агач башыннан төшерәбез дә...

— Әгәр төшәргә теләмәсә?

— Төшмәсә, сугып төшерәбез, иптәш өлкән лейтенант.

— Молодец! Киттек!

Тиле аларны күрде. Агач башыннан кычкыра:

— Сез кем?

Өлкән лейтенант черт итеп җиргә төкерде.

— Филипп икенче, атаң башы. Төш, әйдә!

Теге кычкырып көлеп җибәрде.

— Ә мин Наполеон!

Хәрбиләр, аптырап, бер-берсенә карашып куйдылар.

— Во дает! — диде өлкән лейтенант, күзләрен акайтып. — Шаярткан була бит әле. Төш кенә, дуңгызыңны төябез хәзер!

Наполеон төшмәде. Бу башкисәрләр кулына эләксә, аны Изге Елена утравына да озатып азапланмаячаклар. Их, ана бүре монда булса, күрсәтер иде ул аларга күрмешләрен! Монда озак утырырга ярамый. Башкалары да килеп җитсә, эшләр харап.

— Э-эх! — Әзмәвер Наполеон өлкән лейтенант өстенә сикереп төште дә, аягы белән рядовой Әхмәтовның танавына тибеп, куаклыклар арасына чумды.

— Стой!

Шундук берничә автомат очереде яңгырады.

Куаклыклар арасыннан шатыр чапкан Наполеон башта арка-

сын өтеп алган ядрәгә игътибар итмәде. Нәрсәдер чеметеп кенә куйган кебек булды. Әмма бераздан, тыны кысылып, җиргә ауды. Аркасы тулы лычма кан иде аның.

— Улым!

Наполеон күзләрен ачты. Аның каршында элеккечә ак кәфенгә төренгән әнисе басып тора.

— Әни!

Мәрхүмә аңа кул изи, үзе белән китәргә чакыра. Егет аякка басты, чайкала-чайкала, әнисе артыннан иярде.

Зират... Нарат, каенише агачларга караганда тупыллар күбрәк үсә монда. Дымлы яфрак исе килә. Кояш яктысы төшми диярлек. Тирә-юньдә каргалар каркылдый. Моңсу, шомлы, сагышлы урын бу.

Наполеон, аңына килеп, әнисе кабере янына шуышты. Кабергә чардуган куелмаган иде әле. Өстендә яшь кенә балан агачы үсеп утыра. Кем утырткан? Әтиседер инде.

— Нигә тормыш шундый ачы, әнием?! — дип ыңгырашты Наполеон, кабергә башын куеп. — Бу балан да ачы, тормышның үзе кебек ачы ул. Бәлки, безнең тормыш шушы балан ачы булганга шундыйдыр? Борчылма, әнием, хәзер мин бөтен кешелек дөньясын бәхетле итәм. Мин бу ачы тормыш агачын синең кабереңнән тамыры белән йолкып алам!

Егет, әҗәл көчен җыеп, бармаклары белән балан агачы тамырын актарырга тотынды. Бармаклары канап бетте, тырнаклары төште, әмма ул казыды да казыды. Ә соңыннан, әнисе кабереннән ачы тормыш агачын йолкып ала алмаячагын аңлап, әкрен генә җан бирде.

## Фатирыңны алыштыр, әти!

Әлфияне август аенда җирләделәр. Баязит бу кайгыны авыр кичерсә дә, еламады. Еласы еланган инде, ә тормыш дәвам итә. Мәрхүмәнең өчесен, җидесен, кырыгын үткәрергә Кадрия булышты. Әлфия теләгәнчә, мәчеткә барып, никах укыттылар. Әмма әлегә һәркайсы үз фатирында яшәп тора дип килештеләр. Чөнки янда Альберт барында алар тынычлык күрмәячәк. Аннары Кадриянең дә буйга җиткән малае бар иде.

Башта Баязит фатирны сату турында уйлап та карамады. Хатыны белән гомер иткән фатир бит. Монда, кем әйтмешли, күгәргән кадак та сагыш уята. Альберт: «Тиздән мин өйләнәм, фатирны алыштыр», — дип тавыш куптара башлагач кына, бу эшкә алынды ул. Үзе мәшәкатьләнмәде, шушы эш белән шөгыльләнә торган бер фирма конторасына кереп гариза язды да ике атна эчендә фатирны алыштырып бирделәр. Альбертка да, Баязитка да бер бүлмәле фатир тиде. Малайның кыланышлары Баязитны чыгырыннан чыгарды. Аның яшисе килми иде. Шуңа күрә үзенә тәкъдим ител-

гән фатирны да барып карамады, кайгыдан айнымыйча эчеп ятты. Алай да яңа фатир яхшы урында, икенче катта булып чыкты. Һава саф, транспорт аз йөри. Кадрия белән шунда сөенеп кенә яшисе дә бит, Альберт аны монда да тынычлыкта калдырмады. Көн аралаш килеп акча сорый, тавыш куптара. Кадрия әйтмәсә, аның бер бүлмәле фатирын сатып җилгә очырганын да белмичә кала иде Баязит.

Шулай итеп, әти кеше бала кайгысыннан тәмам эчүгә сабышты. Көн белән төн, төн белән көн бутала башлады. Ул арада фатирга шикле ирләр һәм хатыннар ияләште. Дөресрәге, сукбайлар иде алар. Озын сүзнең кыскасы, кем шакыса, шуңа ишек ачты Баязит. Кадрия шәһәрдә булса, моңа юл куймас иде, әлбәттә. Ул авылга авыру әтисен карарга кайтып киткән иде.

Бер төнне, ул исереп йоклап ятканда, кемнәрдер фатирдагы бөтен җиһазны ташып бетергәннәр. Милициягә бармады Баязит. «Дөнья бетә икән, бетсен!» — дип, барысына да кул гына селтәде.

## Чакырылмаган кунаклар

...Бер атна чамасы туган авылында булганнан соң, Кадрия, ашкынып, Казанга кайтты. Баязитны үлеп сагынган иде ул.

Менә икенче кат, менә ишек. Чү! Нигә ул ачык? Йозакны ватканнар бит!

Әллә нинди уйлар узды шулчак Кадриянең башыннан. Ул туфлиен салып, бармак очларына баса-баса гына эчкә узды. Ашханә бүлмәсенә башын тыгып карарса, ыспай гына киенгән бер бәндә инде болай да чайкалып утырган Баязитның авызына аракы коя.

— Кул куй, дим мин сиңа, әтрәк-әләм! Юкса үзеңнең дә, малаеңның да башына җитәбез. Әҗәтне вакытында түләргә кирәк, папаша!

Кадрияне күргәч, чакырылмаган кунак каушап калмады, дорфа гына сорап куйды:

— Ты кто?

Кадрия бер агарынып, бер күгәреп ачу белән җавап бирде:

— Мин аның хатыны. Ә менә сез кем?

— Хатыны? — Ир ыржаеп көлеп куйды. — Алдашасың. Аның хатыны үлде инде.

— Чыгып китегез! Юкса хәзер милиция чакырам!

Әзмәвер күзләрен акайтып өскә үк килә башлады.

— Аh син, фахишә!

Кадрия урамга чыгып йөгерде. Урамда чат саен таксофон, әмма берсе дә эшләми. Аптырагач, ул якындагы почтага чапты. Анда телефон тәгаен булырга тиеш.

Милиция машинасы килеп җиткәнче, урамда басып торды ул. Хәзер адәм баласына ышаныч юк, үтерәләр дә китәләр.

Алар килеп кергәндә, чакырылмаган кунактан җилләр искән

иде. Ә Баязитка ике дөнья бер моржа, йөзе белән капланган килеш өстәлдә йоклап ята. Яшь кенә лейтенант протокол төзеде, сораулар бирде. Кадрия бернәрсә дә әйтә алмады, аларга бары тик Баязит кына җавап бирә ала. Ә ул сөйләшү генә түгел, утырып та тора алмый. Аптырагач, лейтенант үзенең телефон номерын биреп калдырды, иртәгесен шылтыратырга кушты.

Ул көнне Кадрия ишеккә кухня шкафын терәп йоклады. Йокы кермәде инде аңа, әллә ниләр уйлап бетерде. Берара мәрхүм ирен дә искә төшереп куйды. Матур гына яшәп ятканда, йөрәге туктап китеп барды, бәгырь. Юкса йөрәк авырта дип бер дә зарланганы булмады.

Авыллары янәшә генә иде аларның. Кадрия — Бөреледән, Борис — Владимирдан. Керәшен егете иде аның ире. Качып кына иске тегермән янында очрашалар иде. Анысы да бик сирәк кенә. Сугыштан соңгы авыр еллар иде шул, хәзерге яшьләр кебек озаклап биләмдә йөри алмадылар. Кадрия иртүк фермага барып сыерын да сауды, ындырда да торды, уракка да төште, — кыскасы, эшләмәгән эше калмады инде. Авыл җирендә берни дә яшереп булмый, белделәр Кадриянең керәшен егете белән йөргәнен. Бабасы бик дини иде, саклап торып, тегермән тирәли икесен дә сәнәк белән куып йөрде. Моны авылда әле дә кызык итеп сөйлиләр. Алай да Борис үҗәт булды. Кич җитте исә килеп әкрен генә тәрәзә чиртә. Өйдәгеләрнең берәресе торып йөри башласа, шундук куаклыклар арасына чума. Кайвакыт таңга кадәр утыралар иде. Аннары Кадрия, йоклап та тормыйча, әнисе белән фермага чаба.

Соңыннан керәшен егете армиягә китте. Берсеннән-берсе җылы хатлар язды ул Кадриягә. Конвертның тышына исемен Барый дип куя иде.

Армиядән кайткач, Барый яңа исемен паспортка теркәтеп куйды. Өйләнештеләр. Ире Казан елга техникумында, Кадрия аш-су пешерүчеләр әзерләүче һөнәри мәктәптә укыды.

Әйе, еллар авыр булса да, яшьлегенә зарланмый Кадрия. Яратышып яшәделәр шул Барый белән. Кайбер ирләр кебек чит-ят хатыннар янына йөрмәде ул, эштән соң гел өйдә булды. Кино, концерт, театр ише нәрсәләргә дә еш йөреп тордылар. Кибеттән азык-төлекне дә үзе ташый иде.

Яши-яши фатирлы да булып киттеләр. Әмма Кадрия һаман балага уза алмады. Хастаханәгә нянька булып эшкә урнашуы да шуның аркасында килеп чыкты инде. Табибларга якынрак булырга теләде. Кырыкмаса-кырык тапкыр тикшеренде, әллә нинди кыйммәтле дарулар эчте, ә бала һаман юк та юк. Кырык яшен тутырганда, ана булу бәхетеннән тәмам өмет өзгән иде ул. Һәм менә, Ходайның рәхмәте, көннәрдән бер көнне балага узды да куйды. Барый түземле булмаса, гел юатып тормаса, мондый бәхеткә ирешә алыр иде микән ул? Азмыни бала булмау аркасында таркалган гаиләләр.

Барый үзен чын татар кешесе итеп саный иде. Керәшен дигән сүзне бер дә кабул итмәде. Шуңа күрә дә балага Кәбир дип исем куштырды. Бу вакытта ул «Казан» теплоходында штурман булып эшли иде. Бала тугач, Барый озак яшәмәде, телевизор караган җирендә йөрәге тотып үлде.

Киндерледә бакча сатып алгач, Кадрия Әлфия белән танышты. Шуннан бирле гел дус булдылар, бер-берсенә кунакка йөрештеләр.

Бервакыт ул аларга ниндидер йомыш белән керде. Баязит үзе генә иде. Кыстый-кыстый чәй эчертте. Аннары искәрмәстән генә Кадрияне ирененнән үбеп алды. Кадрия моны көтмәгән иде, сикереп торып, Баязитның яңагына китереп сукты да йөгереп чыгып китте.

Бик озак сөйләшмичә йөрделәр. Шуннан соң, кирәк бит, көн дә Баязитны уйлап йөри башлады Кадрия. Аның куе кара кашлары, юка матур иреннәре гел күз алдында торды. Әмма кайчан да булса Баязитка кияүгә чыгам дип һич тә уйламаган иде ул. Батыр хатын иде шул Әлфия. Үлем түшәгендә ятып та ире турында уйлады. Мин үлгәч, Кадриягә өйлән, дигән бит. Кадрия үлсә дә болай булдыра алмас иде.

...Икенче көнне Баязит Кадрия биргән акчага йозак белән пилмән алып керде. Сүзсез генә утырып ашады, шактый вакыт ишеккә йозак куеп азапланды. Маңгаеннан шабыр тир ага үзенең. Хәлсезлек билгесе инде. Коры-сары белән генә тукланып озак эчеп булмый. Эчүдән йөзе зәңгәрләнә башлаган инде. Өс киеме дә вокзал сукбаеныкы төсле. Ак күлмәгендә ике генә сәдәфе эленеп тора. Чалбарын инде әйткән дә юк, кайдадыр күмер бушатып йөргән дип уйларсың.

— Баязит, нинди кеше иде ул? — дип сорады Кадрия, ниһаять, телгә килеп.

Махмырдан башы чатнаган Баязит читкә карап кына җавап бирде:

— Бер мафиози инде шунда. Альбертның әҗәтен даулап килгән. Миндә андый акча юк, шул фатирны биреп кенә котылсаң инде.

Кадрия елап җибәрде.

— И Аллам, бу Альберт сине иртәме-соңмы кабергә кертәчәк!

— Беләм. Фатирны сатарга да тизрәк авылга ычкынырга кирәк, — диде Баязит, калтырый башлаган өске иренен бермәл тешләп торгач. — Син, теге ни, милициягә барып йөрмә инде, мәшәкате күп булачак.

— Тик кара аны, бүгеннән башлап, син бу фатирга аяк та басмыйсың. Авылга күченгәнчегә кадәр миндә яшибез.

Баязит чыраен сытып әйтеп куйды:

— Әлфия мине гафу итәр инде, соңга калганбыз без Альберт мәсьәләсендә.

Шул ук көнне ул элек үзе эш иткән фирмага барып янә гариза

язды. Алыш-биреш бу юлы да тиз хәл ителде. Акчаны долларга алыштырдылар. Баязит икенче көнне үк әнисе янына — Чыбыклыга кайтып китте.

## А, мани, мани!

Сентябрьнең ачалак-йомалак бер көне иде. Альберт көндезге сәгать унда Җиңү проспектындагы базарга юнәлде. Анда Кендек кушаматлы егет белән очрашырга тиеш ул. Алар фатир басачаклар. Фатир хуҗасы шушы базарда Төркиядән кайтартылган күн курткалар белән сату итүче утыз-утыз биш яшьләрдәге хатын. Ирдән аерылган, алты яшьлек кызы бар. Ул хәзер базарда, кызы балалар бакчасында булырга тиеш.

Кендек һәм аның сеңлесе Света белән Межлаук урамындагы притонда танышты ул. Светаның улы кеше үтергән өчен Түбән Кама төрмәсендә утыра. Хатын гәүдәгә матур булса да, йөзе инде шактый таушалган. Сүгенгәндә ирләр кебек сүгенә. Үзенең бөтен җитешсезлеген косметика белән генә каплап йөртә. Кемнәр генә булмый аның фатирында! Караклар, фәхеш хатыннар, лесбиянкалар, күтләкләр... Аларның күбесе героин исни, анаша тарта. Светада бушлай күңел ачып ятмыйлар, әлбәттә. Әйбәт түлиләр. Төнге клубта кассир булып эшләп, акчаны болай да аз алмый ул. Альберт аңа муеннан әҗәттә. Хәзер кәефләнү өчен, ул бер көнгә кимендә мең тәңкәлек әфьюн иснәргә тиеш. Шуңа күрә атасының фатирын да закладка салды инде. Үзенеке инде күптән җилгә очты. Кендек — Светаның сөяркәсе. Ул Альбертка атасының фатирын башка кеше исеменә күчерергә бер атна вакыт бирде. Бу барып чыкмаса, көт тә тор, Альберт теге дөньяда булачак. Кендекне инде күптән милиция эзли. Узган ел Кызыл урамындагы бер йортны басканда, ул глушительле пистолет белән дүрт кешелек гаиләне манчып чыккан иде. Күзендә иман нуры юк Кендекнең. Ачуын чыгарсаң, ике дә уйламыйча муенга пычак салачак. Шул мәҗбүр итте инде аны этисенең фатирындагы җиһазларны урларга. Бәхеткә, этисе нык исерек иде, уянмады.

Ленаның әнисе ни хәлдә икән? Бердәнбер кызы бит. Илсурны да күптән очратканы юк. Ментлар допроска чакырып интектереп бетергәннәрдер инде. Бер күрәсе булыр әле үзен.

Ашыкты теге вакытта Альберт. Телевизорны таксистка мең тәңкәгә сатып җибәрде бит, юләр. Ә ул каян алдың дип тә сорамады. Урланганын белә торып алды инде. Шул көннән бирле Альбертның юньле йокы күргәне юк. Әллә нинди куркыныч төшләр күрә.

Сәгать унда очрашырга сүз куешсалар да, Кендек күренмәде. Сүздә тора торган бәндә түгел. Ә менә башкалар сүздә тормаса, бугазын чәйни. Альберт үзе генә дә баса алыр иде ул фатирны, адресын белми. Инде ни эшләргә? Аңа тагын героин кирәк. Светага баш иеп килергәме? Башка чара юк, тагын берәр

сәгать иснәмичә торса, ул тәмам сыгылып төшәчәк. Ломка начар нәрсә.

Трамвайдан төшеп, Межлаук урамына килеп җиткәч, Альберт биш катлы йортның беренче подъезды каршында милиция машинасы торганын күрде. Ул да булмады, подъездтан иңнәренә автомат аскан берничә ОМОН һәм кулларына тимер беләзекләр кидерелгән ике хатын-кыз белән өч ир-ат килеп чыкты. Хатын-кызларның берсе Света иде. Альберт әле кичә генә алар белән йөзе кара көеп чыкканчы анаша тартып ятты бит, хатыннар төне буе бер кулдан икенче кулга күчеп йөрде. Ә хәзер шайтан туе тәмам. Биш-алты елдан соң гына дәвам итсәләр инде. Кемдер тишкән, күрәсең. Ярый әле иртәрәк чыгып сызган, юкса аны да таш капчыкка китереп тыгасылары булган.

«Кая барырга? — дип уйлады Альберт. — Әллә Илсурларга китәргә инде? Иң башта таксофоннан шылтыратып алырга кирәк».

Якындагы почтадан таксокарта сатып алгач, ул трамвай тукталышы янындагы таксофонга юнәлде.

Трубканы Илсур үзе алды.

— Сәлам! — диде Альберт, тавышын калынайта төшеп. Блатной булып күренергә тырышуы инде. — Бу мин — Альберт. Күптән очрашкан юк, старик, ничек хәлләр?

— Начар, — дип ишетелде трубкадан. — Ленаны үтерделәр.

— Ленаны?.. Менә сиңа мә!.. Кем үтерде?

— Шайтан белгән аны. Прокуратурага чакыртып интектереп бетерделәр инде.

— Кая күмдегез?

— Мин аны күмәргә бармадым.

— Бармадың?.. Начар, бик начар. Егетлек түгел бу. Ә әтиәниең?

— Алар да бармады. Валя апа тикшерүчегә мине юридик факультетка утыз мең доллар түләп керткәннәре турында сөйләп биргән.

— Анысы нигә тагын?

— Ачудан инде. Ленаның үлемен миннән күрә. Экспертиза вакытында аның каныннан морфий тапканнар.

— Шуннан?

— Мине өч көн КПЗда ябып тоттылар. Ул көнне үзем дә иснәгән идем. Кан анализы алдылар. Бу турыда белгәч, Валя апа бөтен белгәнен чыгарган да салган инде. Шуннан соң без аңа ярдәм итәргә тиешме?

— Бик дөрес эшләгән Валя апа. Ленага син иснәттең бит инде беренче тапкыр әфьюнне. Мин аның урынында булсам...

— Әйдә, туктатыйк бу сөйләшүне, җанда болай да мәчеләр тырмаша.

— Синең җанда мәчеләр тырмаша, ә минекендә… — Альберт төчкереп үк куйды. — Кыскасы, сиңа бер йомыш бар, Илсур.

Мең тәңкә биреп тора алмассыңмы миңа? Киләсе атнада кайтарып бирер идем.

— Иснисең килә инде синең.

— Молодец, аңлыйсың икән хәлемне. Рыбак рыбака видит издалека!

— Акча юк. Шулай да бер дорожка биреп тора алам.

Альбертның күңеле күтәрелеп китте.

— Менә бусы егетләрчә! Кайчан килим?

— Өйгә килмә. Әти белән әни болай да тикшереп кенә торалар. Тукай һәйкәле янында очрашырбыз.

— Лады.

«Йонлы колак, — дип уйлады Альберт, телефон трубкасын элеп. — Ике ел кияү булып йөрде йөрде дә... Бу колганың әнисе операциягә яткач, Лена атна буе хастаханәдән чыкмады. Алма агачыннан ерак төшми икән. Их, Лена, Лена... Үтерергә теләмәгән идем бит мин сине. Шулай килеп чыкты инде. Ломка вакытында газиз атамны да суярга әзер мин».

Илсур билгеләнгән урынга вакытында килеп җитте. Тукай скверындагы эскәмиядә сөйләшеп утырдылар.

Колга үзен университеттан сөрүләре, Ленаны беркайчан да яратмаганлыгы турында сөйләде. Әфьюн белән сату итүдә аны компаньон буларак кына файдаланган икән. Лыгырдаган саен, кәкре борыныннан әллә маңка, әллә су агып чыга. Шуңа күрә, лышыклышык килеп, гел борын тартып утыруда булды. Ярата бит шундыйларны кызлар!

Аның белән аерылышкач, Альберт ак порошокны, кул аркасына салып, иснәргә керешге. Менә ул кая дөнья рәхәте! Аның тагын яшисе килә! Ләкин бу рәхәтлек озакка бармаячак. Өч-дүрт сәгатьтән героинның тәэсире бетә башлый. Тагын акча эзләргә кирәк булачак. А, мани, мани! Кая барырга?

Баш вата торгач, ул әтисе янына барып кайтырга булды.

...Ишекне юан гына марҗа хатыны ачты. Еш-еш сулый, астматик, ахры. Фатир эченнән әллә дару, әллә сидек исе килә. Телевизордан бу кварталда кайбер урамнарда су булмаячак дип игълан иткәннәр иде.

— Что нужно, молодой человек? — дип сорады марҗа.

— Әти кирәк иде, — диде Альберт. Аннары эчтән генә хихылдап куйды: «Ну дает әти! Кадрия апа гына җитми икән моңа».

— Нинди әти? — Марҗа берни аңламагандай авызын кыйшатты.

— Ничек инде нинди әти? Баязит Сәүбәнович, конечно!

— Ә-ә, сез аны әйтәсез икән, — дип елмайды хуҗабикә. — Ул хәзер монда яшәми.

Альбертның ачудан күзләре чекерәйде.

— Ничек инде яшәми?

— Очень просто. Бу фатирда хәзер без яшибез.

— Альштырган, димәк?
— Юк, фатирны без сатып алдык.
Альбертның башына күсәк белән суккандай булды. Кендек бу турыда белсә, башын өзәчәк аның. Ул хәзер ничек тә булса әтисен эзләп табарга тиеш. Фатир акчасын кайда яшереп саклый икән? Кадрия апаларда инде. У-у, җен карчыгы, әтигә тәмам хуҗа булып беткән икән.
Ул юл буе план корып барды. Бәлки, әти мине Совет мәйданында көтә, акчаны алып килергә кушты, дип алдаргадыр? Алай дисәң, ул кая барырга җыена, нигә үзе килмәде, дип шикләнә башлаячак Кадрия апасы. Куркытам дисәң дә, куркып кала торганнардан түгел ул. Ә әтисе шунда булса? Мине үтерергә җыеналар, акча кирәк дип мескенләнергәме? Кызганмаячак аны әтисе. Теге вакытта эт итеп кыйнап киткәне өчен генә дә куып чыгарачак. Ярый, барып җиткәч, күз күрер.

## Альбертны тагын җен бутады

...Кадриянең улы Кәбир генә өйдә булып чыкты. Альберт бу егетне мәрхүмә әнисе аша гына ишетеп белә иде. Бакча күршеләре булсалар да, йөзгә-йөз очрашканнары юк. Хәтере ялгышмаса, Кәбирне авиация техникумында укый дип ишеткән иде. Тач әнисе! Шундый ук ачык төстәге чәч, яшел күзләр, биек маңгай. Ир бала әни кешегә охшый дигәннәре дөрес икән. Кайвакыт, көзгегә карагач, Альберт та әнисен күргәндәй булып китә.
— Сәлам! — диде Альберт, Кәбиргә кул биреп. — Син мине белмисеңдер инде?
— Юк, — дип җавап бирде егет.
— Баязит абыеңның улы булам мин.
— Ә-ә... Ишеткәнем бар. Нәрсә кирәк? — Кәбирнең бу сүзләрендә ниндидер шик, ачу сизелгәндәй булып китте. Әнисе берәр нәрсә такылдагандыр инде.
— Кадрия апа кайда?
— Ул эштә.
— Кайчан кайта?
— Бүген төнгедә ул.
— Нәрсә, шулай ишек катында басып торабызмы инде?
— Гафу ит, мин чыгып китәргә әзерләнгән идем.
Альбертның җене кузгалды. Бик теләп кабул итмәделәр аны.
— Мине әти җибәргән иде, — диде ул, күзен дә йоммыйча. — Кадрия ападан фатир акчасын алырга кушты.
Егет иңнәрен селкетте.
— Мин бернинди акча турында да белмим. Әни кайткач, үзеннән сорарсың.
— Безнең вакыт юк, — дип ыжылдады Альберт. — Әти көтеп тора. Бар, шкафларыңны, матрас асларыңны кара!

— Син миңа актарынырга кушасыңмы? Мин әнидән башка бернәрсәгә дә кагылмыйм. Иртәгә килерсең.

Кәбир ишекне япмакчы булды, ләкин Альберт шундук аягын тыкты да ачулы тавыш белән әйтте:

— Әйттем бит мин сиңа, эзлә дип!

— Өеңә кайтып командовать ит, ә монда мин хуҗа! Аңладыңмы?!

— Нәрсә? Син миңамы?! — Күзләре шар булып кабара башлаган Альберт йодрыгы белән Кәбирнең яңагына китереп сукты.

Теге дә карап тормады, их итеп, башмаклы аягы белән Альбертның касыгына менеп төште.

Шуннан соң китте дә китте инде. Бәргәләшә-бәргәләшә, башта прихожийда, аннары кухняда әүмәкләштеләр. Чандыр гына булса да, Кәбир хәлле егет иде. Ул инде аны арттан, муеныннан каерып маташа. Тик Альбертта ерткычлык зуррак. Җиңелә башлаганын сизгәч, аның башына өстәлдә торган чуен кәстрүл белән кундырды. Шәп кундырды! Ыңгырашырга да өлгермәде Кәбир, күзләрен кылыйландырып, киселгән агач кебек гөрселдәп идәнгә ауды.

Егетнең башыннан агып чыккан кан күлләвегенең зурайганнан-зурая барганын күргәч, Альберт, чыраен сытып, мыгырдап куйды:

— Черт!.. Черт!!!

Буласы инде булган. Монда озак калырга ярамый. Хәзер үк бөтен җирне актарып чыгарга кирәк. Тик иң башта бу әтрәк-әләмнең башына целлофан капчык киертеп куярга кирәк иде. Для страховки, кем әйтмешли.

Альберт ыңгыраша башлаган Кәбирнең башына целлофан капчык киертергә дип иелде. «Болай да гаргарәгә килергә тора ич, — дип уйлады ул хихылдап. — Ятсын шунда».

Фатирның астын өскә китереп бетерде Альберт. Ә акча беркайда да юк. Димәк, ул башка җирдә саклана. Әтисе ул уйлаганча ук юләр түгел икән.

Шактый күп эз калдырды Альберт. Кул белән тотынган, кагылган бар нәрсәне дә чүпрәк белән сөртеп бетерү мөмкин түгел. Инде бер генә чара кала, ул да булса, ут төртү!

## Хәерниса карчык улын көтә

Туксан яшьлек Хәерниса карчык әле яз башында гына арулталуның нәрсә икәнен белми иде. Кояш баеганда йокларга ята, кояш чыкканда йокыдан уяна. Бер дә тик тормады, бер карасаң, бакчада, икенче карасаң, каз-үрдәк бәбиләре янында мәш килә. Чишмәдән суны да үзе ташыды. Бервакыт мәктәптән тимурчылар командасы килгән иде, ярдәм итәргә теләвегез өчен зур рәхмәт, балакайлар, хәзергә барысына да үземнең көч җитә, дип, кире борып җибәрде.

Телевизорга да күнегә алмады Хәерниса карчык. Моннан өч еллар элек улы Баязит алып кайткан иде аны. Тәки карамады. Ята шунда тузан җыеп. Үзе затлы күренә, ерактан кабыза-сүндерә торган хикмәтле нәмәрсәсе дә бар. Дөрес, кабызган чаклары булды, ләкин экранда берничә тапкыр шәрә хатыннар пәйда булгач, бөтен белгән догаларын укып, яңадан телевизор янына килмәскә ант итте.

Әйе, бетеренде, бик бетеренде соңгы вакытта. Аның турында күрше-күлән хатыннары, бер дә авырмый бу Хәерниса карчык, мондый кеше кинәт ята да үлә генә, дип сөйли торганнар иде. Тик аларның сүзләре дөреслеккә туры килмәде. Үлмәде дә, калмады да. Кинәт күзләре начарланды, колагы начар ишетә башлады. Аз гына йөри башласа, тыны кысыла, йөрәге кага. Элегрәк өйдә гел радио яңгырап тора иде. Бигрәк тә татарча концертларны яратып тыңлый иде. Хәзер бу бәхеттән дә мәхрүм булды. Җыр-музыка, колакка барып ирешкәч, әллә нинди аңлаешсыз тавыш боламыгы хасил итеп, башны сызлата башлый.

Хәерниса карчык бүген дә үзен начар хис итте. Әмма кичә Кәҗә Гафурының кече малае, иртәгә Баязит абый кайта, телефоннан шылтыратты, дип кереп әйткәч, гадәттәгедән дә иртәрәк торды. Сөенә-сөенә он иләде, чүпрә җебетте, сөт җылытып, камыр куйды.

Улының кайтасын болай да белә иде ул. Төшендә бер чокыр сөт, аның эчендә бер тамчы сыек кызыл кан күрде Хәерниса карчык. Ни гаҗәп, аның һәр юравы дөрес чыга. Ул хәтта хәтәр сугыш елларында да иренең исән булуына шикләнмәде. Өч тапкыр хәбәрсез югалуы турында кара мөһерле кәгазь килде, еламады. Чөнки Сәүбән төшкә кергән саен нинди дә булса бер сүз әйтеп куя. Хәернисаның күптән сынаганы бар. Төшкә кергән кеше сөйләшсә, ул — исән. Ә менә сөйләшмәсә, үлгән булып чыга. Сугыш бетәргә бер көн калгач, похоронка килеп төште. Утырып елады. Ә икенче көнне төшендә Сәүбән, тәрәзә кагып: «Хәерниса, бала ни хәлдә?» — дип кычкыргач, тынычланды. Җае чыккан саен, гел авыл капкасы янына чыгып баса торган булды. Кайтты Сәүбән, күкрәге яраланып, ике ай госпитальләрдә аунап яткан. Дөрес, башта үлгән дип уйлап, үлекләр янына чыгарып салганнар. Аңына килеп ыңгыраша башлагач, күреп алганнар тагын. Һәм кайтуын кайчан кайтты диген син. Баязитның үпкәсе кабарган төндә кайтып керде, бахыр.

Шул ук елны Сәүбәнне район газетасы редакторы итеп куйдылар. Район үзәге моннан ерак түгел, машина белән кайтып-китеп йөрде. Ә беркөнне... иртәнге якта капка төбендә бөтенләй башка машина килеп туктады. Баксаң, НКВД кешеләре көтеп торган икән. Хәерниса берни дә белмичә калды. Көндәгечә, иренең сумкасына ак ашъяулыкка төрелгән ак күмәч, мичтә тәгәрәтеп пешерелгән дүрт-биш бәрәңге салды. Чыгып киткәндә, һәрвакыттагыча: «И-

сән-сау йөреп кайт, картым!» — дип, битеннән үбеп, ишектән чыгарып җибәрде. Шуннан соң Сәүбән әйләнеп кайтмады.

Әтисен кулга алганда, Баязитка унбиш яшь иде. Әтиең халык дошманы дип, аны комсомолдан чыгардылар. Иң яхшы укучылардан саналса да, унынчы классны тәмамлаганда, өлгергәнлек турындагы аттестатына «өч»ле билгеләре генә тутырдылар. Янәсе, халык дошманы малае яхшы аттестат алырга тиеш түгел. Хәерниса районга барып шикаять язарга да уйлаган иде. Әмма адәм баласы кайда да бертөсле бит, халык дошманы хатынын берәү дә якламаячак.

Заманы хәерче иде. Баязит, әтисеннән калган бердәнбер күн итекне киеп, Саратовка китеп барды. Пароходта анысын да урлаганнар. Медицина училищесына ялантәпи килеп кергән. Дөньяда яхшы кешеләр дә юк түгел, бер фронтовик укытучы, кызганып, аны өенә алып кайткан, туйганчы ашаткан, иске генә булса да аяк киеме табып биргән. Степан исемле кеше иде, ахрысы. Альбомда аның рәсеме әле дә саклана. Немецлар Харьковны алганда, аның гаиләсе чигенеп баручы гаскәрләр белән бомбага тотылып харап булган. Баязит техникумны тәмамлаганчы Степан абыйсында яшәде.

Армиягә алмадылар. Дистрофия — табиблар куйган диагноз шундый. Хәерниса карчык моңа әллә ни борчылмады, хәтта сөенде генә дип әйтергә була.

Баязит авылга кайтырга теләмәде. Свердловскига барып, медицина институтына укырга керде. Әмма халык дошманы дигән кара тамга аны анда да куып җитте.

Менә шуларның барысын да уйлый-уйлый, Хәерниса карчык сарык итеннән бер дигән бәлеш, кыстыбый пешерде, коймак камыры әзерләп куйды. Мич янында әвәрә килә торгач, вакыт тиз узып китте, авылда инде эңгер-меңгер башланды. Ни гаҗәп, инде сентябрьнең егермеләре булса да, көннәр җылы тора. Яңгырның инде шактыйдан булганы юк. Болай булгач, Баязит озак тоткарланмас. Яңгыр яуганда гына бик читен, машина күтәртелгән юлга барып җиткәнче җаның чыгардай була. Район үзәге белән Чыбыклы арасы элек нинди булган, хәзер дә шундый.

Хәерниса карчык инде тамагы ачса да, ризыкка кагылмады. Улын көтте, күзе гел тәрәзәдә булды.

Ниһаять, кемдер тәрәзә чиртте. Баязит! Тач әтисе! Өйгә кайтып кергәндә, ул да менә шулай кылана иде.

Карчык ялгышмады. Тәрәзә артында башына киң эшләпә кигән улы елмаеп басып тора. Үзе генә. Сагындырган инде, балакай. Әлфияне җирләп йөреп, бәрәңге утыртырга да кайта алмады Баязиты. Алланың рәхмәте, күршеләре булышты Хәернисага.

Сөенеченнән йөрәге дөп-дөп тибә башлаган ана, алъяпкычын урындыкка ыргытып, ишеккә ташланды.

## Ана сагышы

Эштән кайтышлый, Валентина, бәлки, бу юлы бер-бер юньле хәбәр ишетермен дип, тагын прокуратурага юл тотты.

Тикшерүче — егерме биш яшьләр чамасындагы кара-кучкыл йөзле егет — үз кабинетында иде. Янында утырган бер карт кына абзыйны озатып чыгаргач, ул аны кабинетына чакыртып алды.

— Әлегә сезне юатырдай берни дә әйтә алмыйм, — диде ул көрсенеп. — Җинаятьче бик чиста эшләгән. Булган бөтен версияләр дә чәлпәрәмә килде. Илсурның монда бернинди дә катнашы юк.

— Ул гына гаепле минем кызымның үлемендә, ул гына! — дип елап җибәрде маржа. — Табыгыз җинаятьчене, буш калдырмам! Җиләк кебек бердәнбер кызымны харап итте бит.

Тикшерүче, коридорга күз салып, ишекне ябып куйды.

— Ярый, — диде ул, тамак кырып. — Сез сер саклый беләсезме?

Хатын, елаудан туктап, өмет тулы күзләрен аңа текәде дә пышылдап җавап бирде:

— Әлбәттә, Ринат Вәлиевич.

— Оператив мәгълүматларга караганда, сезнең кызыгызны Фил кушаматлы бер наркоман үтергән.

— Ә бу мәгълүмат сезгә каян килә?

— Безнең бит төрмәдә дә үз кешеләребез бар.

— Алайса, аны нигә кулга алмыйсыз?

— Чын исемен белә алмаганга күрә. Менә шунда бөтен хикмәт. Наркоманнар арасында безнең бер кешебез бар барын. Бөтен өмет шунда гына. Тик, зинһар, мине эштән кудырасыгыз килмәсә, бу турыда бер кешегә дә сөйләмәгез.

Прокуратурадан чыккач, Валентина трамвай тукталышына барып басты. Лена үлгәннән бирле, аның башы көн дә бер генә юнәлештә эшли иде. Ул барып чыкмаган наркоман кияү һәм мәрхүмә кызы белән бәйле барча вакыйгаларны да тагын бер кат күз алдыннан кичерде. Әйтерсең шул рәвешле җинаятьченең эзенә төшәрдәй нинди дә булса бер җеп эзли иде.

Берүзе үстерде ул Ленаны. Ирдән алимент алмады. Кыз урта мәктәпне «биш»ле билгеләренә генә тәмамлады. Кайбер балалар кебек урамда, подъездларда буталып йөрмәде. Буш вакытында музыка һәм рәсем мәктәбенә дә йөрде. Өлгергәнлек турында аттестат алгач, иптәш кызы белән Мәскәүгә китеп барды. Анда бер ел чамасы кибетче булып эшләде. Валентина, берьялгызым яшәү күңелсез, кайт инде, дип үгетли торгач, кыз янә Казанга кайтты, университетның юридик факультетына укырга керде. Шунда Илсур белән танышты. Бу егетне беренче күрүдә үк ошатмаган иде Валентина. Ник дигәндә, фатирга ремонт ясаганда кыл да кыймылдатмады егет. Авызында гел затлы сигарет булды. Валентина

күрше хатыны белән обой ябыштыра, ә ул балконда, Лена янында, эшлекле кыяфәт белән нидер такылдап, тәмәке тартып утыра. Тотып сукмәкче иде, гәүдәсе зур булса да, бала-чага гына бит әле дип, сабыр итәргә булды. Яңаклыйсы булган икән аны шунда! Кабахәт, Ленаны күмәргә дә килмәде бит!

Тора-бара Лена төнге клубларга йөри башлады. Валентина моңа да бер сүз әйтмәде. Янында егете булгач, туры юлда йөри дип уйлады. Ленаның сөйләве буенча, Илсурның әти-әнисе яхшы кешеләр булырга тиеш иде. Шуңа күрә, кыз аларда йоклап кала башлагач та, әллә ни шөбһәләнмәде. Дөрес, моның шулай икәнлегенә ышаныр өчен, бер тапкыр аларның фатирларына да кереп чыкты. Барысы да тәртип, икесе дә өйдә.

Кызы үтерелгән көнне Валентина гадәттәгечә кичке сәгать биштә кайтып керде. Ишек ярым ачык иде. Прихожийда кан эзләре ярылып ята. Валентинаның йөрәге жу итте. Башта ашханә, аннары кунак бүлмәсенә атылды. Диван янында чалкан яткан Ленаның җансыз күзләрен күргәч, аңын җуеп егылды.

Иң әүвәле милиция, аннары «ашыгыч ярдәм» машинасы килеп җитте. Бөтен бүлмәләрне таптап бетерделәр. Ә бу хәлдән соң җинаятьчедән нинди эз калсын? Дөрес, соңыннан моның өчен аларга эләкте эләгүен.

Шәфкать туташы: «Она уже все», — дип башын чайкагач, Валентина тагын аңын җуйды. Ниндидер көчле укол кададылар аңа. Киленнәре Татьянада гына аңына килде ул.

Милиция фатир ишегенә пломба куеп киткән икән. Тикшерүче аны үзе эзләп килде. Ләкин Валентина аның сорауларына анык кына җавап бирердәй хәлдә түгел иде. Тагын «ашыгыч ярдәм» машинасы чакырттылар.

Җанны иң тетрәндергәне — Ленаны моргтан алып чыгу булды. Эштән килгән хезмәттәшләре дә, туганнары да, Валя үзе дә үкерә-үкерә елады. Буйдан-буйга ярганнар иде бәгырьне.

Шулай итеп, егерме яше дә тулмаган кыз баланы Самосырово зиратына җирләп куйдылар. Илсур да, аның әти-әнисе дә Ленаны соңгы юлга озатырга килмәде. Дөрес, Илсур кулга алынгач, әниләре улларын эзләп телефоннан шылтыратты шылтыратуын. Бу вакытта Валентинаны укол кадап йокларга гына яткырган булганнар әле. Трубканы күрше хатыны алган. Ул, Ленаны үтерделәр, Илсур кулда, дип әйткәч, теге: «Наркотики что-ли?!» — дип елап җибәргән.

Наркоман булган икән кияү. Их, Лена, Лена! Нигә бу турыда әйтмәдең син әниеңә!

Вакыт барысын да дәвалый, дигәннәре дөрес түгел икән. Көн артыннан көн үткән саен, йөрәк ярасы тагын да тирәнәя, тагын да ныграк сызландыра. Лена белән булган һәрбер уенчык, һәрбер бизәнү әйбере дә үтергеч сагыш хисе уята хәзер Валяда. Ара-тирә шундый чарасызлык биләп ала ки, истерикага бирелеп, стеналарга

үрмәли-үрмәли елаган чаклары була. Кырык сигездә генә булса да, шушы ике ай эчендә нык картайды Валентина, маңгаен тирән җыерчыклар басты, зәңгәр күзләре эчкә батып керде, ачык түштәге матур куе чәче дә учлап-учлап коела башлады. Бала кайгысыннан сакласын икән Ходай. Кызы белән тормышның бөтен мәгънәсен югалтты ул. Үлсәң җиңелрәк. Әмма үтерүче кулга алынмыйча, Валентина бу турыда уйларга да тиеш түгел.

## Манара

Баязит әнисенә үз кайгыларын сөйләп тормады. Ләкин Трактор Рәшитнең тиле улын анасының кабере янында тапканнары турында ишеткәч, йөрәге әрнеп әйтеп куйды:

— Күпме яшьләрне харап итте бу хөкүмәт! Башта Әфганстан, хәзер Ичкерия.

Икенче көнне ул иртүк, йомыш бар дип, күрше авылга чыгып китте.

Төштән соң гына кайтып керде, кәефле иде. Анда зур бер кирпеч йорт сатыла икән. Хуҗа кеше белән бәясен дә сөйләшеп куйды. Кыйммәт түгел. Янда сарай, абзар ише корылмаларны төзергә, яңа йорт җиһазлары сатып алырга да акчасы калды әле. Сөенер инде болай булгач Кадрия. Ә төп нигезгә йорт салу турында сүз кузгатмады. Ничек торган, шулай тора бирсен. Ямьшәеп беткән булса да, әнисе йортның бер генә тактасын да алыштыртмады. Чөнки аның өчен монда һәрнәрсә кадерле. Әтиләре сугыштан кайтып кергән көнне чирткән тәрәзә дә, ул соңгы тапкыр чыгып киткән җил капка да — барысы да аның яшьлек еллары ядкәре иде.

Тамак ялгап алгач, Баязит тагын чыгып китте. Бу юлы мәчетне карап кайтырга булды ул. Сугышка кадәр мәчет клуб булып торды, аннары анда колхоз ашлыгын сакладылар. Хәзер менә яңадан мәчет итәргә булганнар. Яңа манара куйдылар дип сөйләгән иде анасы.

Мәчет манарасын кырык тугызынчы елны гына кисеп аударганнар әле. Районнан прокурор үзе килеп кешеләрне кодалап йөргән. Барысы да баш тартканнар. Авыл сәвите белән комсомол ячейкасы да җөрьәт итмәгән манараны кисәргә. Безгә кадәр торган, бездән соң да торсын, ашарга сорамый бит, дип кенә җавап биргәннәр. Маңгайларына наган белән терәгәч тә, баш тартканнар. Шуннан соң авыл сәвите рәисен дә, ячейка секретарен дә кулга алганнар. Аптырагач, прокурор күрше авылда бер капчык бәрәңге урлап тотылган урыс мужигын алып килгән. Ул да, теләсәгез нишләтегез, әмма Алла йортының манарасын кисеп, мәңгелек каһәр алырга теләмим, дип баш тарткан. Шуннан соң тәмам җене кузгалган прокурор район үзәгенә эшкә җибәрелгән берничә немец әсирен алып килгән. Аларга нәрсә, күрсәт кенә инде, манараны их дигәнче аударып та төшергәннәр.

Баязит ярым ай балкып торган биек манарага сокланып торган мәлдә, аның янына башына кәләпүш кигән, пөхтә генә сакалмыек үстергән колхозның элекке партоешма секретаре Нурулла килеп басты. Күрештеләр. Аларның яшьләре бер чама. Мәктәпне бергә тәмамладылар.

— Нихәл, яшьти? — диде Нурулла. — Быел бәрәңге казырга да кайтмадың бугай.

Баязит теләр-теләмәс кенә җавап бирде:

— Мәшәкать күп булды шул, Нурулла. — Аннары, аның төсе-битенә игътибар итеп, шаяртып куйды. — Гел мулла кыяфәтләре кергән үзеңә, сөбханаллаһы, намазлыкка алынмагансыңдыр ич?

— Ә нигә басмаска, бастым, кәнишне, — дип җавап бирде авылдашы, горуранә кыланып. — Шушы мәчеттә мулла булып торам мин хәзер.

Баязит чак кына көлеп җибәрмәде.

— Соң, мәчеттә мулла булып торыр өчен дини белем кирәк бит, Нурулла!

— Син белмәгәч тә, мин мәктәптә укыганда ук бөтен догаларны яттан белә идем. Әтигә рәхмәт. Сизгән булсалар, башны бетерәләр иде, кәнишне. Кыскасы, указлы мулла мин хәзер, вәт!

«Кызык замана китте, — дип уйлады Баязит. — Сәвит заманында алласызлыкка өндәде, хәзер менә мулла булган. Ярый, соң булса да уң булсын, диләр бит. Дингә кайткан икән, моңа сөенергә генә кирәк».

Ә Баязит, намаз укымаса да, Алланың барлыгына һәрвакыт ышанып яшәде. Алай да сакламады аны Ходай. Кайчан да булса мондый бәхетсез булырмын дип тә уйламады. Малаен урыс мәктәбенә биргәнче мәдрәсәдә укыткан булса, нинди бәхетле әти буласы иде бит! Заманы әшәке булды шул.

— Котлыйм сине! — Баязит хәзрәтнең кулын кысып куйды. — Буяу миннән инде, болай булгач.

Нурулланың йөзе яктырып китте.

— Беләм, беләм мин ул буяуны. Бик рәхмәтле булыр идек сиңа, Баязит туган.

Мулла белән аерылышкач, Баязит акрын гына өйгә таба атлады.

## Күзгә-күз

Казанга кайтып күрше хатыны кайгылы хәлләрне җиткергәч, Баязит туп-туры хастаханәгә чапты. Кадрия инде өченче көнен малае янында —реанимациядә икән. Фатирда янасы нәрсә янып беткән. Бусы зур бәла түгел, иң мөһиме — Кәбире исән калган. Баязитны куркытып йөргән мафиозиның эше инде бу. Каян белгән Кадриянең адресын? Альберттанмы? Әйе, Альберттандыр. Әле ярый

акчаны үзе белән алган иде. Күңеле сизгән, күрәсең. Йә югаласы, йә янасы булган бит, каһәр! Ә акча монда — йөрәк турысында!

Хастаханәнең рәшәткәле тимер капкасыннан кереп барганда, аны башына кара кепка, өстенә кара плащ кигән бер егет туктатты.

— Сәлам, Баязит абзый! Сагындыра башладың инде.

Яхшылабрак караса, имәнеп китте Баязит. Теге мафиози ич бу! Хәзер берне сыларга кирәк аңа. Хәер, сугарга беркайчан да соң түгел.

— Нәрсә кирәк?! — диде ул, сабыр булырга тырышып.

— Сөйләшеп алырга иде.

— Бер сөйләштек инде синең белән. Саттым мин фатирны.

— Саткансың икән, бик яхшы, — дип елмайды ташбәбәк. — Миңа синең бер тиен акчаң да кирәк түгел.

— Алайса, сау бул!

— Ашыкма, абзый. Әнә теге кызыл «мерседес»ны күрәсеңме?

— Ие.

— Менә шунда кереп утыргач, мин сиңа ни өчен монда килгәнемне аңлатырмын.

Баязит икеләнеп калды. Яхшылык белән килмәгән инде. Аны монда очратасын белгәч, Кадриянең малае реанимациядә ятканын да белә, димәк. Ә нәрсәгә куркып торырга? Урамда якты, тирә-юньдә кешеләр йөри.

Тәвәккәлләде. Машинаның алгы утыргычына кереп утырды.

Ташбәбәк, елан кебек теш арасыннан гына сыгып, сүз башлады:

— Яхшылык белән генә бирмисең инде акчаны, абзый, ә?

— Тагын бер балык башы. Мин киттем!

— Кит, кем сиңа китмә ди? — Теге кеткелдәп көлеп җибәрде.

Шул мәлне арттан берәү Баязитның муенына бау салды да аны, бар көченә артка каерып, буарга тотынды. Тибенгән, тыпырчынган арада, Баязит көзгедән үзенең үтерүчесен күреп «аһ!» итте.

— Улы-ым! — Башка бер сүз дә әйтә алмады, авызыннан гыжылдау тавышы гына чыкты. Аңа хәзер күзләрендә яктылык нуры сүрелгәнче көзгегә генә карау насыйп иде.

Менә көзгедә Әлфиянең ап-ак йөзе күренгәндәй булып китте. Күзләреннән яшь тәгәри. Нигә елый? Дөньяны әкрен генә караңгылык баса. Берәү ерактан, бик ерактан шатлыклы тавыш белән аңа кычкыра кебек:

— Баязи-и-ит! Синең малаең туды-ы-ы!

## Төнге юлаучылар

Яңгыр кичкә таба көчәя төште. Руль артында утырган Кендек, борын астыннан ниндидер көйгә сызгырып барды да, канәгатьсезлек белдереп, мыгырдап куйды:

— Чыбыклыга алтмыш кына чакрым дигән идең, спидометр инде сиксәнне күрсәтә.

— Күп калмады инде, — диде артта әтисенең җансыз гәүдәсен кочаклап барган Альберт. — Күтәртелгән юлдан барабыз лабаса.

— Тавышың бик тонык. Чирлисең мәллә, парень?.. Үземнең дә башым авыртып тора что-то. Әллә тагын иснәп куябызмы?

— Начар булмас иде.

— Мә, иснә. — Кендек Альбертка тырнак зурлыгындагы кәгазь кап сузды. Тавышында вәкарьлек сизелә иде аның. — Газиз атаңны үтергәнгә намус газабы борауламыйммы?

Альберт дәшмәде. Героинны иснәп алгач, эчтән генә уйлап куйды: «Эшне бетерик әле, сиңа да чират җитәр, мөртәт!»

Мәетне багажникка салмыйча дөрес эшләделәр алар. Апас районына килеп керүгә, машинаны ике тапкыр юл-патруль инспекциясе туктатты. Альберт янында башын артка ыргытып барган пассажирга игътибар бирүче булмады. Исерек дип уйладылар инде. Ә менә багажникны тентеделәр. Хәтта Кендекнең правасын да шундый зур игътибар белән тикшереп тормадылар. Ә яхшылабрак карасаң, андагы ялган мөһерне чамаларга була иде.

Гаҗәп, хәзерге минутта Альберт һичбер намус газабы кичерми. Әфьюн тәэсире бу. Ләкин җанда ниндидер коточкыч бушлык. Дөресрәге, битарафлыктыр. Героиннан аермасын Ходай. Юкса бераз айный башлагач, аны мескенлек, чарасызлык хисе биләп алачак. Аннары инде хет асылын! Намус үзе сөйләшә башлый синең белән. А, ничек кенә сөйләшә әле! Ул синең бөтен җаныңны, бәгыреңне телгәләп ашый. Яралы тәнгә тоз сибү дә алай сызландырмый. Чын тәмуг менә шул була инде. Күзгә әллә нинди җенпәриләр, албастылар күренә, колакта берсеннән-берсе куркынычрак көлгән, кычкырган, янаган авазлар ишетелә башлый. Шушы халәткә кайтып төшмәс өчен, ул теләсә кемне суярга әзер. Альберт тормышның мәңге шулай дәвам итмәсен белә. Моның барыбер бер ахыры булачак. Ничек шулай килеп чыкты соң әле? Юк, уйларга ярамый. Уйламас өчен, тагын җен порошогын иснәргә кирәк.

— Үзем дә юләр инде, ничә чакрым мәет утыртып йөрим, — дип сөйләнде Кендек. — Беткән идемени Казан тирәсендә урын!

— Әти бит чүтеки, кешечә булсын, дидем.

Кендек шаркылдап көлеп җибәрде.

— Әти?! Үтергәндә уйларга кирәк иде әтиең турында. — Аннары көзгедән Альбертның күзе акая башлаганын күреп, юатырга тотынды. — Җә, җә, кабарынма, шаяртам гына мин. Уважаю мин мокрушникларны. Молодец! Нервларың нык икән, парень. Миңа охшагансың. Башың исән булса, караклар дөньясында зур кеше булачаксың әле. Дөрес әйтәсең, әти кеше бит чүтеки. Хөрмәтләп, зурлап күмәрбез үзен, Алла бирсә.

— Бир әле иснәргә.

— Тагынмы?.. Ну ты даешь, парень! Мә, передозировка була күрмәсен.

Альберт, комсызланып, әфьюн иснәргә керепте. Менә хәзер чын кәеф тота ул. Аңа рәхә-әт...

Зират юлына борылгач, Кендек фараны сүндерде. Болай тынычрак, машина игътибарны җәлеп итми.

Машина капкадан эчкәрерәк уза алмады. Анда инде кеше җирләрлек урын да калмаган.

— Хәерчеләр! — дип сүгенде Кендек, төкерекләрен чәчеп. — Казандагы татар зираты дип белерсең, җиргә экономия ясап яталар!

Альберт аяк астында яткан кыска саплы көрәк белән Кендекнең баш түбәсенә бирмәкче булды. Әмма бүре улаган тавыш ишетелгәч, уеннан кире кайтты. Әтисен үзе генә күмәргә уйлаган иде ул. Бүреләр янында ялгызың калу куркыныч.

— Монда бүреләр дә бармыни? — диде Кендек тәшвишләнеп. — Бәлки, шушында гына калдырып китәрбез, ә? Күмәрләр әле. Зиратта көн дә кеше йөреп тора.

— У-у-у! — Тагын бүре улый.

Альберт, бер сүз дә дәшмичә, машинадан әтисен өстерәп чыгарды. Кендекнең дә чыкмый хәле юк.

Шактый эчкә керделәр. Чардуганнар арасы тар, Альберт белән Кендекнең курткалары ертылып бетте. Җитмәсә, агач ботаклары йөзне тырмый, пәрәвез авызга керә. Мәет тә авырайганнан-авырая бара.

— Тагын ун адым барасы булса, мин үләм, — дип ухылдады Кендек, елак тавыш белән. — Туктыйк!

Тынлыкны тагын җан өшеткеч бүре улавы бозды:

— У-у-у!

— Ярый, туктыйк, алайса, — диде Альберт. — Шушында күмәбез.

Монда урын, чыннан да, җитәрлек иде.

Чокыр тирәнлеге билдән булуга, төнге кунаклар тәмам хәлдән тайды. Шуның өстенә тамаклары да нык кипте.

— Су алмаганбыз, юләрләр! — дип шыңшыды Кендек. — Ашыгырга кирәк, парень, берәү генә түгел монда бүре.

— Ишетәм. — Альберт көрәген җиргә кадап куйды. — Җитәрдер, ахрысы. Әйдә, өстерәргә булыш!

Мәетне инде күмеп бетерәбез дигәндә генә, чардуганнар арасыннан берничә бүре күзе елтырап куйды. Фонарь яктысыннан ким түгел иде алар.

— Беттек, парень! — Кендек күтенә үк утырды.

— Хәзер, тагын берничә көрәк җир ыргытам да...

— У-у-у! — Бүреләр инде бер-берсен уздыра-уздыра улыйлар.

Альберт белән Кендек, тирә-юньгә ялт-йолт карана-карана, машинага таба йөгерделәр. Ә юлда киртә булып торган хисапсыз

агач һәм тимер чардуганнар, аларны ычкындырырга теләмәгәндәй, курткаларын, чалбарларын умырып бетерделәр.

Машина белән күтәртелгән юлга чыгуга, Кендек төрмәдә өйрәнеп кайткан җырын сузып җибәрде:

Сижу я за решеткой и думаю о том,
Как рыжему мильтону заехать кирпичем...

«Җырла, җырла, хәчтерүш, — дип уйлады Альберт көлемсерәп. — Борылышка гына килеп җитик, синең башка да кирпеч төшәчәк!»

Ул, тәмәке алырга дип, пиджак кесәсенә үрелде. Анаңны гына икән! Күлмәкчән генә ич ул! Пиджак зиратта калган! Акча да шунда...

— Кендек, безгә борылырга кирәк!

— Ничек инде борылырга?

— Пиджак зиратта калган.

— Нәрсә?! — Кендек шундук тормозга китереп басты. — Вещественное доказательство калдыргансың, брат. Җәяүләп барып кайтасың инде болай булгач! Бәлки, бераз акыл керер. Давай, төш! Акчаңны миңа биреп калдыр. Курыкма, качмыйм. Бер җеп белән бәйләнгән бит без хәзер.

— Акча пиджак кесәсендә.

— У, урод!

Альберт бу юлы акланып тормады, тирән итеп сулыш алды да аяк астында яткан кыска көрәкне Кендекнең муен тамырына утыртты. Тынын да чыгара алмады ташбәбәк, утырган җирендә йөзе белән рульгә капланды.

Аны юл читенә ыргытып, өстенә әрем җәеп куйгач, ул машина белән зиратка юл тотты. Әрем исе бала чагын исенә төшерде аның. Альберт кечкенә вакытта әнисе бу үлән төнәтмәсен ашказаны авыртканда эчә иде.

Уйламагандыр Кендек шушы басуда үз үлемен табасын. Эткә эт үлеме! Кайчан да булса Альбертны да шундый язмыш көтә. Әмма әлегә ул исән. Шулай булгач, яшәп калырга кирәк!

## Матур кәгазь

Яшь бүреләр яңа кабер янында иснәнеп йөргән арада, ана бүре агач ботагына эленгән пиджакны ырылдый-ырылдый өстерәп төшерде. Аннан сасы тир һәм тәмәке исе килә иде. «Адәм баласы төнлә йөрсә, юньлелек белән йөрмәс», — дип уйлады ул.

Нинди төргәк бу? Кеше сурәте төшерелгән кәгазьләрдән тәмле буяу исе килеп тора. Акча! Яшь вакытта ана бүрегә әтисенең сөйләгәне бар. Адәм баласы шушы матур кәгазь өчен бер-берсенең башын ашарга әзер икән. Аны үрчетер өчен ул барысын да эшли. Сихерле кәгазь бу! Куркыныч кәгазь бу! Фу! Теге адәм актыкла-

ры мәет өстерәп килде. Аны да шушы матур кәгазь өчен үтерделәрме?

Ана бүре, ырылдый-ырылдый, очлы тешләре белән яшел акчаларны ертырга тотынды. Үзләре яшел төстә булсалар да, кан тәме килә алардан. Фу!

— У-у-у! — Яшь бүреләр ана бүрене ашыктыра.

Инде кузгалдык дип торганда, җирдә хәтфә булып яткан кипкән яфракларны изеп, лап-лоп атлап килгән аяк тавышы ишетелде. Адәм баласы!

Ана бүре качарга уйламады да.

— У-у-у!

Яшь бүреләр дә качмады.

— У-у-у!

Куаклыклар арасыннан килеп чыккан бәндәдән кан исе килә. Ул әле генә үз ырудашын үтергәнгә охшый. Кулындагы көрәкне уйнатып, бүре өстенә килә.

— Кит пиджак яныннан, соры шайтан! — Агарынган. Димәк, курка.

Кавем башлыгы үткен тешләрен ыржайтты.

— У-у-у! — Якын килмә, чәйним диюе аның.

Яшь бүреләр, аналарына куркыныч янаганын күреп, акрын гына адәм өстенә килә башладылар.

Курыкты. Чигенә торгач, җирдә аунап яткан агач ботагына абынып егылды да, көрәген ташлап, капка ягына йөгерде.

Кавем башлыгы аны эзәрлекләмәде. Ата бүренең киңәшен истә тота ул.

— У-у-у!

Яшь бүреләр бу улауның мәгънәсен бик яхшы аңлады. «Кызык өчен үтерүдән сакланыгыз, балалар. Ата бүре шундый васыять әйтте», — диде ана бүре.

Кузгалдылар. Ерак һәм куркыныч юлга чыга бүреләр. Адәм баласы аяк басмаган җирләрне эзләп чыга. Кешеләр арасында бүре булып калуы кыен. Алар үтерүче түгел, алар бөек табигать кануннарына буйсынып, аның белән аһәңдәш җан ияләре булып яшәргә телиләр. Һәркемнең үз юлы!

## Милициядә

Ноябрь башларында Кәбир хастаханәдән чыкты. Табиблар аның терелә алачагына ышанмаган иде. Бәхеткә, яшьлек җиңде. Өйдә тагын бер-ике ай дәваланганнан соң, ул техникумда укуын дәвам итәчәк.

Кадрия шул гомер хәбәр салмаган Баязитка үпкәләсә дә, авылга телеграмма сукты. Борчылуы юкка гына булмаган икән, аның авылдан чыгып китүенә инде ике айдан артык вакыт узып киткән. Казанга кайтып китәргә тиеш булган бит. Кайда булыр?

Пошаманга калган хатын шул ук көнне милициягә йөгерде. Көлделәр генә, кайтыр, беркая да китмәс дип, тынычландырган булалар. Аннары закон буенча хәбәрсез югалган кешене рәсми рәвештә бер елдан соң гына эзли башлыйлар икән. Шулай да бу мәгълүматның барча милиция бүлекчәләренә дә хәбәр ителәчәге турында әйттеләр әйтүен.

«Үтергәннәр инде, үтергәннәр! — дип уйлады Кадрия, күз яшьләренә буылып. — Бу кадәр вакыт хәбәр салмыйча түзмәс иде. Моргка барып карарга кирәк. Документларын юк иткән булсалар, сукбайлар белән бергә туганнар каберлегенә дә күмеп куюлары бар».

Мең бәлаләр белән прокуратурадан рөхсәт кәгазе алгач, Кадрия моргка юл тотты.

Белешмәләр бүлегендәге олы яшьләрдәге шәфкать туташы аңа таушалып беткән берничә калын кенәгә тоттырды.

— Менә бусында моргтагыларның исемлеге, бусында — фотосурәтләре, — диде дә, кем beләндер бытыр-бытыр килеп,телефоннан сөйләшә башлады.

Күпме генә актарынса да, Кадрия таныш фамилияне, таныш фотосурәтне тапмады. Димәк, Баязитның гәүдәсе монда юк.

Ул инде, борчыганы өчен гафу үтенеп, чыгып китмәкче булган иде, ләкин маржа елмаеп кына әйтеп куйды:

— Ярый, ярый, гафу үтенмәгез инде, бу безнең эшебез бит. Хәер, төрле кешеләр килә безгә. Моннан ун-унбиш көн элек бер бәндә килгән иде. Әтисенең туганнар каберлегенә күмелүе турында белешмә таләп итә. Исемлектә булмагач, ничек бирим ди мин андый белешмәне? Куып чыгармакчы идем, ыжгырып өскә килә. Үтерә дип торам. Милициягә шылтыратам дигәч кенә чыгып сызды. Наркоман иде, ахрысы.

Наркоман, диме? Туктале, Баязитның малае да наркоман бит.

— Төскә-биткәниндирәк иде? — дип сорады Кадрия.

— Буйга әллә ни озын түгел иде үзе. Базык кына гәүдәле, хәтта симез дип тә әйтер идем. Хәтерем ялгышмаса, уң кулында «Слон» дип язылган наколка да бар иде.

Альберт инде! Әтисенең күмелүе турында белешмә аңа нигә кирәк булды икән? Их, үзен бер күреп сөйләшәсе иде! Ә хәзер аны табу мөмкин түгел. Чөнки төпле яшәү урыны да, пропискасы да юк.

Кадрия янә милициягә чапты. Бу юлы аның гаризасы зур кызыксыну уятты.

Шундук прокуратурадан бер яшь тикшерүче килеп җитте. Альбертның кыяфәте белән тәфсилләп кызыксынганнан соң, ул өстәлгә бер фотосурәт чыгарып салды.

— Шушымы Альберт?

— Ие, — диде Кадрия гаҗәпләнеп.

— Слон, димәк.

— Нинди слон?

Тикшерүче елмаеп куйды.

— Кушаматы шундый аның. Без аны инде күптән эзлибез. Ул бер кызны үтерүдә гаепләнә. Димәк, әтисен дә үтергән булуы ихтимал. Әлегә аны изоляторда тотабыз. Сорауларга анык кына җавап бирә алмый. Камерада эт булып улап утыра. Тиздән психиатрия экспертизасы узачак. Мәгълүматыгыз өчен зур рәхмәт сезгә. Вакыты җиткәч, без сезне үзебез чакыртырбыз.

Кадрия прокуратурадан чыкты. Тышта инде караңгы. Хәзер урамнарда элеккечә мулдан электр уты яндырмыйлар. Исән-сау кайтып җитәсеңме син, юкмы, анда берәүнең дә эше юк. Һәркем үзе өчен генә яши торган заман җитте. Кичәгенәк трамвай-троллейбуслар да көне буе туктап торды. Кайсы чатта, кайсы күпер өстендә басып калды. Вакыт үзе туктап калган кебек иде. Ә ул, чыннан да, туктады бугай. Ашыгыр җир юк, үткәннәр үткәндә калды, ә киләчәгебез — соры томан.

Минимаркет яныннан узып барышлый, Кадрия чүгәләп утырган сукбай хатынга игътибар итте. Ул тимерчыбык белән йонлач кына кара эт авызындагы тавык ботын тартып алмакчы. Эт ырылдый, сукбай ырылдый. Каршыдагы кибеттән инде, карак этне акылга утыртырга дип, кулындагы себеркесен болгый-болгый, кибетче хатын йөгереп чыгып бара иде.



# ЧОКЫР ДА ТАКЫР

## Ерганак урамына караңгы төшә

Майның унбишләре иде. Кабан күле ягыннан кичке азан яңгырап җиргә караңгы төшүгә, Ерганак урамындагы шау чәчәктә утырган алмагач, чия бакчаларында «фиют-фиют» итеп әллә нинди хикмәтле кошлар сайрый башлады. Казан Кремле курантлары да, чиркәү чаңы да ишетелә бу җирдә. Шәһәр уртасы булса да, нәкъ авылдагыча монда. Кем әйтмешли, һәркемнең үз агач йорты, үз ишегалды, үз мунчасы. Мунча фәкать татар кешеләрендә генә. Ял көннәрендә дистәләгән мунча морҗасыннан төтен баганасы күтәрелә, күрше күршене зурлап мунча керергә чакыра. Кош-корт тотучылар да бар, иртә-кич ара-тирә әтәч кычкырганны ишетергә мөмкин. Дөньялар үзгәреп китәр алдыннан гына урамга бер дигән асфальт җәелде, газ кертелде. Су да керткән булырлар иде, әмма советлар өлгермичә калды. Бу кадәр кайгыртучанлыкның бер хикмәте бар. Торгынлык елларында яр өстендә генә утырган Юлбашчы музеена чит ил туристлары агыла иде. Алардан берни дә яшереп булмый, күзгә чалынган кечкенә генә җитешсезлек тә фотокамерага эләгә. Аннары көт тә тор, урының йә «Шпигель»дә, йә «Нью-Йорк Таймс»та булачак. Янәсе, менә ничек начар яши пролетариат! Идеологик көрәш рәхимсез иде ул вакытта. Ахыр чиктә, без, Ленин һәм Маркс тарафдарлары, җиңелдек. Һәм бик хурлыклы җиңелү булды бу. Нәтиҗәсен шушы урам мисалында да күрергә була. Монда да пролетариатка рәт бетте, Ерганакның яртысын «яңа урыс»лар басып алды. Шәһәр думасында тузган йортларны бетерү программасы проекты кабул ителүгә, таза нарратлардан салынган мең яшәрлек йортлар йокының иң тәмле вакытында дөрт итеп кабына да иртәнге якка кадәр янып юкка чыга башлады. Шул рәвешле бу урамда ике пенсионер, бер мәче янып үлде. Бер абзыйның хәсрәттән йөрәге ярыл-

ды, икенчесе күкерт кислотасы эчеп үлде, өченчесе исә ике-өч көннән ут тимичә калган мунчасында үз-үзен чәнечте. Дөрес, бер генә гаилә дә урамда калмады, аларның һәркайсына Азино бистәсендә төзелә торган өр-яңа йортлардан ике-өч бүлмәле фатир бирелде. Янгыннар юктан гына чыкмады, әлбәттә. Шәһәр мафиясе күз салган иң матур, иң яшел урамнарның берсе иде ул. Ике-өч ел эчендә морҗалары гына кукраеп утырып калган агач йортлар урынында хан сараена тиң берничә катлы таш йорт калкып чыкты, җиңел машиналар белән тән сакчылары озатып йөрүче «джип»лар да пәйда булды. Ләкин әҗәлең җитсә, сине бернинди байлык, бернинди тән сакчылары да коткара алмый. Әле кичә генә бу урамда менә шундый бер «яңа урыс»ның коттеджын гранатометтан чәпеделәр. Үзе һәм гаиләсе исән калды. Моннан бер ун ел элек Башмаков дигән бу эшмәкәр криминаль бизнес белән шөгыльләнгән өчен хөкемгә дә тартылган иде. Акча коткарды, шартлы рәвештә ике елга ирегеннән мәхрүм иттеләр. Һәм менә чишелеш: коттеджга гранатометтан аталар. Кемгәдер зур зыян салган, йә булмаса, нык комачау итә, димәк. Мондый һөҗүмнәрнең нәрсә белән бетәсен беләбез инде без, бүген үтермәсәләр, иртәгә, берсекөнгә барыбер үтерәчәкләр.

Кыскасы, Ерганак урамына тагын бер шомлы төн килде. Бу айда кем дә булса янарга тиеш. Чөнки ел да шулай, май аена керденме, нәрсәдер «шарт!» итеп куя да ике-өч йортның көле күккә оча. Катлаулы эш түгел, моның өчен бер шешә бензин җитә. Ут төртмәсәләр, башка төрле хәвеф-хәтәр килеп чыга. Бер ай элек урам башында яшәүче әтиле-уллы Митәевләрне суеп чыктылар. Йортлары да янды. Күмерләнгән гәүдәләрен генә эзләп таптылар. Эшмәкәрлек белән шөгыльләнәләр иде. Күрәсең, кемнеңдер юлына аркылы төшкәннәр. Аскы урамда да тыныч түгел, андагы янган йорт подвалына сукбайлар оялаган. Беркөнне шул тирәдә уйнап йөргән малайлар аларның мәче тунаганнарын күргәннәр. Өстәвенә күрше урамда гына кечкенә кызларның печ иткәнен карап торырга яратучы бер маньяк барлыкка килгән, дип сөйлиләр. Милиция көненә берничә тапкыр якын-тирә урамнарны машина белән урап уза. Ләкин әлегә тота алганнары юк.

Заман нинди генә болгавыр булса да, сүзне яшьлекнең үзеннән, мәхәббәттән башлыйк әле. Чөнки ул да иксез-чиксез җиһан киңлегендә балкыган йолдызлар кебек якты, матур һәм мәңгелек.

## Ярату

Рафис белән Айсылу бүген көне буе Горький паркы астындагы комлыкта кызындылар. Аннары, аерылышасылары килмичә, беркадәр парк буйлап йөрделәр. Монда һава шәп, эчкәрерәк кергән саен, тәмле үлән, кыргый чәчәк исе борынны кытыклап тора.

Тиздән алар аерылышачаклар. Озакка түгел, әлбәттә. Айсылу иртәнге сәгать икедә поезд белән бер айга Санкт-Петербургка китә. Ул андагы төзүчеләр институтында кабул итү имтиханнары бирергә тиеш.

Кичке тугызлар тирәсендә алар җәяүләп кенә кайтырга чыктылар. Юл буе сөйләшеп бара торгач, Тукташ урамы чатына килеп җиткәннәрен сизми дә калдылар. Айсылулар зоопарк почмагында, тугыз катлы йортта яши. Әтисе мәшһүр рәссам, Рафиска аның берничә күргәзмәсендә дә булырга туры килде.

Туктадылар. Күз карашлары очрашуга, Рафис Айсылуның битеннән үбеп алды. Нинди матур бу кара күзләр, әйтерсең өлгергән шомырт! Чәчләре дә чем-кара. Андый кара төс Актаныш кызларында гына була, дигән иде аңа беркөн әнисе. Һәм Рафис юри кызыксыныш карады. Чыннан да, Айсылуның әнисе Актаныш авылыннан икән. Аның да чәчләре шундый кара.

— Кит, юләр, кеше күрә бит, — диде кыз, аны этеп.

Рафис кызның бу көязләнүен һич аңлый алмый. Җиденче сыйныфтан бирле бергә йөриләр, ә рәхәтләнеп үпкәне юк. Их, бар бит бәхетле егетләр, йөргән кызлары үзләре куенга керә! Тукталышта, трамвайда булсын, беркемнән дә оялмыйча, рәхәтләнеп үбешәләр. Үбешсәләр соң, аның каравы аларның берсе дә матурлык буенча Айсылуны уздыра алмый. Айсылу бөтен шәһәргә бер генә! Аһ, бу сылу гәүдәне! Озаграк, төне буе кочаклап торасы иде аны! Карашы да, иреннәре дә, сулышы да тәмле аның. Ярый, рәхәтләнеп үбә алмаса да, Айсылуның яратуы кирәк аңа. Ә кыз аны яратырга тиеш. Чөнки эчке сиземләве шуны сөйли. Яратмаса, киләсе елда кияүгә чыгарга сүз куешмас иде. Ярата!.. Айсылу Рафисны ярата!.. А, нинди зур бәхет!

Ә Рафис үзен матур дип санамый. Чәче җирән, йөзендә сипкеле дә бар. Кайсы җиренә карады икән аның Айсылу? Менә бу егет өчен чын табышмак иде. Дөрес, буе шәп шәбен. Метр да сиксән ике булыр. Дүрт ай элек, ярыш алдыннан, «Динамо» клубында үлчәгәннәр иде. Тазалыкка да таза. Кыска җиңле футболка кисә, мыскаллары уйнап тора. Ләкин шундый матур кызны үзеңә карату өчен бу гына барыбер аз кебек. Хикмәт нәрсәдә? Бүген моның серен белергә кирәк.

— Айсылу, — диде ул, ниһаять, тәвәккәлләп. — Син мине яратасыңмы?

Кыз кызарды, аннары мут кына елмаеп әйтте:

— Ә син ничек дип уйлыйсың?

— Минме?.. — Егет югалып калды. — Мин… теге ни…

— Әйтеп бетер.

— Яратасыңдыр дип уйлыйм инде.

— Ә син шикләнә идеңмени?

— Юк, нигә шикләним ди?..

— Нигә шундый сорау бирдең әле син?

— Мин бит ямьсез.

— Син... ямьсез?.. — Айсылу кычкырып көлеп җибәрде. — Кем әйтте сиңа моны?

— Үзем беләм.

— Белмисең син бер нәрсә дә!.. Беләсеңме, мин сине кемгә охшатам?

— Кемгә?

— Әтигә.

— Әйттең тагын.

— Аның йөз чалымнары синдә дә бар. Әйтик, борының, каш җыеруларың белән син гел аны хәтерләтәсең. Ә бер мәшһүр психолог, кыз бала еш кына үзенең әтисенә охшаган егетне сайларга тырыша, дип язган.

— Алай икән.

Бөтенесен дә көтте Рафис, ләкин мондый җавапны көтмәгән иде. Күңелдән генә бераз үпкәләп тә куйды хәтта. Әтисенә охшаганга күрә, имеш. Ә Рафис үзе кайда? Аның Рафис булып яратыласы килә бит!

— Ә син мине ни өчен яратасың? — дип сорады кыз.

— Матур булганга күрә.

— Шуның өчен генәмени?

— Аннары... иренең кырыендагы менә бу кечкенә миңең дә бик ошый.

— Димәк, син дә мине әниеңә охшаганга күрә яратасың. Аның да иренендә нәкъ менә шундый миң бар.

Рафис аптырап башын кашыды:

— Дөрес, — дип мыгырдады ул. — Вәт сиңа психолог!

Алар икесе дә көлеп җибәрделәр. Менә бит ул дөнья нинди. Ниһаять, икесенең дә сере ачылды. Кеше дигәнең шундый хикмәтле җан иясе инде, кайвакыт үзенең нигә ратканын да аңлый алмыйча йөри.

Кыз, көлүдән туктап, беләгендәге сәгатенә күз салды.

— Сәгать ун... — диде ул гаҗәпләнеп. — Тиз уза вакыт... Поезд төнге сәгать бердә китә. Син мине озатырга киләсеңме?

— Киләм. Кайтуга ук будильникны куячакмын.

— Ә уянмасаң?

— Уянмаска ни, әни кичә муллалы сәгать алып кайтты. Батарейкасы бетмичә, мулла азан әйтүдән туктамый...

— Петербургка барып җитүгә, мин сиңа хат язармын.

— Көн саенмы?

— Көн саен.

— Петербург — зур шәһәр. Мине онытырсың кебек, Айсылу.

— Онытмам, Рафис.

— Карарбыз.

— Син нәрсә, инде көнләшә дә башладыңмы?

— Көнләшәм шул. Анда чибәр егетләр күп.

— Син бит үзең әйткән идең, эт елында туган кызлар однолюб булалар дип.

— Йолдызнамәгә ышанмыйм мин.

— Ә миңа ышан, Рафис.

— Җибәрәсе килми сине, Айсылу!

— Дөнья тоташ аерылышулардан һәм кавышулардан тора. Түз!

— Кем әйтте сиңа бу сүзне?

— Бер шагыйрь шулай дип язган... Мин киттем?

— Кит.

— Кара аны, йоклап калсаң, үпкәлим!

Кыз үзләренең подъездларына кереп югалгач, Рафис, татлы хыялларга чумып, Ерганак урамына юл тотты. Нинди конвертта килер икән аңа хат? Айсылу канәфер чәчәкләрен ярата. Мөгаен, аның тышында канәфер чәчәге сурәте булыр. Яратам дигән сүз булыр микән анда? Булыр, һичшиксез, булыр. Ул барысын да тәфсилләп сурәтләргә ярата. Мөгаен, хатның яртысыннан күбрәген Петербург тормышына багышлар. Ә ул нәрсә дип язар икән? Белми, күз алдына да китерә алмый. И, нәрсә баш ватарга! Ни генә язса да, Рафис үзенең иң эчкерсез, иң саф хисләрен җиткерергә тырышачак инде. Һе, ул тиле хисләрне каләм белән генә язып аңлатып булмый шул. Нәрсә ул сүз? Гап-гади бер авазлар тезмәсе! А, б, в, г, д, е... Шул авазлар тезмәсе ярдәмендә бөтен дөнья аралаша. Кайбер хисләрне тел белән дә аңлатып булмый. Кайвакыт бер генә күз карашы да әллә ниләр аңлатып бирә.

Дөнья кызык иде әле Рафиска. Чөнки ул яшь, чөнки аның тормышы әле башланыш кына килә.

## План кирәк

Төн уртасында сузып-сузып эт улады. Аңа ияреп, күрше урамнарда яшәүче этләр дә чәңгелдәшеп өрергә керешге. Митәйләр Әнгәсе бу. Юкка гына уламыйдыр, эт уласа, адәм башына улый, дигән борынгылар. Әнгә ач түгел, аны бөтен урам туйдыра. Йорттан йортка йөреп, тамак туйдырган көтүче малай кебек ул: бүген бер йорт капкасын, иртәгә икенче йорт капкасын килеп исни. Чөнки белә, хәзер хуҗа хатын аңа йә сөяк, йә калган аш чыгарып бирәчәк. Моңа кадәр ул үзенең җиде көчеге белән подвалда яшәде. Кышын берсе тапталды, өчесен аттылар. Ә хәзер менә куышы да юк, аңа сукбайлар хуҗа. Исән калган көчекләр инде шактый олыгайды, хәзер кайда да булса үләксә эзләп йөриләрдер. Бик күп этне кырдылар бу кышны... Явызлана адәм баласы!

Чү! Айвазовский урамы ягыннан болайга таба борылып, иши машинасы килеп туктады. Юк, җил иши исен алып килми, милициядер бу. Алар Ерганак урамында еш була.

Ялгышмады Әнгә, кузовтан аркаларына карабин аскан бер-

ничә адәм сикереп төште. Маэмай, үзен туйдыручы ерганаклыларның ышанычын аклау өчен, һич югында, өреп куярга тиеш иде. Ләкин бу юлы базмады, чөнки милиция белән бәйләнешергә ярамаганын яхшы белә. Өреп караганнар иде инде, унлап этне автоматтан кырып салдылар.

Төн кунаклары инде дөбер-шатыр капка кага:

— Ачыгыз, милиция!

— Нәрсә булган анда? — Хуҗа хатын тавышы. — Үтергәннәр мәллә берәресен?!

— Рафис Гайсин өйдәме?

— Әстәгъфирулла! Ул нигә кирәк сезгә мондый кара төндә?

— Мин сезне аның әнисе дип аңладым, дөресме?

— Дөрес, кәнишне.

— Алайса, капкагызны ачыгыз!

— Ачмый торыйм әле менә, Алла белгән, бәлки, сез мине таларга җыенасыздыр.

— Сезне берәү дә таларга җыенмый, апа. Мин милиция лейтенанты Козырев булам. Ә янымда Вахит районы хәрби комиссариаты хезмәткәре лейтенант Сомин басып тора.

— Йомышыңны әйт, энем.

— Сезнең улыгыз кичә хәрби комиссариатта булырга тиеш иде.

— Булса соң, тиеш нәрсәләр күп бу дөньяда. Бердәнбер малаемны Чечняда үтертер хәлем юк. Әнә Казанга цинк табутларны кайтарып кына торалар. Боевик дигәннәре үтермәсә, үзебезнекеләр үтерә. Башта тәртип кертегез армиягезгә.

— Апа, сезнең малаегызга унсигез яшь. Армиядә хезмәт итү аның изге бурычы. Аңладыгызмы?

— Аңламадым һәм аңларга да теләмим. Ниткән бурыч ул тагын? Улымны үстергәндә мине хөкүмәт бар дип тә белмәде. Ничек үстергәнемне үзем генә беләм. Аена биш йөз тәңкә заршлаты алам мин, вәт. Аның белән бала киендерәсеңме, үзеңне карыйсыңмы? Изге бурыч, имеш. Үсеп җитеп ярдәмчем булды дигәндә генә улым кирәк булдымы?

— Ачыгыз ишекне! Юкса улыгызга җинаять эше кузгатылачак.

— Ачмыйм, үтерсәгез дә ачмыйм!

Шул сүз җитә калды, берничә милиционер капкага үрмәләде. Коты очкан хуҗабикә шундук үрсәләнеп еларга тотынды:

— Юк, бирмим улымны!.. Менмәгез капкага, җимерәсез бит!.. Улы-ым, кач!

— Әни, елама, зинһар! — Малае йөгереп чыккан икән. — Бер мине генә алмыйлар бит армиягә.

— Улы-ым!.. Шушы иблисләр кулына бирер өчен үстердеммени мин сине-е-е!

Капканың эч ягында ыгы-зыгы китте:

— Җибәрегез аны! Җибәрегез, дим!
— Тынычлан әле, апа, буза куптарма! Малаеңны суярга җыенмыйлар бит.
— Улы-ым!
Ниһаять, капка ачылды.
— Узыгыз, иптәш лейтенант!
— Молодец, Рәхмәтуллин!.. Исәнмесез, апа! Мин милиция лейтенанты Козырев булам. Хәзер хәрби комиссариат вәкиле господин Сомин сезнең белән собеседование ясап алачак.
— Собеседование ясап торырга вакыт юк. Гражданка Гайсина, сезнең улыгыз иртәгә көндезге сәгать унбердә иптәшләре белән Екатеринбургка юл тотарга тиеш.
— Бирмим улымны! Бирми-и-м!
— Китегез, комачау итмәгез, апа! — Бусы милиция лейтенанты тавышы. — Ә син, иптәш призывник, бар, тиз генә биштәреңне җый!
— Минем инде барысы да әзер, менә минем биштәрем. Белдем мин сезнең киләсегезне.
— Каян белдең?
— Соң, мин телевизор карамыйммыни?
— Ышандырдың. Әниеңне бер кочаклап үп тә киттек.
— Әни, елама, зинһар! Сугышка озатмыйсың бит. Бөтен кеше дә үлеп бетми, ике ел уза да китә ул. Айсылуны озата алмадым инде. Частька барып җиткәч, хат язармын үзенә.
— Ярый, ярый, балакаем. Бу иблисләрдән болай гына котылып булмый инде. Тукта, суыткычтагы теге тавыкны салып җибәрим. Бүтән нәрсә юк, юлда кирәк-яракны алырга акча да бирә алмадым. Һаман да шул хәерчелек инде, кичер! Зөлфияне дә уятыйм, юкса, абый саубуллашмыйча китеп барган, дип үпкәләр.
— Уятма, кирәк түгел!
— Әйе, дөрес әйтәсең, улым, бу халыкны күреп куркып калуы бар. Хәзер, тавыкны гына алып чыгам да…
Хуҗа хатын өйгә кереп китүгә, хәрби комиссариат вәкиле Рафисның аркасыннан сөеп алды.
— Молодец, энекәш. Башкаларны тимер beләзек белән алып китәргә туры килә иде, ә сиңа киертеп тормабыз, ахрысы, бик тыныч күренәсең. — Аннары ул, тамак кырып, акланырга тотынды. — Син безне дә аңла инде, энекәш, призывниклар артыннан чабып йөрү бер дә рәхәт түгел. Йокы күргән юк бу арада. Акчасы булганнар качып йөрми, утыз меңен чыгарып сала да… Ыһм, дөньясы шуңа калды, понимаешь. Противно, конечно, об этом говорить.
Ун-унбиш минуттан барысы да машинага төялеште. Рафис бүген утызга якын призывник белән район милициясе бүлегендә — КПЗда йоклаячак. Шуннан барысын да вокзалга алып китәчәкләр.

Каталашка акрын гына урамның аскы ягына юл алды. Планны тутырыр өчен, тагын берничә егетне эләктерергә кирәк иде әле. Шул рәвешле бу төндә Ерганак урамында таңга кадәр капка кактылар.

## Илфак язудан баш тарта

Милиция китеп баргач, Әнгә иртәнге җилгә борынын куеп тагын иснәнә башлады. Көчекләрнең шактыйдан бирле тавыш-тыны юк. Ел да шулай, аяк астында буталып йөриләр дә көннәрдән бер көнне кинәт юкка чыгалар. Хәер, күнекте инде ул бу хәлгә. Бераз шулай шыңшып йөри дә соңрак барысы да онытыла, көзгә тагын берничә көчек дөньяга килә. Шундый булырга тиештер, мөгаен, эт тормышы: ана эт үзенчә, көчекләр үзенчә. Исән калу, үсү, тернәкләнү — һәр маэмайның үз эше. Хәзер адәм баласы да шул рәвешле яши. Ата-ана бер якта күңел ача, балалар урамда теләнә. Бигрәк тә шәһәр җирендә гадәти күренеш бу. Дәүләт белән дә шул ук хәл, ул үзенчә, халык үзенчә яши.

Әнгә гасабиланып шыңшыган арада, җиргә сеңгән йорт тәрәзәсеннән такыр гына адәм башы күренде.

— Ә-ә, син дә йокламыйсың икән әле, маэмай, — диде ул, авызын ерып. — Кил монда, герой ана, сөяк бирәм.

Әнгә йөгереп килгән шәпкә тәрәзәдән очкан сөякне эләктереп алды да аны ырылдый-ырылдый кимерә башлады. Бер күзе сөяктә, икенче күзе — Илфакта. Адәм баласын белмәссең, сөяк биргән булып, муенга бау киертеп куюы да бар. Мәрхүм хуҗасының янган подвалында яшәүче сукбайлар да чак кына чылбырга утыртмадылар үзен. Чит кешеләргә өрер өчен түгел, әлбәттә. Берничә атна эчендә якын-тирәдәге мәчеләрне дә ашап бетерделәр алар.

— Ничә көчек китердең инде син? — диде Илфак, эткә кызганулы караш ташлап. — Бөтенесен дә кушып санасаң, кырыклап бардыр, малай, ә? Бичаракай, көчекләреңне сукбайлар тотып ашаганын белмисеңдер әле. Куркыныч дәүләттә яшибез. Бу дәүләт үзе дә сукбай. Сәгате җитүгә, ул изге бурычларын искә төшереп, унсигез яшьлек малайларны сугышка озата. Нәрсә хакына, нигә? Моны ул үзе дә белми. Бу малайларның ничек, нәрсә ашап үскәнен дә белми. Менә бүген дә төне буе никрутларны аулап йөрделәр. Сәп-сәламәт килеш алып китәләр дә инвалид итеп кайтаралар. Исән-сау кайта алса, кәнишне.

Әнгә Илфакның нәрсә әйткәнен аңламаса да, аның нииндидер хәвефле хәбәр әйтүен сизде булса кирәк. Акрын гына шыңшыды, борынын җилгә куеп, тагын иснәнә башлады. «Теге подвалны әйләнеп кайтырга кирәк, — дип уйлады ул. — Бу юлдан язган адәм балалары, мәче итен ашагач, көчек итеннән генә баш тартмаслар».

— Эт тормышы бу, дустым, — дип дәвам итте сүзен Илфак, тәмәке кабызып. — Менә мин бүген төне буе шигырь язып утырдым. Күпме түлиләр дип беләсең инде аның өчен? Булса, шул йөз тәңкә чамасы булыр. Ә аңа, ачуым килмәгәе, бер күлмәк тә сатып алып булмый. Көнбатышта бер шигырь язган кеше ике атна эшләмичә ята ала. Журналистларның да хезмәт хаклары чәчең үрә торырлык. Гап-гади бер мөхбирнең хезмәт хакы җиде мең доллардан артып китә анда. Ә без андый акча ала башласак, ни эшләр идек икән? Акылдан язар идек, валлаһи. Җитте, язмыйм бүтән. Шигырь язып кына дөньяны матурлап та, баеп та булмый. Безгә кадәр дә язганнар, бездән соң да язарлар, ә дөнья ул үз юлы белән бара.

Бездән соң да ышанырлар ул Аллага,
Бездән соң да табынырлар ул Шайтанга...

Шәп әйтелгәнме?.. Хакыйкать шундый, брат. Яшь чакта адәм баласына ай белән йолдызлардан башка берни дә кирәкми. Ул зәңгәр хыяллар диңгезендә адашып йөри, дөньяда дөреслек барлыгына, аның тантана итәсенә ышана. Ә кырыкның теге ягына чыккач, җиргә төшәсең икән. Юк җирдә дөреслек. Анда ялган көчлерәк. Чөнки ялган матур ул, ә дөреслек — һәрвакыт шыксыз була. Мин дә инде җиргә төштем. Мин дә инде җиргә өзелеп төшкән алмадай каралдым. Каралуны үзең беләсең инде, ул — бозыла башлау билгесе.

Әнгә, сөяк кимерүдән туктап, шагыйрьнең сүзен хуплагандай, ырылдап куйды.

— И-их! — Илфак, авыр сулап, бармакларын өтә башлаган төпчекне тәрәзәдән болгады. — Син миннән бәхетлерәк, Әнгә. Сиңа бәхетле булыр өчен бер сөяк җитә. Ә миңа сөяк кенә җитми. Мин бит адәм баласы, миңа рухи азык та кирәк. Бүген «Татар радиосы»ннан бер сәгатьлек тапшыру яңгырады. Миннекәев кояшның теге ягында булып кайткан, имеш. Ул мизгел эчендә кешенең башын, йөрәген һәм башка эчке әгъзаларын алыштыра, имеш. Миннекәев быел илгә яңгыр китергән, имеш. Кыскасы, яңа Гайсә йөри безнең арада. Көлкеме? Көлке түгел бу, брат, бер дә көлке түгел. Милли фаҗига бу. Акылга туймаган кеше сөйләгәннәрне авыз ачып тыңлап утырабыз икән, димәк, без үзебез дә авыру. Адәм көлкесе, гәзитләрне өпкереп подписка ясый башладык бит хәзер. — Илфак койрыгын боргалап утырган Әнгәгә тагын бер сөяк ыргытты. Ләкин бу юлы маэмай сөяккә иелеп тә карамады. — Тыңламыйсың мине, маэмай. Сөяк тә кимермисең… Әллә үпкәләдең дә? Йә, ярый, мине үз-үзе белән сөйләшә дип уйла. Шундый инде без, иҗат кешеләре. Уйлаган адәм баласына икеләтә авыр бу дөньяда яшәүләре. Кайвакыт акылдан язар дәрәҗәгә җитәсең. Менә шундый имеш-мимешләргә ышанып, үзебезнең наданлыгыбызга, беркатлылыгыбызга куанып яши торган

халык без. Хәйдәр Бигичев, Таһир Якупов кебек бөек җырчыларыбызны кабергә тыккан, бер көнлек һәвәскәрләргә чәчәк өйгән халык без. Иренмәгән һәр кешене — экстрасенсны экстрасенс, им-томчыны им-томчы, генералны генерал булганы өчен генә — Язучылар берлеге әгъзасы итеп ала торган халык без. Иренмәгән һәр кешенең — клуб хезмәткәренең, ике-өч җыр язган һәвәскәрнең бенефисларын зурлап, күккә чөеп үткәрә торган халык без. Арабыздан фаҗигале рәвештә киткән бөек юморист Фаил Шәфигуллинның серле үлемен, хәбәрсез югалган шагыйрь, шәп шагыйрь Эдуард Мостафинның язмышын ачыкларга иренгән халык без. Элегрәк аны коммунизмга барабыз дип алдадылар, хәзер демократик җәмгыять төзибез дип алдыйлар. Ун ел чамасы яшәп калган милли суверенитет дигәннәре дә берничә кеше өчен генә булды. Тирәнгә кереп китмим, боларны һәркем яхшы белә. Алла бирсә, киләчәк буын да белер. Чөнки тарих хатирәләр, хатлар, мәкаләләр, документлар, архивлар рәвешендә барысын да теркәп-туплап килә, чөнки тарих кыйналудан, үтерелүдән, эштән куылудан, эзәрлекләнүдән курыкмый, чөнки тарих — ул иң гадел һәм иң кырыс хөкемдар. Күреп торырсың, бүген макталган, бүген күккә чөелгән, бүген төрле дәрәҗәле премияләргә, исемнәргә лаек булган кешеләрнең күпчелеген иртәгә инде беркем дә белмәячәк. Чөнки бу илдә намус сатмыйча бернәрсәгә дә ирешеп булмый, чөнки бу илдә бөтен нәрсә дә — исем дә, абруй да, мәкалә дә, әдәби әсәр дә, фәнни диссертация дә — фәкать корсак өчен һәм фәкать бер кеше гомере озынлыгына гына эшләнә, чөнки бу илдә кичәге ватандарлык иртәгесен ахмаклык, кичәге каһарманлык иртәгесен тилелек булып санала, чөнки бу илдә баш иеп кенә, күргәнеңне күрмәмешкә салышып кына Кеше булып калу мөмкин. Чөнки бу илдә берни дә киләчәк буыннар хакына эшләнми. Чөнки бу илдә фәкать түрәләр бәхилләве белән генә халык язучысы, халык шагыйре, халык артисты булырга мөмкин. Чөнки... бу илдә чын шәхесләрне инде күптән кырып бетерделәр.

Илфак кинәт тынып калды. Чөнки аны тыңлаучы юк. Хәтта Әнгә дә әкрен генә аскы урамга таба титаклады. «Этне сөяк белән алдасалар, безне колбаса белән алдадылар, — дип уйлады ул, тәрәзәне ябып. — Ирештек рәхәткә, кибеткә музейга йөргән кебек йөрибез. Язмыйм бүтән!»

Шагыйрь сервантта торган дипломнарын, Мактау грамоталарын идәнгә томырды. Аларны аңа «Якты җомга» газетасында эшләгәндә биргәннәр иде.

— Кемгә кирәк бу макулатура! — дип мыгырдады ул үзалдына. — Наркоманиягә каршы язылган иң яхшы мәкаләгә конкурс, имеш. Журналист өчен тагын бер мескен акча эшләү юлы. Мәкалә белән генә җиңеп булмый наркоманияне, аның өчен каты закон кирәк, эшли торган закон кирәк!

Дипломнарны мичкә тутыргач, Илфак иске кәнәфигә чумып тынып калды да тагын тәмәке кабызды. «Гомер бер генә, аны болай тәмәке төтененә исереп, сасы бүлмәдә үткәрергә ярамый, — дип уйлады ул. — Ләкин нәрсә эшләргә? Заводка барыргамы? Анда айлар буе хезмәт хакы түләмиләр. Авылга кайтса да шул ук хәл, анда акча дигән нәрсәне онытып бетергәннәр инде. Сабантуйга йөз тәңкә биргәннәр бугай бирүен. Адәм баласын мәсхәрә итү бит бу. Йөз грамм колбасага да җитми хәтта. Ә авылда ишле гаиләләр күп, аларны киендерергә дә кирәк. Коллык менә шушы була инде ул. Яз җиттеме, мәктәпне тәмамлаган балаларның ата-аналары кара кайгыга бата. Баланы югары уку йортына урнаштыру өчен акча кирәк. Юридик факультетка әнә йөз илле меңнән дә ким алмыйлар. Авыл хуҗалыгы академиясенә илле мең чамасы түләргә кирәк. Шуннан соң нишләсен инде авыл кешесе, кемгә дә булса муеннан бурычка бата, абзардагы малын суя.

Шушы хәерчелек аркасында Илфак өйләнмичә дә калды инде. Дөбердәтеп бер туй ясарлык рәтең булмагач, ничек хурланмыйча өйләнергә? Шәһәрдә кияүгә чыга алмыйча калган ялгыз хатыннар да күп югыйсә. Ләкин алар Илфакта нык шик тудыра. Гадәттә, мондый хатыннар йә бик ямьсез, йә чирле, йә җилбәзәк булып чыга. Ә кайберләре картаеп бөкресе чыкканчыга кадәр бай кияү көтә. Дөрес, арада тәкъвалары да бардыр, әмма аларны кем карап-тикшереп йөргән?

Әллә ниләр уйлап бетерде Илфак. Чечняга контракт буенча китеп барган абыйсын да бераз кызганып алды. Кәбир беренче рус-чечен сугышында да катнашкан иде. Акча өчен китмәде. Эшендә торгызмаслармы, дип өметләнде, бахыр. Ләкин район эчке эшләр бүлегенең кадрлар бүлеге начальнигы Билкәев документларын нык пычраткан булып чыкты. Аннары, дөрестерме, юктырмы, министр, Чечняда булганнарны милициягә эшкә алмаска, дигән яшерен күрсәтмә биргән, дип тә сөйләделәр. Чөнки тормыш күпләрнең бу сугыштан кешелек сыйфатларын югалтып кайтуын, аларның психик яктан сәламәт булмауларын бер генә тапкыр расламады инде.

Мисал өчен, биш-алты ел элек берәү, Чечнядан кайткач, үз фатирында граната шартлатып һәлак булды. Кызы ташлаган өчен шулай үч алган, юләр.

Кәбир ничә еллар милиция отличнигы булып торды югыйсә. «За безупречную службу» дигән медален дә Билкәев пенсиягә киткәч кенә бирделәр. Өстәл тартмасында качырып саклаган, мөртәт. Хәзер башын эчүгә салган, дип сөйлиләр. Казан юлында исерек килеш берәүне машина белән дә бәрдергән икән. Кәбирне юкка гына эзәрлекләмәде ул, район прокуроры кушуы буенча эшләнде барысы да. Чөнки милиция лейтенанты аларның кайбер кырын эшләрен яхшы белә иде. Мисал өчен, япүсмер кызны көч-

ләгән район киночелтәре директорының аларга акчалата ришвәт бирүен дә белә иде. Күп булды инде андый кырын эшләр. Ялган шаһит табып, участковый Мирзаяновны аңа карата көч куллануда гаепләделәр. Суд булды. Шартлы рәвештә ике елга ирегеннән мәхрүм иттеләр. Мондый биографияле хезмәткәрне кем милициядә тотсын? Кудылар, әлбәттә. Акланырга тыпырчынып карады каравын, ләкин сыйрагы сыеграк булып чыкты. Министрлыкта Билкәевнең туганнан туган абыйсы эшләгәнен белми иде әле ул.

Кәбирне беренче сугышка озатканда, Илфак бераз гына дулап та алган иде.

— Мөселманга каршы барасың, акылыңа кил! — дип орышып та ташлады.

Ә тегенең үз туксаны туксан. Урыс мәктәбендә укыды шул, бераз татарлыгы булса, болай эшләмәс иде. Вокзалда абыйсына егерме япьле пычак сатып алды Рафис. Юлга чыккан кешегә, исәнсау әйләнеп кайтсын өчен, пычак бүләк итәргә кирәк, дигән сүзне ишетеп белә иде ул. Кем уйлап тапкандыр, бу кадәресен белми һәм белергә дә теләми.

Бик каты сугыш бара иде ул вакытта. Көннәр буе телевизордан күрсәтеп торалар. Россияне тезләндергән чеченнар ягында иде халык. Барысы да илне шушы мескенлеккә төшергән сатлык генералларга, сатлык министрларга ачулы иде.

Бер ай узмады, чеченнар Грозный шәһәрен алдылар. Кәбир җимерелгән бер йортта энекәше әйткән сүзләрне искә төшереп елап утырган, исән калсам, гел өйдә генә утырыр идем, дип антлар эчкән. Боевиклар белән йөзгә-йөз очрашмаган үзе. Машина белән корал ташыган ул.

Яңа ел алдыннанрак, Илфак төш күрде. Имеш, аның абыйсы Кәбир капка төбендә басып тора. Хәрби киемнән. Тик чәче иләмсез озын. Соңыннан белде, бу вакытта аларның полкын Буденныйга чыгарганнар икән. Шәһәр читендәге бер басуда лагерь оештырганнар. Палаталар юк, ашату да юк дәрәҗәсендә. Ике йөз контрактник баш күтәрә. Ләкин артык сикерә алмыйлар, ярты сәгать тә узмый, ике йөз кешене танклар әйләндереп ала. Йә тынычланасыз, йә шушында барыгызны да турап ыргытабыз! Буйсыналар.

Тагын ике айдан, төнлә кайтып керде Кәбир. Илфак үз гомерендә беренче тапкыр тере фронтовикны күрде. Дары исе сеңгән дигән сүзнең мәгънәсен хәзер генә аңлады ул. Кояштан түгел, кердән каралып беткән абыйсы. Ә бетнең исәбе юк. Чәче генә түгел, бишмәте дә бетләп беткән иде. Ярый әле үзендә беткә каршы шампунь булды, юкса югалып калган булыр иде.

Кәбир белән төне буе аракы эчтеләр. Чәчләр үрә торырдай нәрсәләр сөйләде ул. Бер контрактникның җимерекләр арасында калган коляскадагы баланы ничек штыкка күтәрүе турында да әйтте. Үзе күрмәгән, әлбәттә. Иптәшләре сөйләгән. Соңыннан

хезмәттәшләре ул егетне үзен дә дөмектергәннәр. Кеше күзенә күрсәтеп түгел, әлбәттә. Мондый эшләр яшерен эшләнә.

Әшәкеләнде Рәсәй солдаты. Фашисттан кимен куймый. Кая ул солдат кына, командирлар да азды. Полк командиры Буданов әнә унҗиде яшьлек кызны мәсхәрәләп үтерде. Арт юлына көрәк тоткычына кадәр тыккан. Чечняда шулай конституцион тәртип урнаштырмакчы булды микәнни?

Элегрәк журналистлар мондый хәлләр турында курыкмыйча сөйлиләр иде. Хәзер телевидение дә, радио да Чечня турында бик сирәк сөйли. Әйтерсең анда инде тормыш җайланыш килә. Алдау бу, халык башын катыру бу! Күрәсең, аларга артыгын сөйләмәскә дип яшерен күрсәтмә бирелгән. Информацион сугышны отсак, бусын да отабыз, имеш.

Совет чорында Әфганстанны да бик сирәк күрсәтәләр иде. Күрсәткән кадәресе дә совет илен идеаллаштырган материаллардан гына торды. Имеш, Кабулда фәлән кадәр мәктәп, балалар бакчасы төзелгән, тирә-юньдә бәхетле елмаеп укытучылар, ата-аналар басып тора. Баксаң, халык кабул итмәгән икән Әфган революциясен, советларга каршы партизан сугышын башлап җибәргән.

Таң алдыннан икесе дә исереп беттеләр. Кәбир күкрәгендәге медальне аяк астына салып таптый башлады.

— Будь проклята эта война! — дип елады да елады.

Илфак та медальне сөенә-сөенә таптады. Соңыннан аны юынтык су чиләгенә томырдылар.

Айныгач, Кәбир медальне эзләргә кереште. Үземә кирәк булмаса да, министр янына тагып керергә кирәк, дигән була.

Төкерәләр анда синең медалеңә. Шул килеш Кәбир тагын өйдә ятарга мәҗбүр булды. Башка эштә эшлисе килмәде, хурланды. Хатыны белән дә бозылышып бетте. Каты эчте шул. Инде аерылышыр дәрәҗәгә җиткәннәр иде.

Быел, ниһаять, Кәбир тагын Чечняга китәргә булды. Үзен аклау өчен түгел, акча өчен китте.

Бу юлы Илфак аны вокзалга озатырга бармады. Мөселманның мөселманга каршы баруын теләми ул. Октябрь инкыйлабыннан соң Урта Азиядәге басмачларга каршы татбригадалар оештырып та зур ялгышлык эшләдек без. Рәсми рәвештә хөрмәтләсәләр дә, гади халык һаман эт итеп сүгә үзебезне.

Әрәм көчләр, әрәм гомерләр! Һәм менә татарны тагын файдалана башладылар. Бу юлы Чечняда инде. Ай саен эшелоны белән милиционерлар китә генә тора. Кайчан да булса вайнахларның оныклары да йөзебезгә төкермәгәе.

Шулай уйланып утыра торгач, Илфак йокыга киткәнен дә сизми калды. Тәрәзә ачык булу аны куркытмый, чөнки өйдә карак урлардай җиһаз да, савыт-саба да, телевизор да юк. Дөрес, шәхси китапханә шактый бай күренә. Әмма карак аның белән вакланмас. Шәһәрдә хәзер һәр чатта китап саталар.

## Колонка янында

Сәкинә төне буе йоклый алмады. Сәгать сигезне суккач, ул йөрәге сикергәнгә чыдый алмыйча, чиләк-көянтәсен күтәреп, чаттагы колонкага юнәлде. Әгәр бүген төнлә улы артыннан киләселәрен белсә, ул аны авылга — абыйсы янына кайтарып куя иде. Өлгермәде, каһәр. Элек армиядә хезмәт итмәгән егетне егеткә санамыйлар иде, ә хәзер армиядә хезмәт итүчеләргә мескен итеп карыйлар. Дөресе шул, хәзер хәерче малае гына армиядә хезмәт итә. Акчасы булганнар әнә «джип»ларда гүләйт итә, төнге дискотекаларга йөри, кызлар белән типтерә. Алай дисәң, элек тә шул иде инде. Әфганга әнә бер дә начальник балалары бармады. Чечнягага да җибәрмәделәр балаларын. Намус калмады кешедә, ахырзаман җитә, ахрысы. Җыен бандит типтереп яши, көне-төне эшләгән кеше бер тамагын туйдыра алмый. Кичә берәү сөйләп торган иде. Имеш, «Сәфәр» ресторанында бер әбәт ашап чыгу да егерме меңгә төшә икән. Җилдән акча кермәсә, андый акча туздырып йөрмәс адәм баласы. Эшләп алган акчаның кадере зур була аның.

Колонка янында көянтәләрен асып ләчтит сатып торган кәрлә Люда белән юан Таняны күргәч, Сәкинәгә җиңелрәк булып китте. Кайгы-хәсрәтне уртаклашырдай кеше бар, ичмаса, урамда. Татарлар шулай атый аларны. Чөнки мондагы Танялар һәм Людалар дистәдән артып китә. Икесе дә быел гына сабын заводында эшләп пенсиягә чыкты.

Сүзне беренче булып Таня башлады:

— Как дела, Сакина?

— Улымны төнлә армиягә алып киттеләр, каһәрләр!

— Слышали, все слышали. Всю ночь барабанили ворота, гады! Еле заснула. — Аннары Таня татарчага күчте. Монда һичбер гаҗәпләнерлек нәрсә юк, алар икесе дә шушы урамда, татарлар арасында туып-үскән хатыннар. — Менә заманалар, ә! Илне сакларга кеше таба алмыйлар, сволочьлар.

Таняның балалары булмады. Хәер, ул да, ире дә аны кирәксенмәделәр кебек. Бала кирәк булган кеше җир читенә барып җитә. Һич югында, берәр ятимне алып тәрбияли. Ире өченче ел гына эчеп үлде. Һәм кирәк бит, чәчәк ата башлады Таня. Көн дә йортка бер мужик кертә. Соңгысы әнә «мой Колобочек» дип кенә йөртә иде үзен. Барыбер куып чыгарды. Сәбәбен сораша башласаң, яшәп калырга кирәк, дип кенә җиффәртә.

Урыс хатыны тагын берничә зәһәр сүз әйтергә дип авызын ачкан иде, сүзгә Люда килеп кысылды:

— Родину защищать, понимаете-ли. Какую родину? Син моны Ватан дип саныйсыңмы?.. Ха-ха-ха!.. Кодрәтемнән килсә, мин аны бүген үк бүлгәләп, бер өлешен Америкага, икенчесен Кытайга, дүртенчесен финнарга сатар идем. Цивилизация килер иде,

ичмасам. Яшәргә, эшләргә, байлыкларыбызны сакларга өйрәнер идек. Ә Россиядә талый гына беләләр. Сицилия мафиясе әнә талый да белә, гади халыкка да ярдәм итә. Ә бездә мафиясе дә мафия кебек түгел, жмотлар, хайваннар барысы да.

Люда заманында бик күп егетнең башын әйләндергән хатын. Күзләре әле дә зәп-зәңгәр. Тик аракы аны инде тәмам киптереп бетергән. Алган пенсиясен ире, малае, килене белән бер төндә эчеп бетерә. Аракыны денатурат алыштыра, бәйрәм якынча атна буе дәвам итә. Аннары барысы да кайсы сумка, кайсы капчык асып, шешә җыярга чыга. Урамда аның ирен Кыек Муен дип йөртәләр. Чөнки калтырап торган башы бер якка гына карап тора. Уллары Толик төрмәдә утырып чыкты. Базарда закускага берәүнең ике помидорын талап алган өчен, дип сөйләделәр. Әти-әнисе белән сүгенмичә, акырмыйча сөйләшә алмый. Ләкин аракы эчәргә яраткан татар ирләреннән аермалы буларак, беркайчан да сугышмый, балта күтәрми.

— Дөрес, дөрес, — дип җөпләп куйды аның сүзен Сәкинә. — Чит илдә этнең дә кадере бар. Ә бездә… Аскы урамда яшәүче Матрена түтәйне генә алыйк. Ул җиде малаен сугышта югалткан кеше. Ә аны искә алучы да юк. Әллә исән, әллә үлгән, беркем бернәрсә белми. Без бөтен урам белән туйдыра торган Әнгә дә аңа караганда мең тапкыр бәхетлерәк. Матрена түтәйгә кемнең нәрсә биргәне бар?

— Коммунистлар вакытында янына хет тимурчылар килеп йөри иде. Молодец, что напомнила, Сакина. Кереп чыгасы булыр бүген… Нинди илне саттылар бит, әй! — дип сукрануын дәвам итте Люда. — И-их, Сталинны терелтергә-ә!

Аның кызып-кызып сөйләгәнен тыңлап торгач, Таня кычкырып көлеп җибәрде.

— Хорошо говоришь, Людмила! Телевизорга чыгарырга кирәк сине. Йә депутат итеп сайларга кирәк.

— Карагыз әле, кызлар, телевизор дигәннән, кичә мин «Перехват» программасын карамыйча калганмын бит, — диде Люда, сүзне икенчегә борып. — Берәр кызык нәрсә күрсәттеләрме, юкмы?

— А, ничего интересного. — Таня эшлекле кыяфәт белән башындагы яулыгын рәтләп куйды. Аны биш-алты ел башыннан салмый инде ул.

— Что, в городе вчера так никого и не убили? Не может этого быть. Ишеткәнсездер, Дәрвишләр бистәсендә ун-унике яшьлек өч малай бер детдом баласын чәнчеп үтергән. Бүген телевизордан күрсәтерләр, ахрысы.

— Күрсәтәләр, кәнишне, — диде Сәкинә. — Кан никадәр күбрәк, телевизионщикларның рейтинглары да шуның кадәр югарырак. Һы, кызык күрсәтәләр, имеш.

Таня шундук аның сүзен эләктереп алды:

— Турысын гына әйткәндә, Сакина, чыннан да, шуннан кызык табабыз бит инде. Боже, прости! Кайвакыт мин үземнең нормаль кеше булуыма шикләнеп куям. Ие, шикләнеп куям, кызлар. Берәрсен үтерсәләр, җанга рәхәт булып китә. Хәтта ашетит күтәрелә башлый. Ниндидер бер маньякка әверeләм кебек. Сезнең белән шундый хәл буламы?

— Әлбәттә, була, — диде Люда, күзләре ут булып янып. — Бигрәк тә берәр түрәне чәпесәләр рәхәт булып китә. Минем ирем, «Вести» программасын карый башласа, ил башын күрүгә үк котырына башлый: «Таня, когда начнем расстреливать этих гадов?!» — дип акырына. Ярый әле аракы бар, шуның сөреме белән онытылып яшибез. Юкса йөрәк чыдамас иде.

Марҗа әйткәннәрдә хаклык бар. Һәр тарафта наркомания, эчкечелек, фахишәлек, ришвәтчелек, алдаш, талаш, үтереш хөкем сөргән шәһәрдә халык та нык үзгәрде. Ул көн саен түземсезлек белән «Эфир» каналы күрсәтә торган «Перехват» тапшыруын көтеп ала, андагы үтереш-суеш турындагы сюжетларны карап, яшерен ләззәт ала. Әйтерсең шул рәвешле үзен алдаган, хәерче хәлендә калдырган ахмак дәүләттән үч ала.

Сөйләшә торгач, хатыннар тәмам кызып китте:

— Халык — сарык ул, сарык булмаса, аны гасырлар буена алдый алмаслар иде, — диде Таня, җиргә төкереп. — Аны Мавродийлар да, Кашпировскийлар да алдый алмас иде. Аңгыра бит без, акылы булган кешеләр үз ваучерларын «Татнефть»кә тапшырды, машиналар алды. Ә без сатып эчтек.

— Социалистик милекне бүлеп бирделәр, имеш. — Сәкинә kahkahә белән авызын ерып куйды. — Ваучерның нәрсә икәнен аңлатып бирмәделәр ич. Мин дә саттым ваучерымны, акчасына су ташырга дип бер бидон алып калдым. Анысын да наркоманнар мунчадан алып чыгып китте.

— Прав твой муж, Люда, — дип уфылдады Таня. — Сталин терелсә, ни дияр иде икән?

Люда борынын җыерып куйды.

— Сталинмы? Сталин терелсә дә берни кыра алмас иде, душенька моя. Алла каргап киткән ил бу. Америкадан кергән бозыклыкны бернинди себерке белән дә себереп чыгарып булмаячак хәзер.

— Дөрес эшләгән ул барысын да атып. — Таня тел шартлатып куйды. — Шулай эшләмәсә, илгә тәртип кертә алмаган булыр иде.

Люда тәмам кызып китте:

— Если начинать расстреливать, то половину населения надо уничтожить. Иң беренче нәүбәттә илне саткан дәүләт җитәкчеләрен, аннары аларның шестеркаларын, аннары аларга юл куйган халыкны, ягъни синең белән мине дә, Сәкинәне дә атып үтерергә кирәк. Хәтерләмисеңмени, компартия тыелгач, ничек сөенгәнең-

не? Үз башыбызга сөенгәнбез шул. Элекке дәүләт җитәкчеләре үзләре дә яхшы яшәде, безне дә рәнҗетмәделәр. Ә болары көпәкөндез кычкыртып талый. Әллә син Гайдар безнең саклык кассаларындагы акчаларыбызны яндырганда үзенекен долларга әйләндереп куймаган дисеңме? Аннары миңа әйт, ун ел эчендә урлашмыйча гына завод-фабрика сатып алып буламы? Ә бездә алдылар. «Алюминевый король»ләргә кадәр бар бездә. Гади халыкны бер капчык бәрәңге урлаган өчен төрмәгә тыгалар, ә миллионлап урлаган түрәләр, шартлы рәвештә берничә елга ирекләреннән мәхрүм ителеп, өлкә губернаторы итеп сайлана. Кайда булганы бар мондый хәлнең? Кайда дөреслек?!

— Ха! Ты еще правду хочешь искать?

— Ладно, надоела эта политика, — диде Люда, кул селтәп. — Сообразим что-ли?

Танянең авызы ерылды.

— А что, можно, наверное. Суббота, как ни как. Ты будешь, Сакина?

— Миңа ярамый, мин намаз читаю, — диде тегесе кызарып.

Люда аның җилкәсенә төртте:

— Да ладно тебе! Сына в армию проводила, обмыть надо!

— Юк, юк, ярамый миңа, — дип киреләнде һаман Сәкинә. — Аннары аның өчен акча да юк.

— А я вчера стенку продала. — Таня кыланып кына лифчик эченнән илле тәңкә акча чыгарды. — Деньги есть, так что будем пить за мой счет.

Сәкинә ризалык бирүгә, марҗалар, сулы чиләкләрен калдырып, кибеткә чапты. «Ярый, болар юкка гына эчмиләрдер, бераз кайгым басылыр, — дип уйлады татар хатыны, көянтәгә таянып. — И балакай, бик борчылам шул. Интегеп үстер дә ут йотып йөр инде менә шулай».

Марҗалар тиз әйләнеп кайтты.

— Вона, и тетя Матрена идет, — диде сулышы капкан Таня, күлмәк итәге белән тирләгән маңгаен сөртеп.

Люда да әлсерәгән иде. Борынын сеңгереп куйды да башын чайкап кына әйтте:

— Наверное, милостыню просить ходила. Говорят, она на кольце в подземном переходе сидит.

— Не видела.

— Не идет, а тащится. Шутка-ли, девяносто шестой год пошел, как ни как.

Таякка таянган урыс әбие яннарына якынлашкач, Таня кычкырып сәлам бирде:

— Здрасте, тетя Матрена! Как здоровье?

— Да все так же, — дип җавап бирде әби, таягына таянып. — Только вот ноги сильно ноют. Жизнь-то нынче какая пошла, не жизнь, а сущий ад. Старик-то мой счастливым оказался, пораньм

ше меня отошел. Знал бы как я мучаюсь, горькими слезами заплакал бы. А, что жаловаться, все равно легче не станет… Ну, я пошла, да хранит вас господь!

— Мы вас сегодня навестим, — диде Таня, хатыннарга күз кысып.

— Милости просим, заходите, миленькие. А то я одна одиношенькая совсем дикая стала. Радио не работает, телевизор тоже сгорел. Скучно. День как год проходит.

— Спасибо, тетя Матрена! — Таня аракыны Людага тоттырды. — К тете Матрене пойдем. Домой надо сходить, хлеба, лука притащу. У нее, наверное, там шаром кати.

— Да как-то не удобно, — диде Люда, иңнәрен сикертеп.

— Не удобно только на потолке спать. Она только рада будет.

— Как знаешь.

— Мин дә берәр нәрсә эләктерермен, — диде Сәкинә. — Кичә бер килограмм высший сорт мука алып кайткан идем.

Матрена түтәйнең өстендәге иске соры плащы, башына бәйләгән тишек кара яулыгы кызгандырды аны. Сәкинә белгәннән бирле киеп йөри инде ул аларны. Моннан ун ел элек ире шахтада басылып калгач, кайгы уртаклашырга дип кергәндә дә өстендә шул ук плащ иде. Кырыгына бәлеш пешереп кертте, бахыр. Ә Сәкинәнең аны белеп тә караганы юк.

«Менә бит ничек дөнья, — дип уйлады ул. — Тормыш начар, адәм баласы үзе турында гына уйлый, дип зарланабыз. Барысына да үзебез гаепле. Аллаһы һәммәбезне күреп, белеп тора».

**Атышу**

Берәр сәгатьтән Матрена түтәйләр йортыннан урысча җыр агыла иде. Йорт дип әйтеп булмый инде аны. Такта арасына пычкы чүбе тутырып салынган бер утын сараен хәтерләтә иде ул. Ә эчтән йорт алай ук шыксыз түгел. Тәрәзә пәрдәләре, башка чүпрәк-чапрак хәерчелекне бераз каплап тора. Түрдәге сул почмакта тәре, астарак Матрена түтәйнең яшь вакытта ире белән төшкән фотосурәте эленеп тора. Уң як стенага эленгәннәре исә сугышта һәлак булган җиде улыныкы иде булса кирәк.

Башта Таня белән Люда тып-тын утырдылар. Матрена түтәй, фотосурәтләргә күрсәтә-күрсәтә, үзенең яшьлеге, ире, балалары турында сөйләде. Бераз елап та алды. Әмма кыза төшкәч, барысының да теле ачылды. Хәтта үзенең аз сүзле булуы белән билгеле булган Сәкинә дә гел сөйләп кенә торды.

— Ну что, споем, тетя Матрена? — диде исерә башлаган Таня, өстәлгә сугып.

Өйгә җан керү бәхетеннән тәмам онытылып киткән Матрена түтәй, тешсез авызларын күрсәтеп, кеткелдәп көлеп җибәрде.

— Пойте, пойте, миленькие. А я, как говорится, послушаю, молодость свою вспомню. Ой, как пели-то, как пели-и! И танцевали много. Бывало, что по утрам ноги болели. Все под саратовскую гармошку подпевали. Нынче не интересно, так и знают, что магнитофон крутят.

Ниһаять, Таня сузып-сузып җырлап җибәрде. Аңа Люда да кушылды:

Вечер тихой песней над рекой плывет,
Дальними зарницами светится завод.
Где-то поезд катится точками огня,
Где-то под рябинушкой парни ждут меня…

Шактый озак җырладылар. Аракы өстәлдән төшмәде. Икеөч сәгать эчендә Таняның стенка акчасы чыгып бетте, аннары шинкарларга барып Люданың да сәгатен аракыга алыштырып кайттылар. Шуның өстенә сигарет та күп тартылды. Туксан алты яшендә булса да, Матрена түтәйнең тәмәке төтененә исе дә китми. Чөнки ул гомере буена мондый мәҗлесләрдә күп катнашкан. Ә менә Сәкинәнең үтереп-үтереп башы чатный башлады. Әйтерсең мунчада утырып ис тидергән. Китмәкче дә булган иде, марҗалар: «Ты нас не уважаешь?» — дип бәйләнеп теңкәгә тия.

Сүз артыннан сүз китә дигәндәй, кагылмаган темалары калмады. Бер уңайдан, катнаш гаиләләргә каршы чыккан Фәүзия Бәйрәмованы да, Чечнядагы сугышны дәвам иттергән Путинны да сүгеп алдылар.

— Что, им земли не хватает, что-ли? — дип чыелдады Люда, тозлы балык койрыгын чәйнәп. — Сколько крови пролили, гады. А потом все грехи на русский народ вешают. Не русские виноваты, тупые правители виноваты.

— Для кого война, для кого мать родная. — Таня Сәкинәне кочаклап үбеп алды. — Ты согласна со мной, татарочка?

— Согласна, кәнишне, — дип мыгырдады хатын.

— Наши дети гибнут, а генералы деньги зарабатывают.

Люда чыркылдап көлеп җибәрде:

— Сказала тоже, это даже козе понятно. Я вот среди депутатов только Говорухина уважаю. Сын-то у него в первой Чеченской войне без ноги остался. А вот остальные настоящие сволочи, они своих детей знаешь как оберегают.

— Ох, Люда, сколько их развелось, сколько развелось маменькин сыночков!

— Если война начнется, я американцам продамся. Может жить лучше станем.

— Типун тебе на язык! Не будет войны!

— Будет, Таня. Обязательно будет. В сорок первом точно также думали. А Гитлер все-таки напал.

— Американцы не нападут.

— Борьба против терроризма — это только причина, дорогая. Им террористы не нужны, им нужна Россия. Вишь, они у нас уже под носом ходят. А ведь пустили наши, и на Кавказ, и в Среднюю Азию пустили. Торговый центр у них взорвали, видите ли! А где доказательства?

— Әмрикәлеләре дә ипи-тоз белән килмәс, килсә, шул таларга гына килер инде, — диде беркатлы Сәкинә. — Сугыш башлана күрмәсен, улым армиядә бит.

— Хватит политинформации! — диде Таня. — Давай, «Кубалягем, тюгярягем» споем.

Тәрәзәдән урам якка тагын җыр агылды:

Күбәләк гөлләргә кунса,
Гөлләр тибрәнә микән?
Ул да мине сагынганда,
Күбәләгем, түгәрәгем,
Асыл кошым, сандугачым,
Җырлап җибәрә микән?

Җыр тәмам булды дигәндә генә, тәрәзәдә башына кара кепка кигән ир-ат башы пәйда булды.

— Бәйрәмнәрегез мөбарәк булсын, апалар! — диде ул, мыек астыннан елмаеп.

Инде шактый чайкала башлаган Таня дорфа гына сорап куйды:

— Нәрсә кирәк?

— Гражданка Вавилова монда яшиме?

— Манда мандалошка. — Люда шул рәвешле шаяртырга теләде, ахрысы.

Барысы да пырхылдап көлеп җибәрделәр.

— Мин булам ул, балакаем, — диде Матрена түтәй татарчалап. — Ни йомыш иде?

— Без горгаздан идек, әбекәй. Быелның алты ае өчен газга акча түләмәгәнсез, шуны түләтергә дип килдек. Бу урамда бер сез генә должник булып калгансыз.

— И балакаем, акчам юк бит минем, — диде Матрена түтәй уфылдап. — Җиде йөз тәңкә пенсиягә нәрсә генә эшләп булсын?

— Алайса, безгә газны ябарга туры килә, әбекәй, — диде ир-ат. — Начальство шулай кушты.

— Әй, син, татарин, кем белән сөйләшкәнеңне беләсеңме? — дип, һаман да холыксызланды Люда.

Ул арада тәрәзәдә икенче баш күренде. Бусы тотлыгып сөйләшә икән. Бераз өлкәнрәк күренә. Башы тап-такыр.

— Ке… кем анда те…телен озынайта?

— Сез аны дөрес аңламадыгыз, — дип кысылды сүзгә Сәкинә. — Матрена түтәебез герой-ана безнең.

— Һы. — Теге мыскыллы елмаеп куйды. — Ба… балалары шулай күп булгач, ни… нигә газга акча та…таба алмый?

— Балаларым сугышта үлеп калды минем, бәбекәчем. — Матрена түтәйнең тавышы калтырап китте.

— Ә-ә, а… алай икән, хә… хәлегезне аңлыйм, әбекәй. Ти… тик акчаны ба…барыбер түләргә туры киләчәк. Бу и… илдә геройлар күп, а… акчалары гына юк.

— Ты, козел вонючий, выбирай выражение! — диде Таня, тавышын калынайтып.

— Да… давай, плати деньги! — Ир дә тавышын күтәрә төште. — А то газ за…закроем!

— Только попробуй!— дип янады Люда, теш арасыннан сыгып.

— Нә… нәрсә, я… янаган буласың мәллә, ма… маржа?!

Кепкалы ир-ат иптәшен тынычландырмакчы:

— Ипләп сөйләш, Гариф абый. Күрмисеңмени, исерекләр бит барысы да.

— Ми… миңа димәгәе… Акчаны тү… түләсеннәр главные. Бу урамда ничә көн йөрибез бит инде буталып.

— Әйдәгез, болай сөйләшик. — Кепкалы ир янә әбигә дәште. — Хәзергә өч айныкын түләп торыгыз, соңыннан…

— Түләмибез бер тиен дә! — дип чыелдады Люда, һаман саен явызланып.

— Ярый, шулай дип язып куярбыз. — Газовик кепкасын батырып куйды. — Димәк, газны ябарга туры килә.

Күлмәгенә сыя алмый башлаган Люда сикереп торды да духовкада пешкән йомры бәрәңгене тәрәзәгә томырды. Ләкин анда беркем дә юк иде. Таня белән Матрена түтәй аны тынычландырырга керешге. Аракы үзенекен итә, ярсуыннан акылын җуйган маржа диварда эленеп торган ике көпшәле ау мылтыгын суырып алды.

— Атам кабахәтләрне! — Ул инде тәрәзәгә ыргыла. — Геройанага акча түләтмәкче буласызмы?! Ә аның яу кырында ятып калган уллары өчен кем түләр?!

Котлары очкан хатыннар почмакка сеңде. Люда исә тәрәзәдән газовиклар барган тарафка шарт итеп атып җибәрде. Турысын әйткәндә, мылтыкта ядрә бар дип уйламаган иде ул. Куркудан үзе дә бер мизгелгә айнып китте. Әмма абына-сөртенә чапкан газовикларны күргәч, аның канында тагын шайтан суы уйный башлады:

— Куда бежите, крысы?! — Кычкырып көлә-көлә, төзәп тә тормастан тагын чакмага баса.

Бу юлы ядрә, каршыдагы күршенең су кисмәгенә эләгеп, даң итеп куйды.

Әби инде йөрәген тотып идәндә тәгәрәп ята. Таня белән Сәкинә караватастына үрмәли.

— Боже! Что она делает?! — Маржа, күзләрен акайтып, чукына башлады. — Сейчас милиция приедет. Таскать будут всех!.. Дура!

Люда, маршировать итә-итә, «Интернационал» ны җырлый:

Вставай, проклятьем заклейменный,
Весь мир голодных и рабов!
Кипит наш разум возмущенный,
И в смертный бой вести готов!

Җыр тынды. Котырынган марҗа, кабалана-кабалана, шкафта актарына башлады. Патрон эзли!

Озак маташмады, мылтыкны корып, янә тәрәзә янына килде. Тагын «шарт!» та «шорт!», «шарт!» та «шорт!»

Урамда инде милиция машиналары сирена улата. Башта алар тагын Башмаковка һөҗүм булган дип уйлаганнар иде. Газовиклардан сорау алгач, аңладылар — исерек хатыннар шаяра.

Ниһаять, радиорупордан ультиматум яңгырый:

— Гражданка Марусова! Прекратите стрелять! Сопротивление бесполезно!

Каян белгәннәр?.. Тәрәзәдән инде башка җыр ишетелә:

Черный во-рон, черный во-о-орон,
Что ты вье-е-ешься надо мной…

Тагын «шарт-шорт!» Мылтык тынган арада, урам яктан берәү акыра:

— Люда, сука, прекрати! Образумься, что ты делаешь?! — Ире. Сүгенүе ярату билгесе инде.

— Ты же сам хотел всех из автомата! — дип көлә Люда һәм тагын чакмага баса. — Ха-ха-ха!.. Вот так вам!.. Вот так!

Бу юлы төбәп ата. Ядрә милиция машинасының бензин багын тиште. Машина дары мичкәседәй дөрт итеп кенә кабынды. Менә-менә шартлаячак. Аннары Ерганак урамында мәхшәр көтелә. Күбесе агач йортлар бит.

Янгын сүндерүчеләр килеп җитте. Шлангадан күбек сиптерәләр. Ничек курыкмыйлар?

— Жалко, — дип кычкырды Люда. — А какой хороший фейерверк получился бы!

Ультиматумның файдасы юк. Юлбашчы музее түбәсенә инде снайпер үрмәли. Бик яшь күренә, мыегы да үсмәгән әле.

Җайлы гына урнашып беткәч, снайпер рациядән хәбәр салды:

— Мин әзер.

— Стреляй на поражение, лейтенант.

— Слушаюсь, товарищ полковник!

Бер минут уза, ике, өч, дүрт, биш… Снайпер һаман атмый.

Рациядән янә полковникның гасабилы тавышы яңгырый:

— Нәрсә булды анда, Габбасов? Нигә атмыйсың?

— Булдыра алмыйм, иптәш полковник. Ул бит хатын-кыз. Бәлки, аны башкача тынычландырырга кирәктер?

— Разговоры!

— Миннән булмый, башка снайперны чакырыгыз.

— Нәрсә, өлкән лейтенант булырга теләмисеңмени? Мин сине трибуналга бирәчәкмен, молокосос!

Җавап ишетелмәде. Снайпер инде түбәдән үрмәләп төшеп бара.

— А, шайтан! — Ядрә җиңел машина артында чүгәләп йортны күзәткән полковникның ботын сыдырып узды. — Убью гада!

Янында утырган опер Васютин, баш очыннан тагын берничә ядрә сызгырып узгач, ут килгән якка тулы бер магазин чәпеде дә агарынып утырган полковникның ботына күз салды:

— Зацепила что-ли?..

— Әйе, — дип җавап бирде теге, чыраен сытып. — Сөяккә эләкмәгән эләгүен, до свадьбы заживет.

— Что с снайпером?

— Что, что?.. Зеленый попался снайпер…

— Понятно… — Васютин тамак кырып куйды. — Что будем делать? Перестреляет эта баба нас всех, к черту!

— Двое с тыла должны подойти.

— Давно бы так.

Шул мәлне Кыек Муен этә-төртә милиция кардонын узды да, кулларын болгый-болгый, йортка таба элдертте. Салган булырга охшый.

— Люда, милая, остановись!

Иренә атмады Люда. Аракы сөреме дә чыга башлады бугай. Кинәттән ул үзенең нинди юләрлек эшләгәнен аңлады. Ләкин эшлисе эшләнгән. Бирелсә, барыбер рәхәт көн күрмәячәк. Изолятор, суд, төрмә — боларның берсен дә күтәрә алмый ул.

— Прощай, Геннадий! — Люда, мылтык көпшәсен авызына тыгып, аягының баш бармагын чакмага турылады.

Ир инде тәрәзә янында:

— Люда-а!

— Ыһ!

Өлгермәде Геннадий. Дөнья белән саубуллашкан кешедән генә чыга торган соңгы аваз булды бу. Ау мылтыгы, марҗаның ярты башын умырып, түшәмгә сылады.

— Вот дура. — Кыек Муен күзләрен акайтып басып торды да, каушап-иләсләнеп, йөзе белән тәрәзә тупсасына капланды. — Дура-а!

…Бу куркыныч көндә Матрена түтәй дә, хастаханәгә барып җитә алмыйча, «ашыгыч ярдәм» машинасында вафат булды. Диагноз — инфаркт миокарда.

Сәкинә белән Таняга берни булмады. Аңлатма кәгазьләре яздыргач, җинаять эше ябылды, аларны шул ук төнне кайтарып җибәрделәр.

Люданың мәете атна буе моргта ятты. Ире белән малае аракыдан айнымады. Күмүне Сәкинә белән Таня оештырды. Башка күршеләр дә акчалата ярдәм итте.

## Армиядән хат

Төш вакыты узып бара. Кер юган Сәкинә капканың аръягында кемнеңдер кыштыр-мыштыр килгәнен күрде. Почтальон хатын икән, ярыкка ниндидер бер кәгазь тыгып маташа. Коммуналь хезмәт хуҗалыгыннан квитанциядер. Ай саен акча суыралар. Булмаган чүп савыты, булмаган дворник өчен дә түли урам. Акча кемнеңдер кесәсенә кереп бара. Бер хатын әнә күрше урамдагы подъездларны юып йөри. Дүрт айлык хезмәт хакын әле дә алмаган. Баш күтәрә башласаң, берәр сәбәп табып, куып кына чыгаралар, ди. Кер порошогын да, себеркесен дә, чүпрәген дә үз акчама сатып алам, ди. Вәт заманалар! Хәзер ул мастерлар идән чүпрәге белән дә акча эшли башлады микәнни? Кем ничек булдыра, шулай талый. Күрше Нургаянны гына әйт син. Бүген бер, икенче көнне башка оешмада. Гел машинага утыра үзе. Ул урлап тора, аны куып торалар. Башы эшли, димәк. Башкалар кебек егермешәр ел бер тиенсезгә бер генә урында черәшми. Аның каравы менә дигән «десятка» алды, агач йортын кирпеч белән тышлап чыкты. Базардан кайтса, сумкасы тутырык ит, колбаса булыр.

Сәкинә, калган чүпрәк-чапракны кер машинасына салып, юеш кулларын итәгенә сөртә-сөртә, капкага юнәлде.

— Бәрәч, хат ич бу! — диде ул, аны кулына алып. — Севастополь диелгән. Өчпочмаклы зәңгәр мөһере дә бар. Тик бик юка күренә. Рафистандыр.

Ана, кабалана-кабалана, конвертны ачты. Улыннан шул.

— И балакаем, үзең кайтып кергәндәй булдың! — Сәкинә хатны күкрәгенә кысты. — Нигә шулай бик аз яздың? Ярты гына бит. Йә, ничек синең хәлләр?

*Сәлам Севастопольдән!*

*Исәнме, әни һәм Зөлфия сеңлем! Озак язмый торганга ачуланмагыз. Мин хәзер Севастопольдә. Алты айдан диңгез пехотасында хезмәт итәчәкмен. Әлегә учебкада. Монда дисциплина бик каты. Кичә автоматтан һәм гранатометтан аттырдылар. Ярты көн строевой подготовка белән уза. Безнең ротада җиде татар малае бар. Өчесе Казаннан. Дус-тату яшибез. Ашау ягы ярыйсы. Синең бәлешләреңне, өчпочмакларыңны сагынам.*

*Әни, беркөнне төштә Айсылу белән синең кыстыбый пешергәнеңне күрдем. Мин армиядән, ул Петербургтан кайтып төшкән, имеш. Имтиханнарны да гел «бишле»гә генә биргән икән. Кечкенә Зөлфия дә шунда. Сезгә эндәшәм, ишетмисез. Кыстыбыегызны да ашарга өлгерә алмый калдым, учебный тревога белән уяттылар. Аннары көне буе сезне, шул кыстыбыйларны сагынып йөрдем.*

*Айсылуга юлда ук хат язып салган идем. Язса, якын көннәрдә җавап хаты килеп җитәр, шәт.*

*Үзегез ни хәлдә, әни? Райисполкомнан күчерәбез дип килмәделәрме? Күчәргә ашыкма. Кайткач, Алла бирсә, мин ул урында алты почмаклы йорт салып чыгам.*

*Ярый, сау бул, әни! Зөлфия сеңлемә чуктин-чук сәлам! Минем өчен борчылып тормагыз.*

*Сәлам белән улың Рафис.*

*1 июнь, 2000, Севастополь*

Хатны укып чыккач, Сәкинә Таняларга йөгерде. Сөенече белән уртаклашасы килде аның. Диңгезче бит хәзер Рафисы!

Баксаң, Таня инде бер атна Геннадий белән эчә икән. Икесе дә анадан тума килеш караватта аунап яталар. Өйдә тәртип юк, бөтен нәрсә идәндә. Карават астыннан Геннадийның чалбар балагы һәм Танянның сары колготкие күренеп тора. Күлмәкләре дә шунда. Аларны ап-ак мәче йоны каплаган. Өстәл янындагы гәзит битенә исә сөяк өелгән. Әңгәгә дип әзерләгәндер инде. Чебеннең исәбе-хисабы юк. Алар да, эссегә чыдаша алмыйча, безелдәп тәрәзәгә килеп бәреләләр. Таня үзе пычрак хатын түгел, бәйрәм узгач, өен тагын тәртипкә китерер. Ә менә махмыр исе монда әле тагын бер ай торачак.

Ишектән килеп кергән Сәкинәне күрүгә, ул өстенә юрган да тартмыйча, ухылдап сорап куйды:

— Что случилось, Сакина?.. Пожар что-ли?

— Ишегең ачык иде, шакымыйча кергәнгә ачуланма, — диде югалып калган хатын, никтер хатны артка качырып. — Улымнан хат килде.

— Счастливая ты. — Чәче-башы тузган Таня ыңгыраша-ыңгыраша торып утырды. Күзләре тәмам кысылып беткән. — Деньги есть?

Сәкинә аның аракы яратканын белә, шуңа күрә үзе белән бер чәкүшкәлек акча да алган иде.

— Акча бар барын да…

— Так что же ты стоишь?.. Беги в магазин! Обмыть надо. А потом, глядишь, и групповуху организуем. — Таня, Кыек Муенның күтенә сугып, кычкырып көләргә тотынды. — Да ведь, импотент несчастный.

Геннадий юрганны инде өстенә тартып куйган иде.

— Не зли меня! — дип ыжылдады ул, карлыккан тавыш белән.

— Нәрсә, шаяртканны да аңламыйсың мәллә? — диде марҗа, татарчага күчеп, һәм идәндә аунап яткан яулыкны башына бәйләп куйды. — Геннадий миндә яшәргә җыена бит әле, Сакина. Туйдырды ялгызлык дигәннәре. Сөяркәләр килә дә китә, ә бу исерек булса да, гел янымда булачак. Эчәргә иптәш тә бар… Ха-ха-ха!

— Привет, соседка! — Геннадийның болайга таба борылып ятарга хәле юк иде булса кирәк. — Ушла моя Люда…
Кыек Муенның гәүдәсе калтырый башлады. Елавы иде, күрәсең.
— Да не стони ты. — Марҗа ирнең башыннан сыйпады. — Все равно все там будем. Син хатыныңа чардуган кую турында уйла. Аннары Толикны да гел караштыргалап торырга кирәк. Ул инде өегездәге әйберне сатып эчә башлады. Киленегезне әйтер идем, тәмам сукбайга охшап бара. Яшьлеге бар, матурлыгы бар, бу яшьтән аракыга сабышкач…
— Сукбай она и есть, — диде ир, борын тартып. — Толик бит аны притоннан табып алып кайтты. Куып чыгармакчы булган идек, мин аннан башка яши алмыйм, асылынам, дип, кулына бау тотып йөри башлады.
— Аракы сөреме белән аңгыраеп йөрде Толигың. Чибәррәкне дә эләктерә ала иде. Хотя, хәзер кызлар карарлык кыяфәте дә калмаган инде. Яшьлекнең кадерен белмиләр, юләрләр. — Таня, кәттә генә кыланып, арт ягын селкетеп куйды. — Их, егерме яшькә яшьрәк булсам, монда ятар идеммени мин? Берәр бизнесмен егетне эләктереп, инде күптән йә Парижга, йә Канар утрауларына чыгып сызган идем.
— Китәр идең абзар артына, — диде ир, ниһаять, торып утырып. — Синдәй сыра мичкәсе кебек юан хатыннар Парижда да җитәрлек. Шул Африка джунглиларында яшәүче каннибалларга гына кирәк булсаң инде.
— Что?.. — Марҗа, бөеренә таянып, аңа таба килә башлады. — Аһ, ты, старый хрыщ! Мою пенсию пропиваешь, да еще…
Геннадий сүзне шундук уенга борып җибәрде:
— Җә, җә, тынычлан, котыртып кына әйттем мин сиңа бу сүзләрне!
— Шулай дисәң генә котыласың, — диде Таня, авызы ерылып. — Давай, Сакина, сгоняй в магазин, а то сушняк у нас.
Сәкинә кибеттән бик тиз әйләнеп керде. Таня инде газ плитәсенә чиләк белән су куйган, дөнья бетереп, бер атна элек сатып алган шампунен эзли. Юынырга маташуы инде. Бу җәйге челләдә гел юынып тормасаң, аракы эчмичә дә, тирләп-сасып бетәсең. Геннадий да торган, ул Таняның иске туфлиенең резина табанын ябыштырып маташа.
Озак тормады Сәкинә. Хатны укыткач, газда чәйнекне онытып калдырганмын дип, чыгып китү ягын карады. Чөнки белә, болар чәкүшкә белән генә канәгатьләнмәячәк.
…Кечке якта ул, янына кечкенә Зөлфияне утыртып, хат язарга алынды. Җиңел эш булмады бу, иң әүвәле башлый алмыйча интекте, аннары нәрсә язарга белмәде. Күптән, бик күптән хат язганы юк инде аның. Ире Шәүкәт шахтада эшләгәндә нинди җылы хатлар алышалар иде! Аларның барысын да кадерләп саклый ул.

Рафиска да күрсәткәне бар, ләкин әлегә укытканы булмады. Күбесе ярату турында бит, иртәрәк булыр дип уйлады. Ә хәзер, улы янында булса, бергәләшеп укырлар иде әтиләренең хатларын.

Берничә бит кәгазьне мичкә йомарлап ыргыткач, ниһаять, язар сүзләр дә табыла башлады.

*Сәлам Казаннан!*

*Улым, хатыңны алдык, зур рәхмәт! Сеңлең белән бергә хат язарга утырдык менә. Сиңа күп сәлам әйтә. Абыемны сагындым, ди. Бераз елап та алды. Үзем дә еладым, балакаем. Башыңны сакла, бу дөньяда таянычыбыз син генә.*

*Бүген күп итеп кер юдым. Киемнәрең армиядән кайткач ярамастыр инде. Синең үсә, киңәя торган вакытың. Алай да, бер-бер нәрсәгә ярарлар әле дип, үтүкләп, төреп куйдым барысын да. Теге зәңгәр джинсы чалбарыңны сүтеп, Зөлфиягә юбка тегеп бирдем. Бик ошатты. Аны кибеттән ала башласаң, күп акча кирәк.*

*Суны син ташыганда бик рәхәт иде. Хәзер кисмәктә су тотмыйбыз. Чиләк-көянтә белән алып кайтканда да җитеп тора. Дөрес, кер юганда су күп кирәк инде анысы. Зөлфия бик булыша, йорт каршындагы бакчадан чыкканы юк. Чүбен дә утый, кичкенә чиләге белән кыярларга да су сибә. Кызымнан да уңдым, Аллага шөкер.*

*Әлегә райисполкомнан күчерәбез дип килгән кеше юк. Безнең йортларны киләсе елда сүтә башлаячаклар, дигән сүз йөри. Белмим, ничек яшәрбез икән без ул Азино якларында? Бигрәк шәһәр чите бит. Аннары Зөлфиягә дә яңа мәктәптә укырга туры киләчәк. Әле ерак булачакмы ул, якынмы — Алла белгән. Азинога киткән кешеләрнең моң-зарын ишетеп тә куркып беттек инде. Еш кына су да булмыйча тора икән анда. Аннары лифтта хатын-кызларның алтын алкаларын да салдыралар, ди. Минем алтыннарым юк, бусы өчен курыкмыйм. Зөлфия үсеп килә бит, телевизордан маньякларны гел күрсәтеп кенә торалар. Җитәкләп йөртмәсәң, күп катлы таш йортлар арасында адашып бетәчәк бит ул. Карап торышка бөтенесе дә бертөсле бит алар.*

*Айсылудан хат алмадыңмы? Икегез ике якта булып, бер-берегездән бизмәсәгез ярый инде. Күзендә нур бар аның, сине дә нык ярата булса кирәк. Ике-өч көнгә бер тапкыр Санкт-Петербургтан шылтыратып тора. Үз кызым кебек күрә башладым аны. Рәхмәттән башка бер сүзем юк.*

*Зөлфия синнән фоторәсем сорый. Аны үзенең иптәш кызларына күрсәтәсе килә. Мин дә бер рәхәтләнеп карар идем, балакаем. Мөмкинчелегең булса, шылтыратып алсаң да бик ярар. Хәзер телефон бөтен җирдә дә бар бит.*

*Син казыган баздан бик уңдык. Бәрәңгеләр бүген казып алган кебек. Хәзер бәрәңге дә кыйммәт бит, чиләге илле тәңкә. Базарга чыккан идем, бәясе төшәргә уйламый әле.*

*Шуның белән тәгәлләрмен инде. Үзең күп итеп яз. Зөлфия сиңа акварель буяу белән ясалган рәсем җибәрә. Астына нидер язып маташа бугай. Нинди рәсем икәнен күрсәтми, ояла, ахрысы.*

*Сау бул, балакаем!*

*Сине үбеп, сагынып калучы әниең һәм Зөлфия сеңлең.*

*6 июнь, 2000, Казан*

## Кулыңны куй, Толик!

Бер атнадан Геннадий үлеп китте. Берәүләр аны сагышыннан, икенчеләр денатураттан агуланып үлде, дип сөйләде. Бу озакка сузылган эчүдән соң Таня да саргаеп калды. Бавырына зыян килгән, күрәсең. Берничә тапкыр Сәкинәләргә кереп зарланып та утырды.

Геннадийларның өендә исерек Толик кына калды. Башта хатыны, аның артыннан мәчесе чыгып качты. Хәер, Валяны хатын дип әйтү бик зурлау булыр иде. Килеш-килбәте белән вокзал хатыннарыннан ким түгел. Беркая да эшләми. Дөрес, ара-тирә Мөштәри урамына менеп көнбагыш саткалаган була, ләкин кулына азмы-күпме акча керүгә, аны якын-тирәдәге исерек мужиклар белән эчеп бетерә. Чөнки аракы яраткан кеше шешәдәштән башка яши алмый. Бүген син салып бирсәң, иртәгә сиңа салып бирәчәкләр. Әби-бабай пенсия алганда яшәргә була иде. Ә хәзер Толикның нәрсәсе бар? Дала кебек шыр ялангач йорт калды аның карамагында. Бөтен нәрсәне сатып бетерделәр, хәтта караватта йокларга матрас калмады. Бу җимерек абзар өчен фатир ала алмаячак ул. Чөнки аңа башкалар хуҗа булырга җыена. Бер килделәр инде. Гәүдәле генә яшь-яшь ике егет йорт өчен (дөресрәге, җир өчен инде) илле мең сум акча тәкъдим итте. Толик каршы килгәч, янарга ук тотындылар. Берсе: «Йортыңдагы матчага асып китәбез, уйла!» — диде. Гади кешеләр түгел. Икесе дә зур начальниклар кебек киенгән. Кулларында — шифр белән ачыла торган кыйммәтле кара дипломат. Валя аларны тәрәзәдән карап калды. «Джип» машинасында киттеләр. Көчләп бөтен документларга кул куйдырачаклар да үтерәчәкләр Толикны. Хәзер кеше үтерүне чебен үтерүгә дә санамыйлар. Качыйк дигән иде Валя, Толик тыңламады. Милициягә гариза илткән иде, беләбез без сезне, алкашларны, больницага барып дәвалан, дип куып кына чыгардылар. Милиция яклый ала торган заман түгел бу, шуңа күрә Валя чыгып китте. Зиратта ятуга караганда, притонда ятуың яхшырак. Хәер, притоннар — аның яшәү рәвеше. Толик белән дә менә шундый притоннарның берсендә таныштылар алар.

...Валя бүген көне буе Чехов базарында буталып йөрде. Урамда хәер эстәп утырган ике сукбай хатын белән дүрт денату-

рат шешәсен бушаттылар. Ашау булмаганлыктан, аның инде бөтен эче яна. Җитмәсә, Толиктан балага да узган. Бүген генә аңлады. Аракыдан түгел, карындагы яралгыдан косты. Ярый, туса туар шунда. Чүп савыты бетмәгән, салыр да китәр.

Якындагы йорт подъездында йоклап алгач, ул кая барырга да белмичә аптырап калды. Узган-сүткән кешеләр анда көнчелек хисе уята. «Их, бар бит бәхетле кешеләр, — дип уйлады ул, кашын җыерып. — Аларның өйләре дә, акчалары да бар. Ә мин кем? Минем нәрсәм бар?.. Туйдырды болай яшәү, гарык. Минем дә өем бар бит. Тузган булсын, җимерек булсын, барыбер өй бит. Аның өчен дәүләт бер дигән фатир бирәчәк. Кулдан гына ычкындырырга кирәк түгел йортны. Хәзер Толик янына кайтам да иртәгә үк дворник булып эшкә урнашам. Җитте, минем дә кеше төсле яшисем килә!»

Якты уйлардан канатланып киткән Валя, үзе дә сизмәстән, Ерганак урамына йөгерде. Инде кичке уннар тирәсе булса да, бик караңгы түгел әле. Июньдә көн озыная башлый шул.

...Өй турысына килеп җитәрәк, аны тагын шик басты. Тегеләр килгән булса? Бетерәләр башны, берсүзсез бетерәләр. Исерек ир белән хатынны беркем дә якламас. Базга күмеп куйсалар да, эзләүче булмаячак.

Капка бикле түгел. Хәер, аның бикле булганы да юк. Ут яна. Димәк, Толик өйдә. Пәрдәләр генә тартылган, берни күренми. Аның беркайчан да пәрдә тартканы юк. Өйдә чит кеше булуы ихтимал. Кем белгән аны, бәлки, берәр культурныйрак шешәдәш хатын да алып кайтып утырткандыр әле. У-у, сука, әллә нинди хыяллар тугандыр әле башында, йортлы булдым дип куанадыр.

Чү, эчтән ниндидер ят тавыш ишетелә! Сүгенгән тавыш бу. Кемдер ыңгырашкан да кебек. Бетте баш! Теге ике интеллигент җыбыткысы килгән, алайса.

Валя тәрәзәгә якынрак килде, колагын куеп тыңлый башлады. Кирәк бит, нәкъ менә шундый вакытта тынлык урнашты. Күтәргәме?

— Ә-ә, бездә шпионнар бар икән!

Капты Валя. Арттан берәү аны беләгеннән суырып алды. Теге чакта килгән әзмәверләрнең берсе икән. Сияргә чыккан, башкисәр, чалбарын да төймәләргә өлгермәгән.

— Мин... — Шуннан ары Валя бер сүз дә әйтә алмады. Әйтерсең телен йоткан.

— Нәрсә мин?! — дип акырды башкисәр. — Өйгә атла, сучка!

Өйгә кереп, матчага аягы белән асылган шәрә Толикны күргәч, Валя имәнеп калды. Кара көймәгән җире юк бахырның. Баш турысында канлы селәгәй күлләвеге җәйрәп ята.

— Нишләттегез аны? — дип пышылдады хатын, чыраен сытып.

— Документларга кул куймасаң, сине дә нишләтәбез, — диде өстәл артында утырган симез битле әзмәвер хихылдап. Үзе, пыш-пыш килеп, тәмәке тарта. Бусы озынрак та, тазарак та күренә. Валяга бераз текәлеп карап торгач, ул әшнәсенә эндәште:

— Иди сюда, Кабан, выпьем!

Өстәлдә ике бушаган аракы шешәсе, тәмәке төпчеге белән тулган көл савыты һәм таратып ташланган кәгазьләр күзгә ташлана. Бер генә сәгать утырмыйлар икән. Кеше ишетер, кеше килеп керер, дип тә курыкмыйлар. Азган бәндәләр инде болар. Андыйларга ике дөнья — бер морҗа.

Кабан Валяны этеп җибәрде:

— Садись на кровать!..

— Я… я постою, — дип елап җибәрде Валя, тезләре калтырап. — Не убивайте, пожалуйста!

— Чибик, налей ей тоже.

— Пусть сперва мочу попьет, — диде тегесе, эре генә кыяфәт белән чалбар сәдәфен чишкәндәй кыланып. — Ладно, в следующий раз… Как ты ее засек, Кабан?

— А… — Әзмәвер, кул селтәп, өстәлдәге рюмканы каплап куйды. — За окном стояла.

— Подслушивала, значит?

— Значит, да.

— У-у, курва! — Чибик буш шешәне Валяга таба томырды. — Не хорошо! Уши отрежем, поняла?!

— Хватит, Чибик, не дури! Делом надо заняться.

— Извини. Сейчас уломаем.

— Здесь долго находиться нельзя, засечь могут.

— Знаю. — Чибик Валя янына килеп сүз башлады. — Син бу мәхлукның хатыны буласың инде, име?

— Ие.

— Вообще-то, күбрәк урам этенә охшагансың син. Толигыңа әйт, өстәлдәге документларга кул куймаса, без аны да, сине дә тереләй базга күмәбез. Поняла?

— Нинди документка?

Ташбәбәк сәгатенә карап алды.

— Биш минут вакыт бирәм. Время пошло!

Валя Толик янына килеп басты, курка-курка гына куллары белән аның кара көйгән аркасыннан сыпырды:

— Толик, бу мин.

Ирнең тавышы бөтенләй беткән, сызгырып-гыжылдап чыга:

— Беләм…

— Кулыңны куй. Үтерәчәкләр бит.

— Без болай да яшәмибез инде.

— Нигә шулай дисең?

— Тормышмыни бу? Үтерсеннәр, минем үләсем килә!

— Ә минем үләсем килми, Толик. — Хатын, тезләнеп, аның

башын кочаклады. Битеннән буй-буй булып мөлдерәмә яшь ага. — Куй кулыңны!.. Икебез дә эшкә урнашырбыз… Минем кеше төсле яшисем килә.

— Үләсең килмәгәч, нигә килдең?

— Синең хәлеңне белергә дип…

— Анысы өчен рәхмәт.

— Кулыңны куй, зинһар!

— Куймыйм.

Шул мәлне Чибик, аракы эчкән җиреннән сикереп торып, Толикның күтенә китереп типте:

— Скотина!

— А-а…

— Будешь подписывать?! — Тагын тибә.

— А-а…

— Знай, — дип ыжылдады Чибик, — отсюда дорога только в ад! Ваша шкура в ваших руках! Даю еще минуту!

Валя идәндә үрмәли-үрмәли ялваруын белә:

— Толик, мин балага уздым… Толи-и-к! Зинһар, кул куй!

Сынды ир, чыдамады, ишетелер-ишетелмәс кенә итеп әйтеп куйды:

— Ярый, китерегез кәгазьне…

Чибик әшнәсенә ишарә ясады:

— Дай им бумагу!

— Башта чишеп төшерегез! — Толик үз хокукларын белә.

— Обойдешься. Давай, подписывай!

Түшәмдә асылынып торган килеш берничә кәгазьгә кул куйгач, ир мышык-мышык елап җибәрде:

— Гады, все отобрали!

Өстәл артында утырган Кабан инде пистолет көпшәсенә глушитель бора.

— Что вы собираетесь делать? — Валя күзләрен акайтып артка чигә башлады.

— Что, что? Х… через плечо!

Пистолет тавышы бөтенләй ишетелмәде, «шап!» иткән тавыш кына яңгырап куйды. Валя белән Толик та тавыш-тынсыз гына күз йомдылар. Аларның маңгайларында хасил булган кечкенә генә тишектән сиптереп кан ага иде.

…Өйгә ут төртеп, «джип»ка утыргач, Чибик канәгать тавыш белән әйтеп куйды:

— Все чисто, ищи ветра в поле! Иртәгә Шпатовны бераз кысасы булыр. Унар мең тәңкә моның өчен бик аз. Дело мокрое, шкурой рискуем.

— Шерхан дип сөйләш, — диде Кабан, тәрәзәгә сеңгереп. — Ул фамилия белән әйткәнне яратмый.

— Яратмаса соң?! Шерхан, имеш. Мент он поганый! Син аның безнең өстә күпме акча эшләгәнен беләсеңме?

— Белмим һәм белергә дә теләмим. Крышасы шәп, менә бусын яхшы беләм. Кем икәнен генә әйтми... Син рульне чамалабрак тот, ДПСниклар килеп чыкмасын. Безгә бу районнан тыныч кына чыгып сызу хәерле.

— Что правда, то правда, — диде Чибис, хихылдап, һәм машинаны Достоевский тукталышына таба борды.

Шулай итеп, бу төндә Ерганак урамында тагын бер йорт янды.

## Борчылу

Толикларның йорты янган төнне, Илфак Апаста — карт әтиәнисе янында иде. Абыйсы Чечняга киткәч, ул ике атнага бер кайтып китә торган булды. Җәйге чорда авылда эш бик күп була, бәрәңге төбен өяргә, колорадо кортын җыярга, печән алып кайтырга кирәк, утын яру да аның өстендә. Әти-әнисенә булышырдай балалар үстерә алмады инде, хәерлегә булсын. Кәбирнең кызы быел юридик факультетка укырга керергә маташа. Әнисе көнтөн Казан юлын таптый. Узган ел кыз вак-төяккә ярап тора иде әле. Быел, имтиханга әзерләнәм дип, өеннән дә чыкмады. Һи, нәрсә ул кыз бала? Бүген монда, иртәгә кияүдә. Ир баладан файда күбрәк, кәнишне. Илфакның классташлары инде әзмәвердәй берничә бала үстерделәр. Кайсысыныкы икәү, кайсысыныкы дүртәү. Рафикның малае әнә гер күтәрү буенча республика чемпионатында икенче урын алды. Аның артыннан тагын ике ир бала үсеп килә. Вәт менә бу тормыш! Ә Илфак нәрсә? Картлык көнендә аңа бер кашык су бирүче дә булмаячак.

Бу юлы әти-әнисе шәп кенә сүктеләр үзен. Имеш, радиодан да ишетелмисең, газетада да басылмыйсың. Сирәк яза Илфак, әмма берәгәйле яза. Башкалар кебек сан артыннан кумый ул. Графоманнар басты дөньяны. Фантазияләре — нульдә, тел ягы да бака күле кебек сай. Бер мәшһүр каләм иясе әйтмешли, кайчан котылырбыз икән без «тал-тирәк», «сагыш», «чишмә», «сандугач» дигән сүзләрдән. Илдар Юзеев әйткән иде бугай бу сүзләрне. Моны туры мәгънәсендә аңларга ярамый, әлбәттә. Һаман да шул тел ярлылыгы, фикер сайлыгы галәмәте.

Вәт замана, иренмәгән бөтен кеше шигырь яза, җыр чыгара! Ә берсендә дә шаккатырырлык фикер юк. Кайберләрен искә алмаганда, әлбәттә. Илфакка килсәк, ул беркая да ашыкмый. Бөеклек чире яшьлектә калды инде аның. Хәзер менә җигелеп, тырышып язар чак җитте. Сәгате суккач, радиодан да, телевизордан да чыгып ясар, Алла бирсә. Тик моның өчен әле ул аһ итәрдәй бер поэма язарга тиеш. Бүгенге тормыш турында бөтен дөресен язарга тиеш. Ә басмасалар?.. Бусы да булырга мөмкин, чөнки әкрен генә цензура килә. Мисал өчен, экстремизмга каршы закон кабул ителсә, бездә бик күп әсәрләрне кире борырга мөмкин

булачак. Латин графикасын яклап чыгасың икән, син — экстремист, Татарстан җир асты байлыкларына үзе хуҗа булырга тиеш дисең икән, син тагын экстремист. Әле ун ел иркен сулыш алган арада язылган әсәрләрне дә яңадан карап чыкмагайлары.

Шундый уйлар бораулады Илфакның миен. Бу Ерганак урамы турында зур роман-поэма язарга тели ул. Монда бер дигән персонажлар бар.

Мисал өчен, Анатолий Высоцкийны гына алыйк. Заманында ул мех фабрикасында тегү машиналарын ремонтлый иде. Ерганак урамында бөтен хәерче әле дә ул урлаган машинада тегә. Бераз салса: «Я Высоцкий, а вы кто?!» — дип, күкрәк кага башлый. Мондый чакларда ул еш кына чалбар кияргә дә онытa, кибеткә демонстратив рәвештә трусиктан гына (анысын да алдын артка киеп кенә) бара. Аннары аның подвалыннан таңга кадәр «Интернационал» җыры агыла. Высоцкийның подвалында иске тәлинкәдән күп нәрсә юк. Хәзер тегү машиналарын ремонтламый инде, куллары калтырый.

Бер җәйне, капка төбен себерергә чыккач, ул биш минутта биш мең марка эшләп ыргытты. Зыялы гына ике ир-атның Юлбашчы музееннан Ерганак урамындагы хәерчелекне төшереп йөргән мәле була бу. Сөйләшүләренә караганда, немецлар булырга тиеш. Салмыш Высоцкий, үзенең дөм хәерче булуын күрсәтергә теләпме, бөтен киемен салып ташлый, трусиктан гына кала. Кулына себерке тоткан ярым шәрә пролетариат кемгә кызык булмасын? Тегеләрнең авызлары колакларына җитә. Шәп материал бит, рәхәтләнеп төшерәләр Высоцкийны. Әле шуның өстенә акча да биреп китәләр. Дөрес булса, моның өчен аны КГБга да чакыртып алганнар ди. Ниндидер бер журналда фоторәсеме чыккан икән. Бәлки, болар барысы да имеш-мимешләр генәдер, ә менә аның шуның өчен эштән куылуы рас, җәмәгать. Тик биш мең марканың рәхәтен күрә алмады Высоцкий. Хатыны шундук каядыр качырып куйды. Ташлап чыгып киткәндә дә, кәҗә тоягы гына күрсәтте. Шуннан бирле ул үзенең подвалында «Щорс турындагы җыр» тәлинкәсен әйләндереп ята.

Ә күрше Галимҗан әнә сүтелә торган агач йорт нигезен актарып бер чүлмәк алтын тапты. Кемдер милициягә хәбәр иткәч, төнлә читкә чыгып сызган. Берәр ел чамасы хатынына, балаларына гел шылтыратып торды, хәзер тавышы-тыны юк. Мәскәүдә бәреп үтергәннәр, дигән имеш-мимешләр дә йөри. Мөгаен, шулайдыр, исән булса, хатынын, ике баласын җимерек йортта яшәтмәс иде.

Исмәгыйль исә көн дә бурлак кебек уф алла арбасы белән якын-тирәдәге йортлардан калдык азык-төлек җыеп йөри. Үзенә түгел, күршесенә. Алар дуңгыз асрый. Исмәгыйльнең хезмәт хакы — бер литр әчер-әчемәс бал. Узган-сүткән кешедән һәрвакыт тәмәке сорар, бирмәсәләр, җирдә аунап яткан төпчеккә дә канәгать. Берәр танышы очраса, авызында һаман бер сүз булыр:

— Күрше Володя шәп кеше булган безнең. Ул әйткән идея белән исән вакытта эшләмичә дә яшәргә була иде. Ике буш шешәгә бер ак ипи тия иде. Ә хәзер шешә җыеп кына түгел, эшләп тә тамак туйдырып булмый. Вушшым, фашистлар килде властька! Тфү!

Әйе, кызык урам бу. Өстәге урамда гына Ленин, Горький яшәгән. Бөек юлбашчы турында сүз чыкса, аны бу урамда, никтер, гел күрше дип атау гадәткә кергән. Йөргәннәр микән Ленин белән Горький Ерганак урамыннан? Йөргәннәрдер. Бәлки, Тукай да булгандыр әле монда. Бәлки, берәресендә тел очына шикәр салып, чәй дә эчкәндер. Бәлки, шушы урамда яшәгән берәр татар кызына да гашыйк булгандыр. Алар да адәм балалары бит. Кызганыч, бүрәнәләре сөяк кебек шыкырдап торган борынгы йортларны гына җимерәләр. Агачны кисә белгән шул борынгылар. Эче тулы сагыз. Әйтерсең бүген генә урманнан алып кайтканнар. Бер бабай сөйләп торды, ул чакта агачны кыш көне кискәннәр икән.

«Әллә өйләним микән? — дип уйлады ул. — Ялгызлык жанны ашый. Кырыкны узып киттем бит инде. Тагын бер биш-алты елдан өйләнәм дисәң дә, өйләнеп булмаячак. Чәч тә коела, тешләр дә бетеп бара».

Йокларга яткач, адәм баласы әллә ниләр уйлап бетерә. Әйтерсең уйлар энциклопедиясен актара. Кинәттән ул бичара Толикны искә төшерде. Эчеп күрсәттеләр, малай. Һәм менә ничек бетте барысы да. Люда белән Кыек Муен да юк, уллары белән киленнәре дә харап булды. Бу аракыны нигә бетермиләр икән? Нигә бетерсеннәр, ул шәһәр казнасына акча кертә. Шуның хисабына малоимущийларга, ятимнәргә социаль ярдәм күрсәтелә. Имеш! Аракы сатып илне матурлап та, бәхетле итеп тә булмый. Иллюзия бу! Коточкыч саташу бу! Ә илне ничек бәхетле итеп була? Шайтан белгән. Хотя, татар инкыйлабка кадәр аракы эчмәгән бит. Гореф-гадәтләр нык булган, кеше мәчеткә йөргән. Дин коткарырга тиеш кешеләрне. Коръәнле балалар булырга тиеш без. Ә анда язылган сүрәләр, уйлап карасаң, шундый гади, шундый аңлаешлы. Күрәсең, адәм баласы өчен кайбер төшенчәләрнең аңлаешлы булуы гына җитми торгандыр. Михнәт күрә башласа, бәла-казаларга тарыса, ул һәрвакыт Алланы искә төшерә. Үлә башлагач та, ник болай эшләдем икән, ник болай яшәмәдем икән, дип үкенеп ята. Мәчеткә йөрү белән бергә, зиратка да ешрак йөрергә тиеш кеше. Кабер ташларын күрү дә аны бер мизгелгә айнытып җибәрә. Ул бер генә сәгатькә булса да, философка әверелә.

Толик, Толик... Нәрсә булды сиңа? Әллә үтерделәр инде? Дөм янып беткәннәр бит, каһәр, экспертиза ясардай җирләре дә калмаган. Үтергәннәрдер, шәт. Дөньялар үзгәргәнче бу урамда бер генә янгын очрагы да булмаган. Китап палатасына барып, юри

гәзитләр актарып утырды. 1961 елда булган соңгы янгын очрагы. Анысын да вакытында сүндереп өлгергәннәр. Һәй, бер Ерганак урамы гынамыни, бөтен Казан дөрләп яна. Көн дә зур учак ягалар диярсең.

Җир кирәк «яңа урыс», «яңа татар»ларга. Шуңа яндыралар. Толиклар йортын да шуңа яндырганнардыр. Ә ике мәет нигә кирәк? Бу сорауга җавап табу өчен, иң беренче нәүбәттә, йортның кем исемендә булуын ачыклау мәслихәт. Менә бу эврика!

Илфак, сикереп торып, тәмәке кабызды.

— Үтергәннәр! Тәгаен, үтергәннәр! — дип мыгырдады ул һәм өстәлдә яткан «Буш тәпие» сөякләрен алып, тышка чыгып китте.

Әнгәне сыйламакчы иде ул. Соңгы көннәрне улап-шыңшып йөрде, бахыр. Малайлар сөйләп торды, подвалдан көчекләренең сөякләрен ташып, шундагы тапландык бакча тирәсенә күмгән икән. Көннәр буе шунда утыра, имеш. Менә бит, кем әйтер анда адәм акыллары юк дип. Элек болай кыланмый иде. Картая барганын, бүтән көчекләр тудыра алмаячагын сизенәдер. Ятимлек хисе куркытадыр. Әйе, барысы турында да картая башлагач кына уйлана башлыйбыз шул. Акыл керә дигәннәре шушы була торгандыр инде. Ә яшьлек артык уйланырга яратмый, ул үзен мәңгелек дип уйлый.

— Әнгә!.. Нәх-нәх! Кая син?.. Әнгә, дим!

Тавыш-тын юк. Илфак, сөякләрне капка төбендә калдырып, өйгә кереп китте.

А, сәгать инде иртәнге ике! Тагын йокы булмады, каһәр. Иртәнге биштә торып, Казансуга балыкка төшәргә уйлаган иде, барып чыкмас, ахрысы. Ярый, планнар үзгәрә болай булгач. Журналистское расследование белән шөгыльләнәчәк ул бүген. Район эчке эшләр бүлегендә аның бер танышы бар. Хәзер полковник булды бугай. Менә шуңа үзенең гөманнарын сөйләп бирәчәк. Тикшереп карасыннар әле, кем исемендә икән хәзер Толикларның йорты?

Яткач, тагын әллә ниләр уйлап бетерде Илфак. Аннары, шул уйлардан арыныр өчен, күз алдына килгән төсле сурәтләрне күзәтә, өйрәнә башлады. Менә кызыл нокта барлыкка килә. Хәзер җәелеп, спираль рәвешенә керергә маташа. Юк, аны аксыл төс алыштырды. Бу аксыл төс әллә кәгазь, әллә экран рәвешен алмакчы. Тагын кызыл нокта, ул кан күлләвеге төсенә кереп бара. Әччәч!

Күз алдына тагын әллә нинди хикмәтле сурәтләр килде. Арада куркынычлары да, матурлары да бар. Шул рәвешле, Илфак, тәмам онытылып китеп, йокыга киткәнен сизми дә калды.

## Тырышырбыз

Район эчке эшләр бүлегенә сәгать өчкә генә килеп җитте Илфак. Шул инде, төне буе йоклый алмыйча интегәсең дә көне буе тора алмыйча азапланасың. Җитмәсә, кырынганда киселеп бетте. Өчле лезвие дип мактаган булалар, бәясе хәттин ашкан, ә үзе бер атна кырынырга да җитми. Аптырагач, өстәл тартмасында яткан иске «Спутник» белән кырынырга мәҗбүр булды. Инде йөзләгән карандаш очлаган иде бугай аның белән. Алай да шәп кырды. Көндезге йокы да йокы түгел, баш шәрифләре чатнап тора. Бәлки, магнит давылы галәмәтедер? «Маяк»тан өченче июньне авыр көн дип атаганнар иде кебек.

Көнбатыш колониясенә әверелеп бара Россия. Юк, колония генә түгел бу, чып-чын резервация. Кибет тулы шикле тауар. Үзе кыйммәт, үзенең һичбер сыйфаты юк. Бер гәзиттә, безгә чит илләр өченче, дүртенче сортлы тауар җибәрә, дип язганнар иде. «Буш тәпие», чәй, кием, аракы, төрле эчемлекләр, соклар... Дөрес язалар, элекке еллардагы һинд чәен генә ал, нинди хуш исле иде! Ә хәзер кабы шул ук булса да, һичбер исе юк. Бу өч тиенгә ярамаган тауарны кайтартып, кемдер акча эшли. Безнең корсакка агулы ризык, агулы эчемлекләр тутырып байлык туплый!

Илфак күрергә теләгән кеше полковник Олег Филатов иде. Керәшен малае ул. Университетта бер курста, бер группада укыдылар. Ул чакта журналистика факультетында укыган егет-кызларның күбесе бөтенләй башка юлдан китеп барды. Тормыш бит, барысы да үзенә җайлырак урын эзләргә тырыша. Филатов та журналист булып китмәде. Чөнки ул инде укыганда ук үзенең язуга сәләтле булмавын аңлый башлаган иде. Алай да хатын-кызны үзенә карата белә иде. Бер балигъ булмаган кызга корсак ясаганы өчен университеттан да куа яздылар. Өйләнеп кенә котылды. Бергә озак яшәмәделәр, Олег аерылды. Вакытлыча өйләнү тавыш-гаугадан котылу стратегиясе генә иде аның өчен. Университетны тәмамлагач, Совет районында участок милиционеры булып эшләде. Аннары шул ук районда тикшерүче дә булды бугай. Ә хәзер әнә кем булган: оешкан җинаятьчелеккә каршы көрәш бүлеге начальнигы!

Полковник Филатов аны кочак җәеп каршы алды.

— Откуда? — диде ул, кулларын җәеп, һәм кәнәфиеннән сикереп торып, аның каршысына атлады. Авызы ерык, йөзе кояш кебек балкый. — Сколько лет, сколько зим! Түргә уз, дустым!

Элек тә шкаф кебек иде, хәзер дә шундый икән. Тик чигә турылары инде агарган, маңгаенда тирән җыерчыклар да бар.

Илфакны өстәл артына утырткач, Олег, өстәлдә бармакларын биетә-биетә, көлемсерәп куйды:

— Ә син үзгәргәнсең, брат, картайгансың, димме?

— Яшь бара бит, Олег, — диде Илфак елмаеп. — Син дә

картаеп барасың икән. Урамда очраган булсаң, танымаган булыр идем, валлаһи. Университетны тәмамлаганнан бирле очрашканыбыз юк бит. Таркаурак булды безнең группа. Ә менә башкалар дүрт-биш ел саен очрашып тора.

— Адәм баласы дөнья куа. — Полковник көрсенеп куйды. — Вакыт юклыкка зарланабыз шул.

— Бусы сәбәп кенә… Әнә президент Ельцин үзенең курсташлары белән әле дә очраша. Кичә телевизордан сөйләп утырды. Уйлап карасаң, илбашының бөтенләй вакыты булырга тиеш түгел.

— Сүзләреңдә хаклык бар.

— Ярый, ничек синең хәлләр? — диде Илфак. — Балаларың үсеп җиткәндер инде?

— Үстеләр… Бер кызым, бер малаем бар. Кыз әле мәктәптә укый. Быел дүртенче сыйныфка күчте. Малайдан ун елга соңрак туган иде. Дүрт-биш еллар элек Витя белән проблема да булып алган иде, хәзер җайланды инде. Мин бит аны армиягә алмасыннар өчен милиция батальонына урнаштырган идем. Ике ай да хезмәт итмәде, качты. Хәрби билетын көчкә бирделәр. Бераз басым ясамыйча да булмады. Дөньясы шундый бит хәзер. Кая гына барма, бөтен нәрсә өчен танышлык кирәк. Связьлар гына яшәтә бу заманда адәм баласын… Ярый, мин күп сөйләшә башладым бугай. Үзең турында сөйлә инде.

— Турысын гына әйткәндә, Олег, минем тормышта әллә ни яңалык юк. Һаман да буйдак әле. Берничә гәзит-журналда эшләп алдым. Хәзер менә профессиональ язучы.

— А! Алайса, син китабыңны чыгарып сөйләш инде.

— Булганын өләшеп бетердем шул. Икенче килгәндә, һичшиксез, алып килермен.

— Нәрсә язасың?

— Күбрәк лирика инде. Соңгы вакытта поэмага алынырга исәп.

— Молодец! Син укыганда ук талантлы егет идең, Илфак. Мин синең каләмең барлыгына ышанам. Йә, сөйлә, нинди йомыш белән килдең?

Илфак сүзне ерактан башлады.

— Беләсеңме, Олег, — диде ул, тамак кырып. — Безнең Ерганак урамында йортлар яна башлады бит.

Олег кычкырып көлеп җибәрде.

— Әйттең яңа сүз, Казанда янгын булмаган көн юк та бугай.

— Ә бездә йортларны махсус яндыралар.

— Ничек инде махсус?

— Халыкны Ерганак урамыннан Азинога күчерү өчен. Матур урын бит, һәр тарафта яшеллек, кеше кызыкмаслык җир түгел. Күптән түгел менә күрше Толикларның йорты янды. Юктан гына түгел дип уйлыйм. Ничә йорт янды, ә һәр очракта бер җавап: электр чыбыгында замыкание булган, имеш.

— Нәрсә белән дәлилли аласың?

— Дәлилләр юк. Бер нәрсәне тикшереп карарга булышсаң, мәсьәләгә, бәлки, нинди дә булса ачыклык кертеп булыр иде.

— Сөйлә, сөйлә, — диде Олег. Аның йөзе җитдиләнеп китте.

— Иң әүвәл Толикның йорты кем исемендә икәнен белергә кирәк, минемчә. Аңа йортны сату турындагы документка көчләп кул куйдырганнар дигән шигем бар.

— Аңлашылды. Шик бар икән, димәк, тикшерергә кирәк. Мин бу мәсьәлә белән бүген үк шөгыльләнә башлармын.

— Рәхмәт.

— Рәхмәтне соңыннан әйтерсең, — диде полковник елмаеп. — Бераз тотасыңмы?

— Элек тоткалый идем, хәзер бик шаярмыйм инде. Мәчеткә йөри башладым бит.

— У-у, тәмам тәкъва егеткә әверелеп беткәнсең син, малай.

Илфак шаяртуга шаярту белән җавап бирде:

— Бигүк тәкъва түгел шул әле, тәмәкене ташларга кирәк. Ярый, Олег, монда сиңа комачау итеп утырып булмас, китим инде мин. Кайбер ашыгыч эшләр дә бар иде. — Ашыгыч эше юк инде Илфакның, болай гына әйтте. Кешене озак борчымау электән килгән гадәт аның. Аннары никтер уңайсыз хис итте ул үзен. Әллә милиция һавасы ошамады, әллә башка нәрсә, — Алла белгән.

— Жалко, жалко! — диде Олег, аны ишеккә кадәр озатып. — Бу соңгы килүең булмастыр дип уйлыйм.

— Үзең бер килеп чык. Йорт номеры унике. Ерганак урамында бердәнбер сары йорт. Шулай дигәч, кайберәүләр мине шаярта дип уйлыйлар. Унике ел элек буяган идем, һаман тора, шайтан.

— Килеп чыгармын, һичшиксез, килеп чыгармын. Иртәгә үк шылтырат, нәтиҗәсен әйтеп бирермен. Телефоным — җитмеш җиде һәм дүрт ноль. Исеңдә калдырдыңмы?

— Калдырдым, кәнишне. Бик җайлы номер.

Илфак чыгып киткәч, полковник үрелеп селектор төймәсенә басты:

— Филатов говорит. Оперуполномоченного Шпатова ко мне. Срочно!

— Его на месте нет. Может вызвать Васютина?— дип җавап бирде кызу милиционер.

— Нет, мне нужен Шпатов. Когда приедет, пусть заглянет ко мне!

— Слушаюсь!

«Хәсрәт язучы! — дип уйлады полковник, кәнәфигә сеңеп. — Казынмакчы була! Шпатовка әйтеп куярга кирәк, бераз күзәткәләп йөрсен».

Шпатов... Әгәр бу әтрәк-әләмнән ераграк торса, полковник

мондый тайгак юлга кереп китмәгән булыр иде. Барысы да аның сеңлесе Маринаның туган көненнән башланды. Өчәү генә утырдылар. Аракы су урынына эчелде. Таң алдыннан Шпатов, исергәнгә салышып, диванда ятып калды. Ә Марина Филатовны йокы бүлмәсенә өстерәде. Бу кадәр вәсвәсәгә нинди адәм баласы каршы тора алсын? Сихерләнгән кебек, бөтен дөньясын онытты полковник. Утыз яшьлек хатын табигый булмаган сексны ярата икән. Таңга кадәр тәгәрәштеләр. Аннары полковник әкрен генә чыгып шылды. Шпатов берни дә белми калсын, имеш.

Икенче көнне моның кабинетына, тузынып, Шпатов килеп керә. Янәсе, ул аның сеңлесен көчләгән, Марина прокурорга барырга җыена. Тезләре йомшарып китте полковникның. Ачудан күз аллары караңгыланды. Шантаж! Башта ул оперны сугып ук екты. Соңыннан, авыз-борыныннан кан аккан Шпатов медицина экспертизасы турында әйтеп куйгач, өстәл артына утырып, ике кулы белән башын тотты. Менә сиңа, күрәсең булса. Табигый булмаган секс өчен прокуратурада аны башыннан сыйпамаячаклар. Төрмәгә дә китереп тыгулары мөмкин. Бер сүздә булгач, Марина үзен мондый секска Филатов мәҗбүр итте, дип әйтәчәк. Нәрсә кирәк бу Шпатовка? Бик тәвәккәл мужик, аннан җиңел генә котылып булмас. Аптырагач, йомшарып китеп, турыдан-туры шулай дип сорады да. Ә теге елмая, сүзне ерактан башлый.

Өч ел элек аның сеңлесе опекунга бер әбине алган икән. Хәзер нindидер бер ир туганы килеп чыккан. Шуңа күрә әби опекунлык турындагы килешүдән баш тартырга уйлый. Димәк, әби үләргә, ә туганы, аны үтерүдә гаепләнеп, төрмәгә утырырга тиеш. Боларны Шпатов үзе башкарып чыгачак. Ә Филатов әбине туганы үтергән дигән версияне якларга һәм прокурордан җинаятьчене кичекмәстән кулга алу турында карар кәгазе алырга тиеш. Менә нәрсәдә икән хикмәт!

Филатов йөзе ертык оперны КПЗга да тыгып куярга уйлаган иде. Ләкин алдын-артын уйлый торгач, карарыннан кире кайтты. Закон хатын-кызга ныграк ышана, Марина аны бөгәрләп төрмәгә тыгачак. Кыскасы, язмышына буйсынырга булды Филатов. Алга таба күз күрер. Форсаты килеп чыгуга ук бетереп ыргытачак ул Шпатовны. Бусына инде һич шикләнмәскә мөмкин.

Шул ук көнне Шпатов әбине ваннада тончыктырып үтерде. Марина ул чыгып китүгә үк таксофоннан, фәлән йортта кеше үтерделәр, дип, милициягә хәбәр салган. Сорау алганда үзен ничек тотты, юха елан икәнен белмәсәң, кызганып елап үләрсең: елыйелый күзләре шешенеп бетте. Әрәм йөргән икән моңа кадәр, мондый сәләт белән бер дигән актриса да чыккан булыр иде үзеннән.

Әбинең ир туганын кулга алдылар. Ул инде илле яшьне узып бара торган юан гына абзый булып чыкты. Ташкентта хатынын, сигез баласын калдырып кайткан. Әбинең сеңлесенең малае икән. Документлары тәртиптә, Алафузов урамында дворник булып ур-

нашкан. Бик дини күренә. Аракы эчми, тәмәке тартмый. Берәр аламарак бәндә булса, Филатовка болай ук авыр да булмас иде. Ләкин хәзер ул үз башын коткару турында гына уйларга тиеш. Чак кына кызганса, йомшаклык күрсәтсә, шик Маринага төшәчәк. Ә монда тәҗрибәле тикшерүчеләр җитәрлек. Эшне кулларына тапшырсаң, өч көндә телеңне чишәләр. Инде болай да әлеге җинаять эшен бер ел да эшләмәгән яшь тикшерүчегә бирде.

Тикшерү барышында Марина бөтен гаепне әбинең туганына сылады. Имеш, ул садист, көн саен килеп тавыш куптарган, әбине үтерергә ант иткән. Теге, бичара, мондый нахак гаепләүләргә, сары чәчле марҗаның оятсызлыгына чыдый алмыйча, һәм дә үзенең мәет янынннан табылган тәмәке төпчеге белән ватык күзлеген күреп, тикшерүче алдында ук йөрәге ярылып егылды. Ә бу матди дәлилләрне хәйләкәр Марина әзерләп куйган иде. Дөрес, Филатов тикшерүчене ашыктырмаса, бу җинаять эше бераз озаккарак та сузылган булыр иде. Абруе зур әле аның. Прокуратурада, Филатов ялгышмас дип, эшне ябарга булдылар.

Бераз вакыт узгач, фатир Маринаныкы булды. Аны сатып акча бүлешкән көнне Филатов «Сәфәр» ресторанында утырды. Күпме эчкәнен хәтерләми, Марина таксида өстерәп алып кайткан. Болай егылып эчкәне юк иде әле. Күрәсең, намус газабын шулай басарга теләгәндер. Өйгә кайтмады, чөнки хатыны, балалары алдында оят иде. Аракыны авызына койды да койды, койды да койды. Иртәгесен эшкә дә бармады, кәрәзле телефон аша, ашыгыч эш белән Мәскәүгә китеп барам, дип хәбәр итте. Хезмәттәшләре күзенә күренергә курыкты ул. Әйтерсең алар аның турында барысын да белеп торалар. Марина белән рестораннарда ешрак буталып йөрсә, беләчәкләр дә беләчәкләр инде. Без капчыкта ятмый, диләр бит. Нинди хурлык!

Полковник көне буе зәңгәр күзле Марина кочагында ятты. Чибәрлеккә чибәр үзе, юха елан. Дулкынланып, чәчелеп торган сары чәч толымнары, чия иреннәре, ап-ак тешләре күз явын алып тора, аларга карап туеп булмый, алар фәкать үбәр һәм иркәләр өчен яратылган. Ә Марина иркәләнә дә, иркәли дә белә.

— Мой рыбенок! — Менә шундый сүзләр әйтеп, иреннәрен чупылдатып, ул махмырдан ухылдап яткан ирнең авызына шәраб һәм кара уылдык сала. Аннары, аның борчылганын сизеп, тирләгән маңгаен, битләрен сыпыргалый, тынычландырырга итә. — Не бери в голову, все будет нормально!

Бусында әле кешелек сыйфатлары бетеп җитмәгән. Дорфа кыланмый, бераз кызгана да кебек. Ләкин үзе дә тыныч түгел, ник дигәндә, аның белән беррәттән шәраб чөмерә. Тик никтер исерми. Юкса хатын-кыз ирләргә караганда тизрәк исерергә тиеш бит. Кыскасы, ирләр психологиясен яхшы белә торган хатын бу. Ун ир белән генә түгел, меңнәр белән йоклаганга охшый. Меңнәр астыннан вибратор килеп чыккач та оялмады. Хәзер ирләр

юк, хатын-кызларның күпчелеге шуның белән рәхәтлек ала, дигән була. Әйе, дөнья үзгәрде. ОРТ каналындагы тапшыруда әнә берәү кыяр да күтәреп чыкты. Огурец — он как вечный солдат, дигән була бит. Тамашачының күңелен ача, имеш. Тфү!

Марина, аның уйларын укыгандай, моңсу гына әйтеп куя:

— Һаман да борчыласыңмы? Такова жизнь, бәгырькәчем. Не мы первые, не мы последние. Оглянись вокруг, все грабят. Потому что страна воровская. Әллә син мине хәерче тормыш канәгатьләндерә дип уйлыйсыңмы? Юк, канәгатьләндерми. Башкалар талаганда мин нигә карап торырга тиеш? Минем дә тәмле ашыйсым, матур киенәсем, Гавай, Канар утрауларында ял итәсем килә. Гомер бер генә бирелә кешегә. Алла, намус дигәннәрен йә ахмаклар, йә куркаклар уйлап тапкан. Үзең күрмәгән нәрсәгә ничек ышанырга була? Минем бер танышым әйтмешли, пәйгамбәрлек — афериزмның иң югары ноктасы ул.

Исерек хатынның Аллага каршы әйткән сүзләрен тыңлый-тыңлый, Филатовның күңеле болгана башлый. Аңа бу кызык түгел, чөнки күңелендә шом утыра. Фатирга менә-менә бер төркем спецназ бәреп керер төсле.

— Эй, син йоклыйсың мәллә? — Марина бармагы белән аның борын очына төртә. — Йоклама, юкса миңа моңсу булачак. Сөйлә әле берәр нәрсә!

— Хәл юк, — дип мыгырдый полковник. — Башка вакытны сөйләрмен. Хотя бер сорау биреп карыйсым килә үзеңә.

Марина, тахта-караваттан торып, өстәлдәге апельсинны әрчергә керешә.

— Сорап кара.

— Хәзер инде мин кирәк түгелме?

— Анысын Шпатовтан сорарсың.

— Әллә атылырга инде? — Филатов шаяртмады, аның башында, чыннан да, шундый уй туа башлаган иде.

Марина кычкырып көләргә тотына:

— Нет, не застрелишься. Духу не хватит! Так и будем мы с тобой…

— Что мы будем?

— А ты думаешь, что твой опер тебя в покое оставит? Ни хрена подобного, он даже свою сестренку не пожалел.

Филатов зәһәрләнә башлаган хатынның күзләренә туры карамыйча гына сорап куя:

— Ул сине дә мәҗбүр иттемени?

— Ә син ничек дип уйладың? Әлбәттә, мәҗбүр итте. Ул инде ятимнәр йортында вакытта ук мине башка балаларның әйберләрен урларга мәҗбүр итә иде. Ә каршы килсәң, шундук типкәләп ыргыта. Тәнемнең кара янмый йөргән чагы бик аз булды минем.

— Алай икән, — дип мыгырдый полковник, тамак кырып. — Ә эти-әни?

— Машина бәреп китте аларны. Миңа алты, Володяга җиде генә иде әле ул вакытта. Алар исән булса, бәлки, минем тормыш бөтенләй башка юлдан киткән булыр иде. Мин бит заманында медицина институтына укырга керергә хыяллана идем. Беренче имтиханда ук «ике»ле куйдылар. Моның өчен бик күп акча кирәген белмәгәнмен шул.

— Карале, Марина, әгәр мин сезнең белән хезмәттәшлек итәргә теләмәсәм, син мине судка бирер идеңме? — ди Филатов, сүзне икенчегә борып.

— Запросто! — Хатын кычкырып көләргә тотына. Аннары бераз сулыш алгач, янә аның янына сузылып ята. — Не переживай, не ты первый, не ты последний.

— То есть?

— Кичә мин телевизордан бер тапшыру караган идем. Анда бер КГБ полковнигы турында сөйләделәр. Фамилиясе Попов иде, ахрысы. Менә шул полковник, Америка разведкасы белән хезмәттәшлек итеп, Советлар Союзына беләсеңме күпме зыян китерә?.. Егерме миллиард сумлык зыян китерә ул безнең илгә! Егерме миллиард! Син бу санны күз алдына китерә аласыңмы?.. Ә хәзер уйлап кара, син кем дә ул кем?

— Аңлаешлырак итеп сөйлә.

— Ярый, аңлаешлырак итеп сөйлим. Попов кебек кешеләр алдында син гап-гади пешка гына бит, бәбекәчем. Гөнаһсыз бала, кем әйтмешли. Попов ил кадәр илен саткан. Ата-анасын, хатынын, балаларын саткан, наконец. Ә син илгә тугрылыклы хезмәт итәсең, шуның өстенә аны артка өстерәүче сорыкортлардан коткарасың. Бу очракта үзең өчен бераз гына акча эшләү турында уйлау начар күренешмени? Синең дә тамагың бар, гаиләң бар. Аларны ничек тә булса туйдырырга кирәк бит.

— Туйдырырга гына җитә иде акча.

— Тиле! Бу илдә инде күптәннән һәркем үзенчә яши. Акча өчен генераллар, министрлар сата илне. Аны президентлар да сата хәтта. Горбачев Советлар Союзын таркаттымы?.. Таркатты! Ельцин таркату эшен дәвам иттеме?.. Итте! Бу илне сату булмадымы? Министрлар дәүләт миллиардларын кесәсенә тыга. Ә син читтә калырга тиешме? Исеңә төшер, нинди куәтле империяне югалттык без! Хурлаган булабыз тагын үзен. Таларлык җайлары калмагач, казна караклары, шул ук озын куллы министрлар, генераллар хурлады аны. Мондый җинаятьчелек, мондый җимереклек, мондый ятимлек революциядән соң да, сугыштан соң да булмаган. Чыгарга куркыныч урамга!

Менә шундый сөйләшү булды алар арасында. Филатов кичке якта гына өенә кайтып керде. Елап, шешенеп беткән хатыны Лена аны килеп кергән шәпкә яңаклап алды. Погонына Маринаның берничә бөртек чәче ябышып калган икән. Ничек кенә акланса да, Олег үзенең туры юлда йөрүенә ышандыра алмады. Хатын-

кыз эт кебек сизгер бит ул, аны алдап булмый. Елена да аның чит хатын-кыз куенында ятканын аңлады. Әле ярый балалар өйдә булмады, юкса оятыңнан җир тишегенә кереп китәрсең. Бер атнарак элек, ул аларны Сочидагы ял йортына җибәргән иде.

Бераздан тормыш үз урынына утыра башлады кебек. Полковникның күңеле бераз тынычлана төшге. Форсаты чыгуга Марина белән очрашу ягын карады ул. Әмма өйгә һәрвакыт вакытында кайта, вакытында китә торган булды. Теге көнне Марина үзенең чәч бөртекләрен юри калдырган икән. Һәр очрашкан саен, ул аның йә күлмәк якасында, йә муенында кершән эзе калдырырга тырыша. Олегта инде тәҗрибә бар, көзге каршында яхшылап каранмыйча өйгә кайтып керми. Марина бервакыт битендәге елтыравык белән дә ышкылгалап караган иде, тирләдем, дигән сәбәп табып, сабынлап битен юып куйды. Бу Маринага нигә кирәк? Мөгаен, Олегны үзенеке итү өчендер. Әйе, шулай икән. Беркөнне Марина абыйсын юк итү турында сүз кузгаткач аңлады ул моны. Гомере буе кеше үтереп, фатир үзләштереп яшәп булмаячагын ул да яхшы белә икән. Ә Шпатовтан котылу Филатовның үзенә дә файдага гына. Ләкин ул әле Маринага ышанып бетми. Сынау, тикшереп карау гына да булырга мөмкин бу.

Оперның нәфсесе зурдан. Акчасын казинода туздырып бетергәч, ул ике бүлмәле фатирында притон оештырып ятучы бер наркоман кызны күзәтү астына алды. Фамилиясе — Ермолова. Ике ел элек аны университетның өченче курсыннан куып чыгарганнар. Шактый данлыклы фамилия. Әти-әнисе медицина фәннәре докторлары. Хәзер икесе дә вафат. Бердәнбер кызларының наркоман булуын күтәрә алмаганнардыр инде. Кызның башка туганнары юк. Димәк, аның фатирын үзләштерү бик җиңел булачак. Башта ул бу эшне кансыз гына башкарып чыгарга уйлаган иде. Ник дигәндә, Ермолова инде йортта булган бөтен җиһазны сатып бетергән, өендә шул бер иске өстәл дә бер урындык кына калган. Эшләр болайга киткәч, аннан фатирны да арзан гына бәягә сатып алырга мөмкин. Наркоман эчкече генә түгел, акча дигәндә, ул фатирын да, ата-анасын да сата.

Ләкин Шпатовның уе барып чыкмады. Фатир турында сүз кузгатуга, кыз аны сүгенә-сүгенә куып чыгарган. Алай гына да түгел, лифтка кереп барганда: «Тебе моя квартира нужна? Получай, козел поганый!» — дип, башына пластмасс чиләк тә томырган әле.

Шпатов яный башлагач, кыз күтен һәм телен генә чыгарып күрсәткән. Артыгын кыланмаган опер. Кыргызстаннан кайтып фатир эзләп йөрүче репатриант рәвешендә килгән бит. Милициядән икәнлекне сиздерергә ярамый, эзгә төшүләре мөмкин.

Азды опер, Филатовны инде күптән санга сукмый. Көннәр буе әллә кайларда югалып йөри. Иртәнге пятиминуткаларга да соңга калып килә. Башка оперлар бу хәлгә инде гаҗәпләнә дә

башлады бугай. Бүген дә иртәдән бирле юк Шпатов. Мөгаен, Ермолова фатиры тирәсендә болганадыр. Притон оештырган вакытында наркотик белән эләктермәкче була. Ә наркоманнар андый ахмак түгел, алар милиция исен сизүгә үк урын алыштыралар. Хәзер ярты елсыз анда күренмәсәң дә ярый инде.

«Тизрәк юк итәргә кирәк кабихне, — дип уйлады полковник, тешен кысып. — Юкса башка җитәчәк».

Шул мәлне селектордан кизү милиционер тавышы ишетелде:

— Товарищ полковник, Шпатов прибыл.

— Минем янга күтәрелсен.

— Слушаюсь!

«Тагын нәрсә дияр икән? — Гасабилана башлаган Филатов, тәмәке кабызып, тәрәзә янына килеп басты. — Ничего, все равно замордую гада!»

Минут та узмады, ишектә Шпатов пәйда булды. Хәзер ул монда үзен хуҗа итеп тота. Әнә, рөхсәт тә сорап тормыйча, өстәлдәге графинның авызыннан голт-голт итеп су эчә башлады. Акайган зәңгәр күзләре шакалныкы кебек уйнап кына тора.

— Йә, кайда йөрдең моңарчы? — диде Филатов, нәфрәтен тыя алмыйча.

— Теге сучканы саклап утырдым. — Опер ухылдап, өстәл янындагы урындыкка килеп сеңде. Авызыннан җен исләре килә. Кичә каты гына җиффәрткән, күрәсең. — Дүрт сәгать вакытны әрәм иттем!.. Ничего, все равно поймаю, а пока, пускай, малость поживет. Жизнь-то она сладкая штука. Ха-ха-ха!

— Чамалабрак! — диде полковник ыжылдап. — Үзеңнең кайда утырганыңны белеп кылан!

Шпатов кул гына селтәде:

— Да ладно тебе, тоже мне начальник нашелся.

— Повторяю, говори, да не заговаривай! — Филатов йодрыгы белән өстәлгә китереп сукты.

— Ярый, ярый, тынычлан, начальник, — диде опер җитдиләнеп.

— Менә шулай дөресрәк булыр… Тәк, кем турында сөйли башлаган идең әле син?

— Ермолова турында инде… Бүген синең ярдәм кирәк булмас. Маринаны үзем белән алырга туры киләчәк. Ермолова мине таный, ишек ачмавы мөмкин. Ә эчкә кергәч, мин аны шундук бөгәрләп салачакмын.

— Ярый, үзеңә кара. — Полковник Илфак турында әйтмәкче иде, ләкин шундук тынып калды. Аның башына бер дигән фикер килгән иде. Ул бу әтрәк-әләмне җинаять урынында үтерәчәк!

«Сеңлесен дә шунда дөмектерергә кирәк, — дип уйлады ул. — Жалко, конечно, әмма хатын-кызга ышанган ир ахмак кеше ул. Барыбер кайчан да булса сатачак. Акча бар, тагын да матурракларын табарга мөмкин».

— Нәрсәгә чакырдың? — диде опер.

— Болай гына, бераз эш турында да онытма дип әйтергә теләгән идем. Алдыңны-артыңны карап йөр. — Филатов янә тәмәке кабызды. — Ә, тагын бер соравым бар икән әле. Теге Кабан һәм Чибик кушаматлы бәндәләр безне сатмасмы?

— Юк, икесе дә ышанычлы егетләр.

— Мин аларның кем икәннәрен белә аламмы?

— Менә бусы инде, иптәш полковник, синең өчен сер булып калсын. Мин үземнең осведомительләремне сатмыйм.

— Ә дөньяда нәрсә генә килеп чыкмас?

— Килеп чыкса, әйтермен, борчылма.

— Ә алар мине беләләрме?

— Юк.

— Бусы яхшы… Димәк, син бүген Имәнлек урамында буласың?

— Әйе.

— Ә Марина кайда?

— Минем машинада утыра.

— Ярый, ни пуха!

— К черту! — Опер торып ишеккә таба юнәлде. — Эшне төгәлләгәч, мин сиңа хәбәр салырмын, начальник. Син борчылма, барысы да тәртип булыр.

— Амин, шулай булсын.

Опер чыгып киткәч, полковникның йөрәге кысылды. Бүген хәлиткеч көн булачак. Шпатов белән Маринаны юк итүгә, яңа тормыш башлап җибәрәчәк ул. Җитте, һәр нәрсәнең чамасы була. Ә Чибик белән Кабанның аны белмәүләре мәсьәләне җиңеләйтә. Шаһитлар никадәр аз, шуның кадәр яхшырак. Тик менә ата алыр микән ул аларны? Соңгы мизгелдә калтырап төшсә? Юк, калтырап төшәргә ярамый, Ермолова фатирында аның язмышы хәл ителәчәк.

Полковникның йөрәге тагын уйнарга тотынды. Элегрәк валидол да булыша иде, хәзер әллә нинди көчле дарулар да тәэсир итми. Көн дә кан басымы, көн дә колак шаулый. Хастаханәгә барып кардиограмма төшертеп карарга вакыт таба алма инде. Болай булгач, бармыйча да хәлең юк.

А, шайтан, һава җитми, инде күз аллары караңгылана... Күзгә күренгән бөтен нәрсә эңгер-меңгер вакытында кебек. Әллә кояш тотылдымы? Кемдер чаң кага: даң-ң-ң, даң-ң-ң. Туктасыннар иде!

Ул чайкала-чайкала торып басты. Үзе белән нәрсә булганын аңламыйча, калтыранган куллары белән инде бөтенләй күренмәс булган өстәлне капшарга кереште.

— Коткарыгы-ыз… — Тавышы бөтенләй чыкмады Филатовның. Барысы да куркыныч төш кебек.

Кинәт аяк астыннан идән дә шуа башлады. Штормга эләккән

кораб палубасы кебек айкала. Җир тетриме? Шулайдыр, хәзер барысына да ышанырга була. Алайса, нигә берни дә аумый, дөбердәми, шапылдап төшми?

Ул каядыр оча... Төпсез упкын бу! Үз кабинетында утыра иде бит. Мөмкин хәл түгел. Әйтерсең аны тугызынчы каттан ыргытканнар. Ә аста берни дә күренми. Хәер, мескен генә яктылык күренгән кебек. Ләкин ул һич якынаймый. Күңел дә болгана, гүя ял паркындагы шайтан тәгәрмәчендә әйләнә.

Чү! Кемнәрдер чабыша, гасабилы тавышлар ишетелә:

— Скорый чакыртыгыз!

— Чакырттык инде.

— Күптәнме?

— Унбиш минутлап булыр.

— Озак маташалар. Якында гына бит үзләре. Пульсы бармы?

— Сизелер-сизелмәс кенә.

— Начар, бик начар…

— Ул үлә…

Кем турында сөйләшәләр?.. Филатов үләме?.. Ничек инде үлә? Аңа үләргә иртәрәк!

— Алло! «Ашыгыч ярдәм» машинасы кайда?.. — Бусы опер Васютин тавышы. — Нәрсә?.. Ватылып калды?.. Вот уроды! Алайса, икенчесен җибәрегез… Ничә минуттан?.. Унбиш?.. Ярый, көтәбез. Карагыз аны, полковник Филатов үлсә, мин сезнең җаныгызны алачакмын!

«Мин үләм. — Шундый уй узды Филатовның башыннан. — Мине беркем дә коткара алмаячак».

Бер мизгелдә бөтен тормышы күз алдыннан узды аның. Дөрес яшәмәгән икән, сагынып искә алырдай берни дә юк. Хатыннан, балалардан башка берни дә юк!

Тагын упкын, тагын аяк тавышлары, шөбһәле авазлар… Ара һаман саен ерагая. Аңа суык, колакта әллә җил, әллә сыбызгы сызгыра… Туктатыгыз! Кем шаяра?!

Каршында үлем басып тора түгелме?! Әччәч, йөзе ап-ак! Кемгәдер охшаган, искә генә төшереп булмый. Башында кара капюшон, бер кулында нәкъ риваятьләрдәге кебек очлы чалгы, икенче кулында — сыбызгы. Чалгысы аңлашыла, бусы җан кыя торган корал, ә сыбызгы нигә? Аның кулында сыбызгы булырга тиеш түгел. Уф, канга, җанга, тешкә тия!

Бөтен дөнья ап-ак, әйтерсең томан төшкән.

Үлем әкрен генә ерагая башлады. Аны тыз-быз килеп йөргән адәм сурәтләре алыштырды.

Диспетчер тавышы:

— Мадрид — Вашингтон маршрутында «Боинг» пассажир самолеты белән һәлакәткә юлыккан әрвахларның унбишенче кабинага керүләрен сорыйбыз.

Аэропортмы?.. Алай булгач, нигә «әрвахлар» ди? Әрвах ди-

гәннәре үлгән кеше була бит… Тфү! Һичбер нәрсә аңлашылмый, барысы да буталды.

— Филатов Олег Дмитриевич! Беренче номерлы билет кассасына килегез!

Нинди касса, нинди билет?! Ул бит беркая да очарга җыенмый. Аңа «ашыгыч ярдәм» машинасы чакырттылар. Авыру килеш ничек юлга чыксын?

Менә томан тарала башлады. Баксаң, ул зур гына пыяла бинада, затлы кызыл кәнәфидә утырып тора икән. Кулында зур гына дипломат та бар. Дипломат тотырмаганын яхшы хәтерли ул. Бик авыр күренә. Нәрсә булыр анда?

Дипломатны ачып җибәргәч, полковник чак кына егылып китмәде. Анда аның гомер буе җыйган акчасы ята!.. Кем кассадан алган? Кем дипломатка тутырган?.. Бусын бер Алла белә.

— Господин Филатов, кабатлыйм, сезнең беренче номерлы кассага килүегез сорала. — Тагын диспетчер тавышы.

Чакыралар икән, барырга кирәк, дип уйлады полковник. Нинди билет ул тагын? Филатов беркая да барырга җыенмый, шуны белегез! Хәзер күрсәтәчәк ул аларга үзенең кемлеген!

Әйләнә-тирәне бер кат күздән кичергәч, ул, әтәчләнеп, каршы якта торган кассага атлады. Тирә-юньдә гаҗәеп матур гөлләр үсеп утыра, бина дивары пыяладан гына булса да, тышта күзләрне камаштыргыч зәңгәр киңлектән башка берни дә күренми. Әйтерсең бу бина күктә эленеп тора. Сәер, бик сәер аэропорт!

Кассир матур хатын-кыз иде. Бөдрәләнеп торган озын сары чәче, күк йөзедәй зәп-зәңгәр күзләре һәркемнең һушын алырлык.

— Миңа беренче кассага килергә куштылар, — диде полковник.

— Фамилиягез? — Тавышы да сөйкемле, каһәр.

— Филатов… Олег Дмитриевич, — дип мыгырдады каушап калган полковник.

— Сезгә беренче кабинага. — Кассир хатын аңа кызыл төстәге билет сузды. — Җиденче катта әти-әниегез белән очрашырсыз. Аннары сезгә Утлы Боҗра планетасына очарга кирәк булачак.

Бу сүзләрне ишеткәч, Филатовның күзләре акайды.

— Утлы Боҗра планетасына?.. Беренче тапкыр ишетәм… Га… гафу итегез, мин бит космонавт түгел.

— Сорауларыгызны җиденче катка күтәрелгәч бирерсез.

Полковник, як-ягына каранып, пышылдап кына әйтте:

— Аннары минем әти-әнием үлгәнгә дә дүрт-биш ел вакыт узып китте бит инде… Нинди очрашу ул тагын?.. Сеңлем, ә башка төрле билет юкмы?.. Әйтик, поездга, пароходка.

Кассир моңсу гына елмаеп куйды:

— Сез үлдегез бит инде, абый. Андый билетлар җирдә генә була.

— Алай икән. — Полковникның тезләре калтырап куйды, елап

җибәрде. — Үлгәнмен, значит… Үләсе килми бит, сеңлем. Алай-са, кире якка билет бир. Нинди транспорт булса да ярый. Самолет та, пароход та, хәтта космик кораб та бара. Акчам бар, күпме теләсәң, шуның кадәр бирәм.

— Үләсеңне алданрак уйларга иде, абый.

— Соң, кем белгән аны теге дөньяда мондый галәмәтләр барын. Совет чорында, Алласыз чорда үстек бит, матурым. Белгән булсам…

— Гөнаһларыгыз бик зур, абый. Язмышыгызга буйсыныгыз, барыбер җавап тотарга туры киләчәк.

— Мин үтерүче булырга теләмәгән идем, сеңлем, валлаһи теләмәгән идем. Шпатов мәҗбүр итте, сеңлесе Марина белән шантажладылар. Мә, ал акчаны, сумкасы белән бирәм. Доллар белән бирәм, сеңлем!

Шул мәлне аның янына таза гына бер егет килеп басты. Күмер кебек кара йөзле, көдрә кара чәчле. Тышкы кыяфәте белән тач опер Васютин инде менә.

— Олег Дмитриевич!

Филатов үзенең өстенә иелеп текәлгән милиционерның чыннан да Васютин икәнен аңлап, имәнеп калды. Аэропорт та, матур кассир хатын да саташу гына булган икән. Хастаханәдә — реанимациядә, система астында ята ул! Артыгын ычкындырды бугай. Черт! Нигә килгәннәр?

— Васютин? — дип мыгырдады полковник, хәлсез тавыш белән.

— Әйе, мин, Олег Дмитриевич.

— Күптәннәнме мин монда?

— Өченче көн китте, Олег Дмитриевич, өченче көн Шпатовны кулга алдылар, — диде Васютин. — Имәнлек урамындагы алтмыш өченче фатирдан бер кызны үтереп чыкканда эләктергәннәр. Ишекне сеңлесе Марина ачтырган. Эләктермәгән дә булырлар иде, күрше хатыны глазоктан таныш калган. Заманында ул Шпатовлар тәрбияләнгән ятимнәр йортында тәрбияче булып эшләгән икән. Шпатов бөтен гаепне сезгә өя. Бүген аңа ялган документлар тутырырга ярдәм иткән нотариусны да кулга алачаклар. Качып өлгермәгән булса, әлбәттә.

Полковникның тагын күз аллары караңгыланды.

— Не может быть! — диде ул, сулышы буылып. Тагын бөтен дөнья зыңгылдый, тагын упкын.

— Что не может быть?.. Олег Дмитриевич! — Васютин тавышы бу. Төпсез караңгылык эченнән, яңгырап, колакларны сызлатып ишетелә. — Сезгә начар мәллә?.. Сестра, где вы?!

— Что случилось?

— Ему плохо, позовите врача!

— Я здесь… Остановка сердца… Черт! Я же говорил вам!.. Маша, готовь адреналин!

Менә Олег инде кассир хатын әйткән беренче кабинага кереп бара. Саташу булмаган икән бу. Ул үзе генә. Лифтка охшаганрак җайланма иде ул, тик бераз иркенрәк итеп эшләнгән. Аннары анда бернинди дә төймә юк.

Ул кереп басуга, шуылмалы ишек тавыш-тынсыз гына ябылды да кабина зур тизлек белән югарыга күтәрелә башлады. Тизлек арткannan-арта, һава басымы үзгәрүдән Олегның хәтта колагы тона башлады. Хәер, аның нәрсә икәнен кем белгән. Ул бит үлде, шулай булгач, нинди колак тону ул тагын? Аның җаны гына утыра бу кабинада. Алайса, дипломатны ничек тотып бара? Менә бит, кулы да, аягы да бар… Тфү! Һичбер нәрсә аңлап булмый.

Ниһаять, кабина туктады. Ишек ачылып китүгә, ул гаҗәеп матур бер бакчага чыгып басты. Тирә-юньдә алтынсу төстәге таш белән әйләндереп алынган фонтаннар су коя, алар тирәсендә искитмәле хуш исле чәчәкләр үсеп утыра. Каштанга охшаган агачлар башында чуар каурыйлы төрле матур кошлар сайрый. Эссе. Кояш нәкъ баш очында.

Якындагы фонтан янында, эскәмиядә утырган ике таныш адәмне күргәч, Олег аһ итте. Әтисе белән әнисе ич бу! Аларны үлгәч ничек киендергәнен бик яхшы хәтерли ул. Әтисе көрән төстәге костюмнан, ак күлмәктән, кызыл галстуктан иде. Ә әнисенә аның иң яраткан озын кара күлмәген киерттеләр.

— О, господи! — дип пышылдады полковник.

— Улым. — Әнисе инде аның янында. Моңсу елмаеп, улын кочаклап алды. — Сагындым сине, балакаем!

Олегның күзләренә яшь килеп тыгылды.

— Мин дә сагындым сине, әни.

Әтисе генә килергә ашыкмый, аларны читтән күзәтеп утыра.

— Рәхәтләнеп сөйләшәсе иде дә бит, күрешер өчен бик аз вакыт бирелде, улым, — диде ана, күңеле тулып.

— Әтинең кәефе юк, ахрысы?

— Ул сиңа үпкәләде.

— Нигә?

— Кеше үтерү юлына баскан өчен.

— Син беләсеңмени?

— Монда бөтен нәрсәне дә беләләр, улым.

— Ә син мине гафу итәсеңме, әнием?

— Гафу итәм. Ләкин сине зур җәза көтә.

— Беләм, баштан сыйпамаслар. — Олег анасының күкрәгенә башын куйды. — Аллаһының рәхмәте киң, әнием.

— Өметеңне өзмә.

— Әтигә әйт, мин аны бик тә яратам. Рәнҗемәсен.

— Әйтермен.

Олег тагын нидер әйтмәкче иде, ләкин әнисе шундук юк булды. Күрәсең, очрашу вакыты чыккандыр. Аны сагыш хисе биләп

алды. Җавап бирәсе көннәр алда әле, аерылышу озакка булачак. Нишлисең инде, язмышы шундый, димәк. Юлында Шпатов очрамаган булса, аңа хәзер бераз җиңелрәк булыр иде. Аллаһы сынавы булган икән!

Инде дөньяны салкын караңгылык каплады. Ул тагын каядыр оча, ә аста коточыргыч төпсез упкын теш шыкырдата иде.

## Үзгәрергә кирәк

Олегның вафатыннан соң, Илфак аңына килә алмыйча йөрде. Курсташы, бандитизмга каршы көрәш бүлеге начальнигы шундый кеше булып чыккач, ни эшләргә, кемгә ышанырга? Ә ничек матур каршы алган булды бит. Баксаң, Толикларның йортын яндыруда да аның катнашы бар икән. Батыр башына хатын-кыз җитә, дип юкка гына әйтмәгәннәр шул. Аракы белән хатын-кыз министрларны да кәнәфиеннән очырта. Оят онытылды кешедә. Ахырзаман галәмәте бу. Кемнең кулында — шуның авызында, дигән шигарь җәмгыятьнең иң караңгы, иң тузанлы почмакларына да үтеп керде. Илдә байлык кына түгел, хәтта хәерче хәер эстәп утыра торган урыннар да бүленгән.

Язудан тәмам күңеле кайтты Илфакның. Әрәм бу дөньяга матур рифмалар! Әрәм бу дөньяга акыллы сүзләр!

Ул, каләмен ташлап, урамга чыкты. Чехов базарына барып, рюмочныйда туйганчы аракы эчте. Бу гына җитмәде, кайтып килешли, подвалда шаулашып утырган сукбайлар белән, әллә мәче, әллә эт итеннән авыз итеп, денатурат чөмерде. Дөм исерек булса да, гел аңында булды. Сукбайларның авызларында юньле сүз юк. Кем ничә шешә җыйган да, кем бүген хәер эстәргә чыгар? Сүгенергә өйрәнәм дисәң, шулар янында гына утыр. Килеш-килбәтләренә карасаң, косып үләрлек. Кайберләре, торырга иренеп, йомышын да шунда гына үти. Вәт тормыш! Эт тә чистарак яши.

Ә шигырь сөйләгәнен игътибар белән тыңладылар. Һәркайсы үзенчә фәлсәфә куертып утыра. Менә шунысы гаҗәпләндерде Илфакны. Нәрсә дип җавап бирде әле Таня исемлесе, мондый эт тормышында яшәгәнче, берәр баерак егеткә кияүгә чыгып балалар үстерүгә ни җитә, дигәч?.. Природой брак не предусмотрен, диме?.. Наполеон әйткән икән бу сүзләрне. Унҗиде яшьтә генә әле үзе. Яхшылап юындырсаң, бизәндерсәң, министрларны кызыктырырлык! Үз кадерен үзе белми, бичара.

Утыра торгач, сукбайлар да туйдырды Илфакны. Алар үзләре дә аның акыл өйрәтүеннән туйганнар бугай. Каршысында нибары кулына денатурат шешәсе тоткан Таня гына утыра. Күп эчүдән очкылык та тота башлады. Башкалар инде бер почмакта йокыга китәргә азапланып ята.

Илфак, Таняны битеннән үбеп, нидер мыгырдады да, алпан-

тилпән килеп, өенә кайтып китте. Эчкәндә бөтен кешене дә ярата башлыйсың икән ул. Тик менә иртәгесен генә начар булып китә. Үзеңнең исереклегең, сөйләгән сүзләрең, кылган гамәлләрең өчен ояла башлыйсың. Алай да, чайкалып торуга карамастан, бүген Ерганак урамында Илфактан да аеграк уйлаучы кеше юк иде.

«Барып җиттем тәки, — дип уйлады ул. — Эт, мәче ите генә ашарга калды инде… Болай яшәп булмый, тормышта нәрсәнедер үзгәртергә кирәк. Кайда котылу юлы? Кортлап беткән бу фани дөнья проблемаларыннан арыну юлы кайда?! Теге дөнья бар. Анда әле җавап тотарга туры киләчәк. Димәк, иртәгә үк мәчеткә йөри башларга, көн дә биш вакыт намазны укырга кирәк! Җанны бүгеннән үк пакьләндерә башларга кирәк. Дөньяны агарту һәркемнең үзеннән башланырга тиеш».

Аннары ул юл уңаенда очраган Әнгә янында туктап, аңа кесәсендә калган ишы сыныгын сузды. Маэмай, әллә аның авызыннан килгән аракы, әллә эт ите исеннән чирканып, ырылдый-ырылдый, урам башына элдертте. Үпкәләде Илфак, Алла һәм теге дөнья турында онытып, ачы итеп сүгенде, ачуланды, төкеренде.

…Иртәгесен ул төшкә кадәр урын өстендә аунап ятты. Махмыр төшкән иде. Өстәвенә өйдә чыдап булмаслык эссе, бөтен җиргә чебен тулган. Урамда утыз биш градус чамасы.

Ниләр генә уйлап бетермәде ул! Шушы баш очында түшәм, түшәм өстендә түбә, түбәдән соң бинһая киң күк йөзе җәйрәп ята. Аннан соң кара космос башлана. Нигә аның чиге юк? Чиксез нәрсә буламыни? Чиге булса да, аның артында ни бар? Берсе дә һич башка сыймый. Уйлап карасаң, адәм баласы да аквариум балыгы кебек бит. Җир үз күчәреннән ычкынды исә, без юк! Аннары бу төн белән көн, ай белән кояш та махсус уйлап табылган кебек. Галәмдә шундый тәртип урнаштырыр өчен илаһи гакыл кирәк. Болынга чыгып игътибар белән карый башласаң, нинди генә бөҗәк юк бит. Һәркайсы каядыр оча, йөгерә, үрмәли, шуыша. Хуҗасыз була алмый галәм. Аларны гакылсыз табигать һичничек уйлап таба алмый. Адәм баласы роботларны да кайчан гына ясый башлады. Юкса аның күзе дә, кулы да, акылы да, мие дә бар бит. Ясап кара әле син бер тере чебенне! Кешелек дөньясы моны беркайчан булдыра алмаячак. Уф, уйлый башласаң, баш авырта башлый.

Төштән соң, ниһаять, Илфак торып чәй эчте, тешләрен чистартты, тәһарәт алды. Мәчеткә барырга иде исәбе.

Урамга чыккач, тәмәке кабызмакчы булды. Ләкин шырпысын кабызуга, уеннан кайтып, тәмәкене җиргә томырды. «Яңача булгач, бөтенесе дә яңача булсын! — дип уйлады ул. — Аракыны да эчмим, тәмәкене дә тартмыйм!»

Җомга көн иде бу. Мәрҗани мәчете шыгрым халык белән тулган. Илфак башта ни эшләргә дә белмичә югалып калды. Әйтергә оят, мөселман баласы була торып, мәчеттә үзеңне ничек тотарга

икәнен белмә инде! Алай да ул үзен бик тиз кулга алды, беренче катта утырган яшь кенә мөәзин янына килеп, сугышта һәлак булган ата-бабалары һәм дә дөньядан киткән барча туганнары хөрмәтенә дога укытты, садака бирде. Аннары шунда ук утырган бер туташтан Коръән китабы сатып алды. Кыйммәткәрәк җибәрә җибәрүен. Акчасы булмаган мөэмин-мөселман аны ничек сатып алыр? Алалар шул, ашамасалар да, алалар. Чиратка бастылар инде әнә.

Урамга чыккач, Илфак Коръәнне ачып карады. Аның нинди сүрәдән башланганын да белми бит ул. Адәм хуры! Җитмәсә, шагыйрь булып йөри бит әле! Пушкин булып Пушкин белгән Коръәнне! Толстой да Коръән белән танышып чыккач кына бер аллалыкка килгәндер. Моның өчен чиркәү анафемасына дучар булган ул.

Шул көннән башлап, Илфакны күрүче булмады. Явыз телләр аны, авылына кайтып асылынган, дип сөйләсә, башкалары, Бохарага укырга киткән, дип сөйләде. Ә аның йортында хәзер Себердән кайткан алты балалы гаилә яши. Илфакның туганнары булса кирәк. Ни генә булмасын, аны исән дип уйлау дөресрәктер. Чөнки бер-бер хәл булса, карт әти-әнисе булса да, эзләп килерләр иде.

## Хатлар

*Сәлам Петербургтан!*

*Рафис, кадерлем, бүген мин Казанга кайтып китәм. Котлый аласың, Айсылуың — төзүчеләр академиясе студенты.*

*Синең хәлләр ничек? Диңгезче формасында төшкән фотосурәтеңне күрсәткәч, бүлмәдәш кызлар аһ итте. Көнләшеп үлә яздылар. Нинди чибәр, нинди таза егет икән, диделәр. Тфү, тфү! Күз тидерә күрмим тагы. Ләкин син борыныңны күтәрмә, мин дә ямьсез түгел бит, әйеме?.. Шаяртам. Хатларыңны укыйм да елыйм, укыйм да елыйм. Петербургка киткәндә, мин болай озакка аерылышырбыз дип уйламаган идем. Ай, иркәлисең дә инде мине үзең. Хатларыңны мендәр астына салып ятам. Алар минем күңелгә җылылык биреп тора. Синнән хат килгән көннәрдә, мин очынып йөрим. Каян уйлап табасың шундый матур сүзләрне? Нигә аларны миңа баштарак, су коенганда, йолдызлар санап йөргәндә әйтмәдең? Ә мин көткән идем, бик көткән идем синнән ул сүзләрне. Миндә дә бар сиңа әйтәсе килгән сүзләр... Матурым, баһадирым минем, тизрәк отпускага кайт. Туйганчы чәчләреңнән сыйпыйсым, күзләреңнән үбәсем килә. Кайткач, нәкъ элеккечә Зәңгәр Күлгә барырбыз, су коенырбыз. Икәүдән-икәү генә, бернәрсә турында да уйламыйча, болында күбәләк куып йөрисем килә минем.*

*Армиядә хәзер дедовщина бик көчле, дип сөйлиләр. Сине рәнҗеттимиләрме?..*

*Үзем хат язам, үзем груша ашап утырам. Махсус алып кайт-*

*тым мин аны. Берсе — миңа, берсе — синә. Аерылышкан көнне мине груша белән сыйлаган идең бит. Менә шулай сагынып утыру икеләтә авыр икән ул, Рафис. Груша бетте, ә син һаман юк. Синекенә тимим, аны үзем белән Казанга алып кайтам.*

*Минем өчен борчылма, бу тынчу шәһәрдә фәкать сине генә уйлап, сине генә сагынып яшим.*

*Онытканчы әйтеп китим әле, безнең әтинең рәсемнәр күргәзмәсен Лондонга куйганнар. Анда минем портрет та бар. Беләсеңме, ул аны ничек атаган?.. «Фәрештә карашы» дип. Әти мине ярата, бердәнбер кызы ич. Ә шулай да синең бәгырем дигән сүзең ул портретка караганда мең тапкыр матуррак. Исән-сау кайтсаң, әтигә синең портретны ясатырга заказ бирәчәкмен. Син диңгезче формасында булачаксың. Шулай булгач, син аны гел үтүкләп кенә тор инде.*

*Вакыт, вакыт... Әле кайчан гына ул бик тиз уза иде. Ә хәзер гел бер урында туктап тора. Синнән тагын хат аласымны уйлап, түземсезлек белән алдагы таңны каршылыйм. Ышанмассың, һәрбер хат гаҗәеп бер затлы нәрсә яшеренеп яткан серле сандык, зур могҗиза булып тоела миңа. Конвертны ачкач та шулай. Андагы һәрбер сүз, һәрбер җөмлә гарасат кебек җанны актарып ташлый. Конвертның исе дә серле, тәмле хәтта... Яратам! Ишетәсеңме, яратам!*

*Хатларыңны озынрак итеп яз. Юкса үпкәлим, белеп тор. Мин аларны җыеп барам. Минекеләрне дә яндырма. Очрашкач, аларны бергә укырбыз. Чиратлашып, көлешеп укырбыз. Бәлки... еларбыз да.*

*Сау бул, матурым!*

*1август, 2000, Санкт-Петербург*

*Сәлам Севастопольдән!*

*Айсылу, сине укырга керүең белән чын күңелдән котлыйм. Бу хатымны мин дә груша ашап язам. Шәһәргә чыккач, базарда бер әбидән сатып алдым. Кырым татары икән. Минем татар булуымны белгәч, акчаны кире бирде. Алырга теләмәгән идем, үзе көчләп бирде. Без өчәү идек. Өчебезне дә аркадан сөйде дә елап җибәрде. Күпне күргән икән, мескен, җиде яшендә ятим калган. 1944 елны авылларын НКВД гаскәре урап алып, халыкны машиналарга төйи башлагач, әтисен атып үтергәннәр. Әнисе Үзбәкстанга департацияләнгәндә мал ташый торган вагонда салкын тидереп үлгән. Юлда әби үзе дә тиф белән чирләгән. Ничек исән калганын хәзер дә аңлый алмый. Сугышка киткән абыйларының да исәнме-юкмы икәнлекләрен белми ул. Бала чагы Үзбәкстандагы ятимнәр йортында узган. Элек, закон буенча, кырым татарларына туган җирләренә кайтырга ярамый иде бит. Шунда үзбәк кешесенә кияүгә чыккан, биш бала үстергән. Хәзер менә, рөхсәт булгач, картлык көнендә туган туфракка кайтып*

*егылган. Авылының исемен дә әйткән иде, хәтердә калмады. Аккүз дип әйтте бугай. Шуннан килеп, үзе үстергән җиләк-җимеш белән сату итә икән. Безнең авыл инде башкача атала, анда урыслар яши, ди. Урыслар аларны авылга кертмәгәннәр. Килмешәкләрнең әзер-бәзергә генә кереп утырган таза йортлардан китәселәре килми шул. Әби үз йортларын бик яхшы хәтерли. Ул әле нык, ди. Яңа хуҗасы — хохол кешесе. Кырым татарлары бер чакрым ераклыкта гына яңа авылга нигез салганнар. Хәзер, Аллага шөкер, авылыбыз шау чәчәктә утыра, дип сөйләде әби. Җиләк-җимеш агачлары да үсеп киткән. Ата-бабалары күмелгән зиратны да тәртипкә китергәннәр.*

*Менә нинди илдә яшибез без, Айсылу. НКВД гаскәрләре кырым татарларын үз җирләреннән сөргәндә, күпләр фронтта булган бит. Уйлый башласаң, акылдан язарлык.*

*Ярый, бусы сүз уңаеннан булды. Синең хисле, якты хатыңны алгач, шигырь яздым бит әле. Рифмалары юньле-рәтле булмаса, зинһар, көлмә.*

*...Мин — ярты алма,*
*Син — ярты алма.*
*Икебез без бер алма.*
*Ярты алма карала,*
*Бөтен алма аллана.*
*Кызарып пеш, каралма,*
*Башкаларга карама.*

*Минем грушага тимәгәнең өчен рәхмәт. Кайткач, бергә ашарбыз. Мин дә сиңа бер груша калдырдым. Аны тумбочкага тыгып куйдым. Тик кызганыч, ул инде нык өлгергән, ике-өч көннән бозыла да башлар. Отпуска бирсәләр, Аккүз авылына барып, сиңа иң баллы грушаларны сайлармын, яме.*

*Әле шуны уйлап ятам, синең белән күрешү ничегрәк булыр икән? Тагын үптермәгән булып кыланырсың инде. Әллә ялгышаммы? Кара аны, мин кайтканчы уйлый тор.*

*Солдат тормышы — соры тормыш инде ул, бәгырькәй. Мондагы көн тәртибен сөйләп тормыйм, чөнки кызык түгел. Аз гына вакыт калуга ук сиңа хат язарга утырам. Әйе, сихерләнгән кеше кебек мин, Айсылу. Ә буш вакыт бик аз, монда бер генә минут та эшсез утырып булмый. Безнең прапор, солдат хыяллана башласа, бозыла башлый, дип әйтергә ярата. Шуңа күрә солдат ашханәдә йә бәрәңге чистарта, йә газоннарны тәртипкә китерә, йә лезвие белән унитазларны чистарта. Бусы дисциплинаны бозган кешеләр өчен «наряд вне очереди» була инде. Әлегә, Аллага шөкер, минем андый хәлгә калганым юк. Калсаң да, бер нишләп булмый, гражданкада түгел бит, буйсынырга туры килә.*

*Монда спорт шәп куелган. Мин дзюдо белән дә шөгыльләнәм әле.*

*Армиядә дедовщина нык үскән дип язасың. Ул безгә кадәр дә булган, бездән соң да булачак. Бусы да үзенә күрә бер сынау инде. Монда төрле кеше бар. Сержантларның аяк чолгауларын юучылар да, аларның күн итекләрен чистартучылар да бар. Үзеңне ничек куясың бит. Миңа да чолгау юдырмакчылар иде, булдыра алмадылар. Берсенең ипи шүрлегенә менеп төшкәч, тынычлыкта калдырдылар тагын. Дөрес, бераз үземә дә эләкте инде. Ирләр генә булган җирдә һәрвакыт шулай, кем дә булса лидерлыкка омтыла. Безнең мәктәптә җәйге лагерь оештыралар иде. Анда да үзенә күрә дедлар булды. Өлкән сыйныфтагылар бала-чаганы кибеткә дә, башка кирәк-яракка да чаптырып кына тордылар.*

*Сагындым. Шуннан артыгын әйтә алмыйм.*

*Портретыңның Лондондагы күргәзмәгә куелуы белән дә котлыйм. Тик мин моңа әллә ни сөенмәдем. Чөнки мин яраткан күзләргә, мин яраткан иреннәргә башкалар да сокланачак бит. Көнләшәм! Бу синең соңгы портретың булсын. Синең матурлыгыңны бөтен дөньяга чәчәргә теләмим мин. Әтиеңә шулай дип әйт.*

*Быргы кычкырталар. Шуның белән хатымны тәмамлыйм, бәгърем. Сау бул!*

*Сәлам белән Рафисың.*

*8 август, 2000, Севастополь*

*Сәлам Казаннан!*

*Рафис, хатыңны алдым. Шигырең бик ошады. Мин аны ятлап та куйдым инде. Әйе, без синең белән бер түгәрәк алма, бөтен алма булып яшәргә тиешбез. Ләкин әлегә без икебез ике якта: син — ярты алма, мин дә ярты алма. Тик мин каралмам, матурым, бусы өчен борчылма.*

*Кичә сезгә бардым. Әниең белән бергә өй юдык. Кечкенә Зөлфия дә безгә булышты. Ай, кулга оста да инде үзе! Чиккән яулыкларын, мендәр тышлыкларын карап утырдым. Нинди генә чәчәкләр, бизәкләр юк анда! Инде оялып кына булса да, сер чишәргә мәҗбүрмен, ул мине кулъяулык чигәргә өйрәтте, кайбер матур җепләрен дә бирде. Әле генә сиңа кулъяулык чигеп утыруым иде. Алла бирсә, тиздән аны кабул итеп алырсың. Әүвәле татар кызлары үзләренең егетләренә кулъяулык чигеп биргәннәр бит. Әйт әле, мин аңа нәрсә сурәте төшердем?.. Беләсең икән шул, алма сурәте ул. Ике ярты алма кушылып барлыкка килгән бөтен һәм баллы алма сурәте! Димәк, безнең икебезнең сурәт, Рафис. Бик матур чыкмаган булса, гаеп итмә.*

*Өйне юып бетергәч, син бервакыт төшеңдә күргәнчә кыстыбый пешердек... Нинди төш, дисеңме? Һи, балакаем, исеңдә тот, хатын-кыздан берни дә яшереп булмый.*

*Мунча кермәдем, машина белән әти килеп җиткәч, көттереп торасым килмәде. Ул да кыстыбыйны бик яратып ашады. Беләсеңме ни өчен шундый тәмле булды кыстыбый? Камыры юка*

*булганга һәм каз кауры белән майлаганга. Армиядән кайткач, мин сиңа көн дә менә шундый тәмле кыстыбый пешерермен. Шулай итеп, Рафис, без синең матур төшеңне тормышка ашырдык. Бүгенге сөенечле хәбәрем сиңа менә шушы.*

*Бер атнадан мин яңадан Санкт-Петербургка китеп барам. Матур, тарихи шәһәр булса да, никтер аны бик яратып бетермим. Һава дымлы анда, яңгырлар да еш булып тора. Казаныбызны үлеп сагынасы көннәр алда әле.*

*Ә бездә хәзер кояш. Көн кыскарганнан-кыскарып бара. Беркая да бармыйм, гел телевизор каршында утырам. Армия турындагы тапшыруларның барысын да карап барырга тырышам. Күңелле тапшырулар түгел. Тәртип юк бу армиядә. Көн дә бер солдат армиядән кача. Кайсын аталар, кайсын үле килеш эзләп табалар. Беләм, сиңа да авыр инде анда, сиздермәскә генә тырышасың. Бөтен илдә тәртип булмаганны армиядә генә тәртип булмастыр, шәт. Ләкин килеп эләккәнсең икән, түз, зинһар!..*

*Күрдеңме, чигүдән битәр, минем тагын бер сәләтем ачыла башлады: үгет-нәсихәт остасы да икән әле үзем. Акыл өйрәткәнгә ачуланма. Сине теп-тере, сәп-сәламәт кеше итеп күрәсем килгәнгә әйтәм бу сүзләрне.*

*Син минем портретымның Лондондагы күргәзмәдә торуын теләмисеңмени? Аһ, әшәке, әллә миңа пәрәнҗә дә киертергә исәбең бармы? Вот татарин!.. Онытма, без егерме беренче гасырга кереп барабыз инде. Портретыма гына карап, берәү дә минем матурлыгыма (ә син чыннан да мине бик матур дип уйлыйсыңмыни? Бусы өчен зур рәхмәт!) зыян сала алмас. Хотя, кем белгән, күз тию дигән нәрсә дә бар бит. Күз тисә, ярты алмаң каралмасын дисәң, өшкерүче эзләп табасың инде. Чынга алма, шаяртып язганыңны беләм, шуңа үзем дә шаяртып кына җавап бирәм.*

*Көзгә кереп барабыз. Елның иң купшы, иң матур, иң моңсу фасылы килә җиргә. Хәтерлисеңме, узган ел мәктәптә оештырылган көзге балдан кайтып килешли син: «Көзен көннәр акрын уза», — дип әйткән идең. Петербургта вакытта шушы сүзгә багышлап шигырь яздым мин. Сизәсеңдер, аерылышып тору безгә файдага гына. Икебез дә шигырь белән генә сөйләшәбез бит. Күрәсең, өлгерәбез, матурым.*

*Ә хәзер минем шигырьне укы. Тик гаҗәпләнеп калма, мин аны кәгазьнең буеннан-буена яздым. Чөнки әйтәсе килгән фикеремне дүртьюллыкка сыйдырырга теләмәдем. Анда ул читлектәге кош кебек тыпырчына гына. Аннары фикерне рифма-ритмга сыйдыру да аның чын иркен боза кебек. Кыскасы, шигыремне ничек бар, шулай кабул ит.*

*Акрын уза, дисең, көзге елак төннәр... Шулай була күрсен, алар — безнең көннәр. Бүген һәр минутын саный кайберәүләр. Безгә бит артыгын Аннан җибәрмиләр.*

*Беләсеңме, баһадирым, мин бит Аллага ышана башладым. Әгәр Ул булмаса, бу дөнья бик тә бәхетсез, бик тә ятим, бик тә моңсу булыр иде. Яшәешнең мәгънәсе булмас иде. Мин теге дөньяны үземчә күз алдына китерәм. Адәм баласы өчен вакытның өч төрле халәте бар: үткәннәр инде беркайчан да кире кайтмый, бүгенгебез иртәгесен үткәндә кала, ә киләчәк әле килеп җитмәгән. Ә теге дөньяда барысы да — үткәннәр дә, бүгенге көнебез дә, киләчәк тә бергә булачак. Анда вакыт дигән төшенчә юк. Димәк, үлем дә юк, аерылышу да юк.*

*Кара темага кереп киттем, Рафис. Оныткачы, бер кызык сөйләп алыйм әле үзеңә. Безнең күршедәге Вася абыйны беләсеңдер инде, шәт. Син аңа узган ел гаражларында машинасының тәгәрмәчен ямарга да булышкан идең. Аны күптән түгел генә хәрби сборларга алдылар. Военкоматтан повестка килгәч, бик нык дулап йөргән иде. Бланкысы советларныкы, чакырулары капиталистларныкы, ди. Кайтты инде, капитан дәрәҗәсе биргәннәр.*

*Шуның белән хатымны тәмамлыйм. Өзелеп сагынып калам. Күп итеп яз. Сау бул!*

*Сине үбеп, Айсылуың.*

*14 август, 2000, Казан*

*Сәлам Севастопольдән!*

*Айсылу, шигырең ошады. Фәлсәфи язылган. Аллага ышана башладым, дигәнсең. Бик хуп, инде Аллага да ышанмасаң, бу җирдә кемгә ышанырга? Безнең бу дөньяга килүебез үзе бер лотерея уены кебек. Алай да лотереягә откан акчага, машинага ныграк сөенәбез. Бу гомерне без бүтән бернинди лотереягә дә ота алмаячакбыз лабаса. Безгә үлем турында ешрак уйларга кирәк. Куркаклык түгел бу, акыллылык билгесе. Иртәме-соңмы, ул барыбер ишек кагачак. Чөнки һәрнәрсәнең башы һәм ахыры бар. Үлем киләсен белеп яшәгән кеше комсыз да, әшәке дә булмый. Аны истә тотсалар, җирдә сугышлар да булмас иде.*

*Бүген көне буе кәефсез йөрдем. Икенче ротада бер курсант казарма тәрәзәсеннән сикереп һәлак булды. Саратов ягыннан иде бугай. Сержантларның мыскыллавына чыдый алмыйча сикергән. Ирлек түгел бу. Күн итек чистартырга кушкан әзмәвердән котылу өчен лаек булмаган чара. Әйе, монда җиңел түгел. Бераз йомшаклык күрсәтсәң, үзеңнекеләр дә муенга менеп атлана. Без, татарлар, бер-беребезне ким-хур итәргә юл куймыйбыз анысы. Сержантлар башкаларның өйдән килгән күчтәнәчләрен үзара бүлешеп ашый. Күзгә карап, мыскыллап ашыйлар. Ә безнекенә тияргә куркалар. Ашханәдә дә, һич оялмыйча, һәр өстәлдән иң тәмле ит кисәкләрен җыеп йөриләр алар. Берәү дә каршы килми, башларын иеп, каш астыннан гына карап утыруларын беләләр. Традиция! Безгә кадәр дә шулай булган, бездән соң да шулай булачак. Сер-*

*жант тамгасын алгач, алар да үзләреннән соң килгән курсантларны имәчәк. Солдатны сержант, сержантны офицер, офицерны генерал, генералны министр имеп ята торган армия бу, Айсылу.*

*Бер офицер армиядәге дедовщинаның ничек килеп чыгуы турында сөйләгән иде. Заманында яшь солдатлар сугышта катнашканнарга шулай дип эндәшкәннәр икән. Элек бу сүз хөрмәтләү, зурлау билгесе булган, ә хәзер чиркану хисе генә уята.*

*Син дөрес әйтәсең, армиядә дә, флотта да тәртип юк. Дезертирлар ишәйгәннән-ишәеп тора. Менә мин инде дүртенче аемны хезмәт итәм, шушы вакыт эчендә полктан егермеләп курсант частьны ташлап китте. Хәзер профессиональ армия булдыру турында сүз болгаталар. Ул тиз генә булмас бездә. Дәүләт профессиональ хәрбиләргә генә түгел, эшләп тамак туйдыра торган кешегә дә юньләп акча түли алмый.*

*Сагынам сине, Айсылу. Санкт-Петербургка кайчан китәсең? Яшәү урының тулай торакта булачакмы? Үзең турында күбрәк яз. Түземсезләнеп көтәм.*

*Сау бул!*

*19 август, 2000, Севастополь*

*Сәлам Казаннан!*

*Мин дә сине сагынам, Рафис. Үзем турында һичбер яңалык сөйли алмам. Өй тавыгы бит мин хәзер. Өй җыештырам, кер юам, телевизор карыйм. Чиккән кулъяулыгым килеп җиткәндер. Ошадымы?.. Чәчәклеләре синең якташларыңа. Аларны Зөлфия чикте. Кызык икән ул чигү дигән нәрсә. Мавыгып китеп, өйдәге мендәрләрне дә чигеп бетердем. Һәркайсында — алма сурәте. Әти белән әни дә гаҗәпләнә. Ике ярты алма кайчан кушылыр инде, дип көлешәләр. Алар кичә Лондонга очтылар. Берәр атна чамасы шунда булырлар, мөгаен. Аулак өйдә калдым мин, бәгырькәчем. Көнләшмисеңме? Борчылма, башка кызлар кебек дискотекаларга да, кафеларга да йөрмим.*

*Очрашу мизгелләребезне күзаллыйм. Ничек булыр икән ул?.. Мин бераз гына юанайган булырмын. Өйдә утырып ябыгып булмый лабаса. Ә син тагын да киңрәк, тазарганрак булырсың, әйеме? Диңгезчеләр шундый була.*

*Их, ярты алманың берсе Казанда, икенчесе — Севастопольдә. Еракларга алып барып ташлады шул минем алмакаемны. Төньяк океан флоты булмагач ярый инде, кызганып үләр идем үзеңне. Кырымда кыш көне дә җылы була, диләр. Син кызганганны яратмыйсың инде, беләм.*

*Әллә яныңа барып кайтыйм микән?.. Кызганыч, вакыт калмады шул. Әти белән әни Лондоннан кайтуга ук, миңа Санкт-Петербургка китәргә туры киләчәк. 1 сентябрьдә укулар башлана. Тору тулай торакта булыр инде. Ыгы-зыгыны яратам мин. Урнашуга ук адресымны җибәрермен. Түзәрсеңме?*

*Уф, туйдырды бу уку. Ә бездә, үзең беләсең, һәркем югары белемле булырга тиеш. Базардагы сатучы да, челнокчы да, дворник та — барысы да. Югары белем дигәннән, безнең сыйныфтагы «өчкә-икелегә» укыган кызлар-малайлар да институтка укырга кергән. Кесәңдә акча булса, бездә укымыйча да диплом алырга була. Шулай ук хәрби билетны да. Бөтен нәрсә дә сатыла бездә. Акчаны кем ничек эшли — бу һәркемнең үз эше. Шуңа күрә дә бездәге дипломнар чит илдә гамәлдән чыга торгандыр инде.*

*Минем классташым Лилия, мәсәлән, проституция белән шөгыльләнә башлаган. Кичә «Эфир» каналында күреп шаккаттым. Ерак юлларда йөрүче шоферларга хезмәт күрсәтә. Белмим, нәрсә мәҗбүр иткән аны бу эшкә? Күзләрен дә йоммыйча, корреспондентка: «Мне нравится такая жизнь», — дип тора. Ә шундый матур, шундый оялчан кыз иде.*

*Кичә көндез шәһәргә чыгып кердем. Кремль янындагы синең белән серләшеп утырган эскәмиядә ял иттем. Күзләремне йомам да хыялга чумам. Имеш, син минем янда. Акрын гына иреннәремә үреләсең. Ә мин карышмыйм. Кешеләр карап торса да оялмыйм, чөнки минем үлеп-үлеп үбешәсем килә. Һәм минем бу иреннәрдән бер генә мизгелгә дә аерыласым килми.*

*Тиле диярсең... Син бит үзең дә мине шулай сагынасың. Әллә ялгышаммы?.. Кайнарлыгыңны хатларыңнан тоям. Алар минем йөрәгемне җылыта.*

*Беркөнне Казанда бик салкын булды. Тәүлек буе бозлы яңгыр коеп торды. Ышанмассың, җылыныр өчен, синең хатларыңны укырга тотындым. Һәм салкын онытылды. Аларны укыган килеш, диванда йокыга киткәнмен.*

*Төнге сәгать унике. Өйдә сөйләшергә кеше дә юк. Бу хатны өч сәгать язам инде. Инша язганда да болай курыкмый идем. Йа Ходай, күпме кәгазь бетергәнмен! Идәндә тау булып өелеп ята. Күрдеңме, ничек җаваплы киләм мин хат язуга!*

*Сиңа хат язарга утырганчы, әтинең картиналарын карап утырдым. Шунда бик сәер фикер килде. Рәссам чып-чын плагиат икән бит ул. Чөнки ул ясаган кояш барыбер җылытмый, ул ясаган җил дә битләрне иркәләми, ул ясаган чәчәкләр дә хуш ис таратмый, ул ясаган диңгез дә чын диңгез кебек шаулый алмас. Никадәр генә даһи булсалар да, алар тере түгел. Табигатьтә чын, тере кояш булганда, аны кабат нигә ясарга? Нигә аның үле вариантын тудырырга?*

*Синең кайчан да булса җил сызгырганын тыңлап торганың бармы? Ул төрле вакытта төрлечә сызгыра. Бер көнне мажор, икенче көнне минор нотада. Әйтерсең көйне синең кәефеңә карап сайлый. Анда вальс белән симфония дә, марш белән фокстрот та, ария белән романс та бар. Аны игътибар белән генә тыңларга кирәк.*

*Әниең сәлам әйтте. Бик аз яза, ди. Без аның белән көн дә*

*телефоннан сөйләшеп торабыз. Иртәгә ул мине варенье кайнатырга чакырды. Син утырткан алмагач быел бик күп алма биргән, шуны җыячакбыз. Менә бит син нинди өлгер, инде тумас борын алмагач та утыртып куйгансың. Миңа да утыртырга кирәк. Бер бөек акыл иясе, бу дөньяны матурлыкка күмәр өчен, җирдәге һәр кеше үз гомерендә бер генә агач булса да утыртырга тиеш, дигән бит.*

*Инде сезгә барырга да оялам. Капка төбендә утырган әбиләр: «Әнә яшь килен килә», — дип пышылдашып калалар. Пышылдашсыннар, әйдә. Килен булгач, чын килен булыйм инде, яраткан каенанама күп итеп варенье кайнатыйм. Ә син минем нинди варенье яратканымны беләсеңме?.. Алма вареньесын яратам мин, алмакаем. Берәр банканы сиңа да җибәрәсе булыр, иптәшләрең белән утырып чәй эчәрсең. Бездә чепок бар, дисең бит.*

*Зөлфия сеңлебезгә төсле җепләр алып барам. Без аның белән ярыша-ярыша чигү чигәбез. Күпме генә тырышсам да, ул барыбер мине уздыра.*

*Төнге сәгать беренче ярты. Сине сагынып, йокларга ятам, матурым.*

*Сау бул!*

*23 август, 2000, Казан*

*Сәлам Севастопольдән!*

*Айсылу, чиккән кульяулыкларыгызны алдым. Гаҗәп матур чыккан. Сеңлем Зөлфиянекен, үзе теләгәнчә, иптәшләремә бирдем. Сөенделәр. Кульяулыкларны иснәп, өй исе килә, диделәр. Синең кульяулыгың белән борын сөртмим. Кесәдә — йөрәк турысында йөртәм. Алай да каралып бетте инде, юасы булыр.*

*Рәсем мәсьәләсендә әйткән фикерең белән бик килешеп бетмим. Табигать адәм баласын ни өчен барлыкка китергән? Мөгаен, үзе тудырган матурлыкка соклансын өчендер. Аннары рәссам шул матурлыкның кабатланмас бер мизгелен, ягъни халәтен эләктереп алып, кешеләргә бүләк итәдер, дип уйлыйм мин. Бер суга ике кереп булмый, дигән борынгылар. Димәк, без кичә күргән диңгез бүген инде бөтенләй башка диңгез, кичә күргән шторм да бөтенләй башка шторм булып чыга.*

*Ә җил сызгырганны мин яратмыйм. Чөнки монда ул бик шомлы яңгырый.*

*Аулак өйдә калдым дигәч, балачак искә төшеп китте. Әти белән әни концертка яисә театрга китсә, без күрше малайлары белән өйнең астын өскә китерә идек.*

*Бервакыт хәтта Толиклар белән телевизорны сүтеп ыргыттык. Андагы кешеләрне тотып карыйсы килгән иде. Ничек телевизорга сыялар икән болар дип, гел баш вата идек. Кешеләрен табып булмады, әлбәттә, ә телевизор күрсәтми башлады. И эләкте инде әтидән. Аннары рәхәтләнеп көлде. Кечкенә вакытта*

*үзе дә шундый наян булган икән, кешеләрен күрергә теләп, стенада эленеп торган радиоалгычны сүткән булган.*

*Балачак шундый беркатлы инде. Йокы туйсын өчен, сәгать телен артка күчереп куйган хәтердә. Әти белән әни эшкә соңга калды. Мин дә мәктәпкә икенче дәрескә генә барып җиттем. Баксаң, сәгать телен күчереп кенә вакытны акрынайтып та, тизләтеп тә булмый икән.*

*Ә качышлы уйнаулар?.. Башкалар йә шифоньерга, йә карават астына кача, ә мин күзләремне йомам. Янәсе, берни дә күрмәгәч, мине дә күрмиләр. Сеңлем Зөлфия дә минем белән шулай качышлы уйный иде.*

*Бу хатым син Петербургка китеп өлгергәнче барып җитәрме, белмим.*

*Сиңа бер сер чишәсем килә, Айсылу. Тиздән безне Чечняга җибәрәчәкләр. Анда хатлар болай тиз йөрмәс дип уйлыйм. Командование аларны энә күзе аша тикшереп җибәрә, дип сөйлиләр. Хатлар сирәгрәк килсә, минем өчен борчылып ятма.*

*Иптәшләрем синнән варенье көтеп кала. Онытмадыммы, диләр.*

*Ярый, хуш иттек!*

*Сәлам белән Рафисың.*

*27 август, 2000, Севастополь*

*Сәлам Санкт-Петербургтан!*

*Син дөрес уйлагансың, Рафис. Хатың мин киткәннең икенче көнендә килеп җиткән. Әни аны үзенең хатына салып җибәргән.*

*Борчуга салдың әле. Чечняда кан коеш бара бит. Телевизордан сөйләгәннәргә ышанмыйм мин. Анда Чечнядагы вакыйгаларны матурлап күрсәтәләр. Информацион сугыш дип атала бу. Хәзер халык аңгыра түгел, кызыксынган кешегә чын мәгълүмат алу өчен интернетка керү дә җитә. Чечен халкына каршы геноцид бара анда. Күпме яшь гомерләр харап булды бу сугышта! Һәм менә сине дә шунда җибәрәчәкләр икән. Уф, йөрәгем кага башлады. Нишләтергә икән ул генералларны? Мине кызганмасаң, әниеңне кызган! Баш тарт! Үзең теләмәсәң, сине анда берәү дә көчләп җибәрә алмый. Тыңла сүземне. Яратуыбыз хакына баш тарт! Минем сине исән килеш күрәсем килә.*

*Инде үземнең хәлләргә күчәм. Петербург матур шәһәр булса да, Казан йөрәккә якынрак. Әлегә тарихи урыннарда, музейларда була алганым юк, чөнки вакыт җитми. Бүген менә, ниһаять, иптәш кызым белән Эрмитажга барырга исәп.*

*Монда һава бик дымлы. Кислород аз булганга, йокы да бик туеп җитми. Күнекмәгән кеше кичкә кадәр дә йоклап ятарга мөмкин. Безне килүгә үк шулай дип кисәтеп куйдылар.*

*Халкы бик әйбәт. Бигрәк тә өлкәннәр тәмле телле. Ә менә тәмәкечеләргә килгәндә, бу шәһәрдә бөтен хатын-кызлар да тар-*

*та кебек. Унөч-ундүрт яшьтәгеләре дә тарта. Белмим, әллә миңа кадәр дә шулай булган, әллә Көнбатыш йогынтысы шундыйнык.*

*Их, метроны күрсәтәсе иде сиңа! Баскычлары текә, беренче тапкыр төшкәндә башлар әйләнеп китә иде. Поездлар биш минут саен килеп-китеп тора. Алла бирсә, бездә дә булачак мондый метро. Тик шуңа гаҗәпләнәм, нигә аны бездә хәзер генә төзи башладылар икән? Метро салыр өчен дә милли мөстәкыйльлек кирәк булды микәнни?*

*Кәефне бетердең әле. Дулкынланудан хәтта яза алмый башладым. Хәзергә үзем турында җитәр. Тагын синең турыда сөйләшеп аласым килә. Чечняны башыңнан алып ыргыт, парень! Юкса миннән тиз генә хат көтмә.*

*Шәп җәза уйлап таптыммы?.. Үзең мәҗбүр итәсең. Шундый усал мин, белдеңме? Күбрәк ачуымны чыгарсаң, командирыгызга да хат язып җибәрәм. Әллә син минем сүзгә колак салмаслар дип уйлыйсыңмы?*

*Тиз арада җавап бир! Көтәм!*

*Сәлам белән Айсылуың.*

*2 сентябрь, 2000, Санкт-Петербург*

*Сәлам Севастопольдән!*

*Исәнме, минем усалым! Вареньегызны алдык. Әнигә дә, Зөлфиягә дә, сиңа да зур рәхмәт. Чия вареньесын яратам мин, иптәшләрем дә бик яратып ашады. Үзебезнең Ерганак урамына кайтып килгәндәй хис иттем үземне. Чит җирдә туган яктан килгән чия төшен дә ыргытырга кызганасың икән.*

*Инде җитди сөйләшеп алыйк. Минем Чечняга китәсемне әнигә әйтмәгәнсеңдер дип ышанам. Бу безнең уртак серебез булып калсын. Шуны аңла, Айсылу, мин бит балалар бакчасында түгел. Монда мин моны телим, моны теләмим дип торып булмый. Безнең прапор әйтмешли, солдат өч кенә сүз белергә тиеш: «есть!», «так точно!», «никак нет!» Чечняга китмәскә теләп гариза язучылар булды инде, көлделәр генә. Кайбер кирерәк курсантларны трибуналга бирү белән дә куркыттылар. Солдат булып язылгансың икән, бөтен приказларга да буйсынырга тиешсең инде.*

*Ә тиз генә хат көтмә диюең белән үтердең дә ташладың. Пычаксыз суйдың, кызый! Ләкин мин моңа ышанмыйм, чөнки син андый үчле түгел. Син матур, син йомшак күңелле, син бик түземсез кыз, бәгърем. Миңа хат язмасаң, синең кәефең кырылачак, каләмең күгәрәчәк. Дөрес әйттемме?*

*Кичә безнең полкка поп чакырттылар. Хәерле юл теләп, барыбызны да чукындырды, өстебезгә изге су сипте. Менә бусы инде бернинди дә кысага сыймый, Айсылу. Безне, татар егетләрен, поп бәхилли. Димәк, кешегә санамыйлар. Димәк, Россиядә*

*империячел сәясәт һаман дәвам итә. Ә бит патша вакытында да мондый хәл булмаган. Хәрби крейсерларны диңгезгә озатканда, анда мөселман ахунын да чакырганнар. Гәзиттән укыганым бар.*

*Бервакыт Николай патша шундый крейсерларның берсенә нииндидер тантанага килә. Ул иң беренче булып попка түгел, мөселман ахунына кул бирә. Сез нишлисез, галиҗәнап, ди крейсер капитаны гаҗәпләнеп. Мөселманнар монда азчылык, ә азчылыкны хөрмәт итәргә кирәк, дип җавап бирә патша. Менә нинди культуралы булган монарх. Ә безнең илбашына, генералларга, күрәсең, мондый югары культурага кадәр әле ераграк. Патша Россиясендә бәйрәм вакытларында мөселман матросларына чәй, урысларга аракы биргәннәр. Аш-су да аерым пешерелгән. Беренчеләренә — сыер, икенчеләренә — дуңгыз ите булган.*

*Булды, ашыгам, безне инде вагоннарга төйиләр. Хатымны җавапсыз калдырмассың дип уйлыйм. Яңа урынга килеп җиткәнче мине югалтма.*

*Сине үбеп, диңгез пехотасы сержанты Рафис Гайсин.*

*8 сентябрь, 2000, Севастополь*

## Чокыр да такыр

Быел кыш бик җылы килде. Инде декабрьнең икенче яртысы булуга карамастан, җирдә бер генә бөртек тә кар юк иде. Дөрес, кар яуды явуын, ләкин ул бик тиз эреп бетте. Иртәнге якта шәһәрне соры томан каплап ала. Биек агач өсләрендә бөтерелеп туктаусыз каркылдаган каргалар да, парклардагы дымлы яфрак һәм җир исе дә көзнең әле дә булса тантана итүен күрсәтә иде. Авыл халкы кар юк дип борчылса, шәһәр халкының исе дә китми. Нәрсә ул кар? Аңа йөрергә асфальт булсын! Кар булмаса, транспортка да рәхәт. Юллар бозланып, тараеп калмый.

Ә бүген табигать иртәдән бирле җиргә кар яудырды. Күп кенә юлларда пробкалар хасил булды, һәр тарафта троллейбуслар, җиңел машиналар батып ятты. Бульдозерлар бөтен карны да эттереп өлгерә алмый. Беренчедән, шундый зур шәһәр өчен алар бик аз, икенчедән, булган кадәресенә дә ничек ягулык җиткерергә?

Ерганак урамының бер очын нык чистартсалар да, икенче очына бульдозер кермәде. Аның онытылган өлешендә машинага гына түгел, ашарга да акчасы булмаган пролетариат яши.

Акрынлап урамга төн пәрдәсе төште. Бетон баганаларга эленгән люминесцент лампалар тирәсендә бөтерелеп карлар оча, тимерчыбыклар гүелди. Салкынайтып җибәргәнгә шулай итә. Кайбер йортларда ут юк, Айвазовский урамында автокран баганадагы чыбыкны өздергән. Бер урам булса да, монда электр уты ике якка ике җирдән килә.

Шәм яктысында утырган Сәкинә, гәзит укып та оныта алмагач, өстәлдә калган торт белән чәй эчте. Бүген кышкы каникулга кайткан Айсылу булып китте аларда. Хәрби комиссариаттан Рафис турында бер-бер яңа хәбәр юк микән дип борчылып килгән. Утызынчы сентябрьдә Ханкала янында улыгыз хәбәрсез югалды, дигән хатны алгач, Сәкинә бер атна урын өстендә ятты. Шуннан бирле һич савыга алмый. Башына чак кына уй керде исә шундук чигәләре кыса, тыны бетә башлый. Бер түгел, йөз барды инде хәрби комиссариатка. Һаман бер сүз: «Улыгыздан хәбәр юк. Эзлибез». Эзләгәннәре бер дә сизелми. Хет кайгысын уртаклашсыннар иде, акча сорап килгән кеше кебек, чырайларын сытып каршы алалар. Ә малай кирәк булгач, төнлә алып киттеләр. План тутырдылар, кабихләр.

Рафисның соңгы хаты сигезенче сентябрьдә килде. Айсылу да соңгы хатны сигезенче сентябрьдә алган. Үтергән булсалар, үле гәүдәсе табылыр иде. Әсиргә алганнардыр балакайны. БТРда барганда шартлаганнар бит. Җидәү булганнар. Берсе, Искәндәр исемлесе, исән калган калуын. Аны юл читендәрәк табып алганнар. Ә калган алтысы юк, әйтерсең су кебек җиргә сеңгәннәр!

Ноябрь ахырындарак бер кулын югалткан Искәндәрне комиссовать иттеләр. Казанга кайтып җитүгә, ул Сәкинәләргә дә кереп чыкты. Чырае ап-ак, кулының киселгән җире әле һаман сызлап-үлекләп тора. Бик аз сүзле булды, балакай. Башкалар белән ни булганны хәтерләми. Чыгып киткәндә, елап арган Сәкинәне кочаклап алды да: «Ул сугышны күрергә язмасын, апа!» — дип, аркасыннан сөеп, саубуллашып чыгып китте.

Чәйне эчеп бетерә алмады Сәкинә. Тиле кеше кебек кинәттән генә тәрәзәдән тәрәзәгә йөри башлады. Әйтерсең менә-менә аның Рафисы күренер төсле. Әмма анда буран котыра да ара-тирә Әнгәнең сузып-сузып улаганы гына ишетелә.

Шулай йорт буенча бәргәләнеп йөри торгач, ул диванда йоклап яткан Зөлфия янына килеп утырды.

Кыз ара-тирә йөткергәли. Мәктәпкә куртка белән генә барган иде шул. Туңып кайтты. Сәкинәнең Мамадыштагы абыйсы кызыннан калган тунны вәгъдә иткән иде, һаман күренми. Мөгаен, шушы якшәмбедә килеп җитәр. Ә аңа кадәр әле нәкъ алты көн бар. Ярый, эчтән җылырак кофта кияр. Ара ерак түгел, 4 нче мәктәп Ульянов урамында гына урнашкан. Алай дисәң, бала-чага шул араны да ике-өч сәгать кайта бит. Юл уңаенда иптәшләре белән кар атышалар, шугалакта шуалар. Аларга бөтен нәрсә кызык. Туңганнарын өйгә кайтып кергәч кенә аңлыйлар.

Сәкинә шәмне сүндереп йокларга ятты. Сукыр кычыткан төнәтмәсе эчүгә карамастан, йөрәге дөп-дөп итеп тибә, колагы шаулый иде аның. Боргаланып ята торгач, ул бер генә мизгелгә онытылып китте. Әллә төш булды, әллә арган акыл белән болай гына күз алдына китерде, аяк-куллары богауланган Рафисның тирән

бер чокырда утырганын күрде ул. Гимнастеркасы ертык, йөзен сакал-мыек баскан. Өстән сакчы кычкыра:

— Эй ты, русский свинья, будишь гаварить?.. Сматри, если кантрактник, наш камандир тибе голову атрежет. Развелось тут вас, наркоманов. Дитей, стариков ни җалеете. Мы вас тоже җалеть не будим. Вайна есть вайна. Пусть перед вашими матирями ваши гиниралы атветят.

Рафис битараф тавыш белән җавап бирә:

— Я не русский, из Казани я.

Сакчы тагын да зәһәрләнә:

— Какая разница? Все равно кантрактник. На наших душах деньги хател заработать, да?

Сәкинә шушы урында куркып сикереп торды. «Үтерәләр балакаемны, үтерәләр! — дип уйлады ул өзгәләнеп. — Исән бит әле ул, нигә коткармыйлар?!»

Кинәт урамда сөйләшкән тавышлар ишетелде.

— Задняя колонна, подтянись! — Кемдер команда бирә.

Әллә Рафис кайттымы? Алайса, нигә алар шулай бик күп?

Сәкинә тәрәзәгә ташланды. Буран, берни дә күренми. Ул, өстенә дә кимичә, эчке күлмәктән генә урамга йөгереп чыкты.

Йа Аллам! Аның яныннан арган, талчыккан солдатлар колоннасы узып бара! Беркем берни сөйләшми. Алгы яктарак тагын команда яңгырый:

— Передняя колонна, шире шаг!

— Сәкинә, кызы-ым! — Тавыш колонна эченнән ишетелә. Кем бу?

Аһ! Әтисе ләбаса. Ул бит… сугышта һәлак булды. Ничек, кайдан?

— Әти-и! — Сәкинә, шашып, әле бер, әле икенче якка ташланды. — Әти-и, син кайда-а?!

Колонна эченнән яшь-яшь кенә бер ир-ат йөгереп чыкты.

— Монда мин, кызым!

Йөз чалымнары һаман шул ук, ябыккан, тартылган. Шундый инде юл газабы.

— Әти, әтием!

Кочаклаштылар. Әтисеннән әллә дары, әллә тәмәке исе килә.

— Әйдә, өйгә керик, әтием!

— Ярамый, кызым. Дошман Мәскәүгә килә, сугышка керәбез бүген.

— Нинди сугыш?.. Сугыш бетте бит инде, әти!

— Бетмәде шул әле, кызым, ул әле башлана гына.

Шушы бәхетле мизгелне тетрәндереп тагын команда яңгырый:

— Рядовой Гайсин, быстро в строй!

— Бәхил бул, балакаем! — Әтисе Сәкинәне шашып-шашып

битләреннән, маңгайларыннан үпте. — Мин кайтырмын, һичшиксез, кайтырмын!

— Әти-и! — Тездән карга баткан хатын сабый баладай үкереп елап җибәрде. — Әти-и, кайт инде-е!

Колонна ахырында атлаучылар арасында тагын бер таныш йөз күренә. Улы ич! Ул да сугышка кереп бара микәнни?.. Нигә эндәшми?..

Болайга таба борылды.

— Улы-ым!

— …

— Нигә бер сүз дә дәшмисең?! — Сәкинә, йөгереп килеп, улын кочакламакчы булды, ләкин, үз аягына үзе сөртенеп, йөзе белән карга егылды.

— Әни-и! — Улы аны шундук күтәреп алды, күкрәгенә кысты. — Әни, туңасың бит, өйгә кер!

— Улы-ым!

— Әни-и, әние-м! — Улыннан да әллә дары, әллә тәмәке исе килә. Олыгайган.

— Нигә өйне узып китәсең? Ничә айлар тәрәзәдән күзем алмыйм!

— Сугышка керәбез, әни. Миңа китәргә кирәк.

— Юк, китмисең! — дип үкерде Сәкинә. — Беркая да китмисең! Җибәрмим!

Алар икесе дә карга егылдылар.

— Әни-и! — Рафис түгел бу, Зөлфия тавышы.

Карга чумган Сәкинә аңына килгәндәй булды. Әччәч! Улы түгел бу, Әнгәне кочаклап утыра лабаса. Эт, үрсәләнә-үрсәләнә, аның битләрен ялый. Яннарында аркасына иске кызыл куртка салган, аягына зур итек кигән кызы йөткерә-йөткерә, елап басып тора:

— Әни, өйгә керик. Суык бит.

Буран Сәкинәнең таралган ап-ак чәчләреннән җан өшеткеч чынбарлык төсле салкын кар бөртекләрен тарата. Әллә аның белән бергә елый, әллә иркәли — белмәссең.

…Ул төнне Сәкинә акылдан язды. Хәзер ул Волков урамындагы психо-неврологик хастаханәдә, икенче катта, дүртенче палатада ята. Янына кем генә керсә дә: «Баламны сукбайлар ашады-ы!» — дип, илереп еларга, үкерергә тотына.

Кечкенә Зөлфияне Мамадыштагы абыйсы алып китте.

Рафистан шул рәвешле бернинди дә хәбәр килмәде. Берәүләр аны чеченнар ягына чыккан, икенчеләре иптәшләре белән кайдадыр тауларда атып үтерелгән дип сөйләде. Әмма Айсылу аның һәлак булуына шикләнми. Исән булса, барыбер бер-бер хәбәр салыр иде. Хәзер ул кияүдә, ике бала үстерә. Әмма Рафисның хатларын әле дә кадерләп саклый. Җанга бик моңсу булган минутларда, ул аларны кабат кулына ала, нәкъ беренче вакытта-

гы кебек, йотылып-йотылып, андагы якты, хисле, сагышулы сүзләрне күңеленнән кабатлый: «Сәлам Севастопольдән!»

Шушы вакыйгалардан соң, Ерганак урамына дүртенче яз килде. Анда төнлә тагын капка кагып йөри башладылар.

— Салихов Марат монда яшиме?

— Ие, балакаем.

— Ачыгыз капканы! Малаегыз армиядән качып йөри.

— Ачмыйм. Үтерсәгез дә ачмыйм!

— Оялыгыз, апа. Малаегыз Ватан алдында изге бурычын үтәргә тиеш!

Ерганак урамында әлегә исән-сау калган бердәнбер агач йорт бу. Чокыр такырланды. Андагы агачларны инде күптән кисеп бетерделәр. Монда хикмәтле кошлар сайраганы да ишетелми. Кошлар гына түгел, этләр дә качып бетте аннан. Бу урамда көн дә даң-доң килеп бетон свайлар кагалар, әле монда, әле тегендә башлары күккә тигән затлы таш сарайлар калкып чыга. Аларның һәркайсы биек таш койма белән әйләндереп алынган. Анда тере кеше барлыгын фәкать вертолеттан гына күреп була. Кеше кешедән кача торган менә шундый ахырзаман килде илгә.



# ХЫЯЛЫЙ ХИКӘЯЛӘР

## ЙОЛДЫЗЛАРГА — ЙОДРЫК

Хатынны әнисе янына кунакка — Тимер Йодрык галактикасына озатып җибәргәч, эчем поша башлады. Ары сугылдым, бире сугылдым, уемда гел ул. Нинди генә чибәр егетләр очрамас иксез-чиксез җиһан киңлегендә. Беркем белми, беркем күрми — теләсәң нәрсә эшлә.

Саклангэнны Ходай саклар дип, мин дә юлга чыгарга иттем. Себеркегә атланып очып булмый бит инде, кораб эзләп «Космопрокат»ка чаптым. Сайлый-сайлый, мием череп бетте: берсенең элемтә блогы бозылган, икенчесенең двигателе эшләми, өченчесенең... Кыскасы, бер генә төзек очкыч та калмаган.

Киттем Хәбир янына. Кайчандыр бик якын дуслар идек, корабын бирмичә калмас, янәсе.

Мин кергәндә, ул шифоньерда актарына иде.

— Нәрсә эзлисең? — дим.

— Нәрсә булсын, — ди теге көрсенеп, — башның сызымын инде. Әллә кая куйдым, тәрене. ТОСИ*дан алып кайткан кебек идем үзен.

Дустымның крокодил кабырчыгыдай кытыршы баш капкачын, иләмсез озын колакларын күргәч, ирексездән елмаеп куйдым.

— Елмай, елмай, — дип мыгырданды Хәбир, авызын турсайтып. — Үзең шундый хәлгә кала күрмә. Берәр маймун башы ясап бирсәләр... — Аннары ул дустанә рәвештә аркамнан сөеп алды. — Йә, ярый, кофе эчәсеңме? Атнакич өлкән кызым Венера планетасыннан җибәргән иде. Ул анда хәзер балаларга татар теле һәм әдәбияты укыта.

---

* Т О С И — терек организмнарны сипләү институты.

Шундый эссе көнне кем баш тартсын инде тәмле эчемлектән.

— Бик һәйбәт булыр, тик каты итеп ясама. Беләсең бит, кан басымым югары.

Хәбир, гәүдәм тирәли кулын йөртеп, сәламәтлегемне тикшерә башлады.

— У-у, беткәнсең син, ахири. Башыңны яңасына алыштырырга кирәк. Йөрәгең дә дан түгел.

— Синекен алыштырганнары да бик җиткән, — мәйтәм, кул селтәп. — ТОСИда крокодил башы ясатканчы, башсыз йөрүең яхшырак.

— Бик дөрес. Башка Ходай ташы төшмәгән булса, ТОСИга якын да киләсе кеше түгел идем мин. Нинди матур башны харап иттеләр. Син дә шулар аркасында борынсыз йөрисең бит.

Мин кайчандыр борын булган җиремне күлмәк җиңе белән сыпырып куйдым.

— Йөрисең инде, башыңа төшкәч.

— Кем тешләп өзде дисең әле?

— Солярия планетасында су коенганда инде, ерткыч балык тешләде. Әллә кайко, әллә…

— Син, ахири, яңа борыннан баш тартма. Әрмән борыны булса да, чүтеки борынсыз йөрү түгел бит.

— Үзләренә булсын.

— Мин Тимер Йодрык галактикасына очарга дип торам әле, — диде Хәбир, кайнап чыккан кофены кечкенә касәләргә агызып. — Дөрес булса, андагы белгечләр кеше әгъзаларын бик оста ясыйлар икән.

Шатлыгымнан чак кына кычкырып җибәрмәдем. Димәк, безгә бергә очарга да була!

…Өч-дүрт көннән Хәбирнең ике урынлы корабы белән антидөньяга юл тоттык. Аның нәрсә икәнен беләсегез килсә, бер башы ватылган тавык йомыркасын күз алдына китерегез. Йомырка кабыгы — һичбер кораб үтеп керә һәм чыга алмаслык гравитация дивары, йомырка сарысы — Тимер Йодрык галактикасы. Антидөньяга дивар йомылып бетмәгән урыннан гына керү мөмкин.

…Җиде ел җиде көн кебек үтте дә китте. Бер парсеклык юл калгач, Аждаһа планетасының иң затлы рестораннарында атна буе үрмәкүчкә охшаган ун аяклы, ун куллы чәчбиләр белән типтердек. Дөрес, айныгач бик уңайсыз булды. Исерек чакта уйламыйсың бит ул, кеше булды ни, аеры койрык ни…

Без тагын юлда. Тирә-юньдә йолдызлар, ара-тирә Җиргә су алып кайтучы кораблар, җиһан буйлап бер баштан бер башка сәфәр кылган дәрвиш астероидлар һәм метеоритлар очрый.

Берничә көннән Тимер Йодрык галактикасына якынлаштык. Ләкин йомылып-тоташып бетмәгән ике гравитация кыры арасына килеп кердек кенә дигәндә, корабта сәер күренеш барлыкка килде: приборларның теле нульдә, баш очында сәер утлы шарлар

очып йөри. Нидер үтереп-үтереп чигәләрне кыса. Һәм очкыч та туктап калды.

Шулай аптырап утырганда, Хәбир йодрыгы белән идарә пультына китереп сукты.

— Каһәр, гравитация кыры йомылган! — дип мыгырдады ул.

Бу сүзләрдән эчем суынып китте.

— Бөтенләй үк йомылып беткән микәнни?

— Мең елдан соң гына ачылачак. — Хәбир, башын диварга төя-төя, елап җибәрде. — Миңа яңа баш кирәк, баш! Мин крокодил башлы булып калырга теләмим!

— Тынычлан, — дим тегеңә, — мин менә хатынсыз да калдым әле.

— Хатынны алыштырып була, ә башны…

— Алыштырып була, имеш. Бик беләсең килсә, бу хатынны ун башка да алыштырмас идем мин. Ул янымда булса, аның гарешкә ашкан сеңлесенең оча торган җиңел машиналар эшләп чыгаручы корпорациясе президенты булачак идем, каһәр. Хәзер барысына да туганнан туган апасы хуҗа булачак инде.

— Сызымын тап та яңаны ясат.

— Барыбер файдасы юк, бездә хатынның төп нөсхәсе генә гамәлдә санала. Бюрократлар! Аннары аның сызымын төшертергә дә онытканмын әле мин.

— Бусы начар, — диде Хәбир, мине чын күңелдән кызганып.

Җиргә кайткач, чормадан хатынның унсигез яшьлек чагындагы сызымын эзләп таптым да ТОСИга заказ бирдем. Гаҗәп бит, бу юлы аны элеккесенә караганда да матуррак итеп ясаганнар иде. Тик иртәрәк сөенгәнмен икән. Үзгәртеп күрсәткәннәр дә соң сызымын! Бер көн маташтым, ике көн, һич кенә дә сызымнар туры килми. Озак яши алмадык, аерылыштык.

Хәзер мин аяз төннәрдә тормышымны бозган йолдызларга карап йодрык күрсәтәм.

## ҖИҢЕЛҮ

Дүрт иярченле кечкенә яшел кояш шәмәхә болытлар артына кереп югалгач, инде болай да бихисап күлләвекләр белән чуарланган шәһәр урамнарында яңгыр коя башлады. Шундук мәрмәр тротуарларда, магнитоплан тукталышында гаҗәеп чуар һәм матур зонтиклар мозаикасы барлыкка килде. Ә шаян гөрләвекләр, бездән алай гына котыла алмассыз дигәндәй, яңгырдан качып берберсенә сыенган шәһәрлеләрнең аяк араларыннан юл салып, аларны бертуктаусыз әле монда, әле тегендә сикергәләргә мәҗбүр иттеләр.

Тәрәзәдән урамга карап торган Аккүз планетасы башлыгы Орг Ман, һава торышы үзгәрүдән сызлый башлаган сул иңен уауа, яңадан өстәл артына утырды. Алтмыш яшьлек бу картның

тирән җыерчыклар белән сырланган киң маңгаендагы зур кызыл күзендә канәгатьсезлек сизелә иде.

— Димәк, СПИД вирусы үзен акламады? — дип сорады ул кабат, караңгы чырай белән.

— Әйе, акламады, — диде, каршыдагы сары кәнәфидә утырган Эмилия. Утыз яшьтә генә булуына карамастан, ул планетаның иң абруйлы генетикларыннан санала иде. — Җирлеләр без уйлаганча ук ахмак булып чыкмадылар. Эпидемия тулысынча туктатылды.

— Кызганыч, бик кызганыч. — Орг Ман уйчан кыяфәттә өстәлдә бармакларын биетеп алды. — Ә мин сиңа ышанган идем, Эмилия. Кояш системасындагы фикер һәм хис тушланмасы үзенең иң биек ноктасына җитте. Җирлеләрне тиз арада юк итә алмасак, безне фикер үтерү җайланмасы гына коткармас: барыбыз да бозылып бетәчәкбез. Син мине аңладыңмы?

— Аңладым, бик аңладым, Ман әфәнде. Ләкин…

— Бер генә минут, — диде планета башлыгы, аны бүлдереп. Һәм өстәлдә яткан фонарь сыман озынча түгәрәк җайланманы алып, Эмилиянең баш очына кызгылт нур юнәлтте. Черт иткән тавыш ишетелүгә үк, ул, тирән көрсенеп:

— Менә күрдеңме, болай яшәп булмый, Эмилия. Бу бүлмәдә мин көн саен диярлек йөзгә якын җирлеләр фикерен үтерәм, — диде.

— Ә минем баш очымда очып йөргәне нинди фикер иде? — диде Эмилия, чәчләрен сыпырып.

— А, бик кабих фикер, җанкисәгем. — Орг Ман, әллә күңеле болганудан, әллә болай гына, тач-точ итеп әфлисун таблеткасын суыра башлады. — Теге ни, мәхәббәт турындагысы. Бигрәк җирәнгеч бу кешеләр. Ике биологик затның бер-берсенең селәгәен ялаудан да ямьсезрәк нәрсә бар микән дөньяда? Әле ярый, бездә хатын-кызлар җил белән аталаналар, юкса…

— Эшләр болайрак барса, безгә дә үбешә башларга туры килмәгәе, — диде Эмилия, аның сүзләрен җөпләп.

Бу вакытта инде Орг Ман стереовидеотелефон янында очып йөргән фикерләрне үтерү белән мәшгуль иде.

— Үбешергә генә микән? — дип мыгырдады ул, тешләрен кысып. — Күр, күпме фикер очып йөри минем бүлмәдә. Революция, коммунизм, фашизм, гомосексуализм… А, бик авырга туры килер, ахры, безнең оныкларга. Дәвалауга бирелми торган күпме чир көтә бит үзләрен.

Бүлмәдәге фикерләрне үтереп бетергәч, планета башлыгы, Фуҗне* өстәлгә томырып, чәчәкле кульяулыгын тирләп чыккан такыр башына куйды.

— Кичә безнең планетада үбешкән өчен егерме дүрт ир-ат

* Фуҗ — фикер үтерү җайланмасы.

һәм хатын-кыз кулга алынды. Тиздән мәхәббәт эпидемиясе башланачак.

— Мәхәббәт авыруына каршы без нәфрәт вирусы уйлап таптык, — диде Эмилия. — Хәзер аны күпләп чыгаруны гына җайга салырга кирәк.

— Нәфрәт? Нинди нәфрәт?

— Бу вирус җенси тормышка нәфрәт уята.

— Бик шәп, ә ул җилгә дә нәфрәт уятмасмы соң?

— Юк, әлбәттә. Тәҗрибәләр уңышлы узды.

— Афәрин. Тик менә революция, коммунизм, путч кебек авыруларга каршы да иммунитет булдырырга кирәк. Тырыша күр инде, Эмилия. Сиңа һәм син җитәкләгән фәнни-тикшеренү институтына зур өметләр баглап торабыз.

— Тырышырбыз, һичшиксез, тырышырбыз, Ман әфәнде. Әгәр зур җыелыш җирлеләрне юк итү фондына яңадан дүрт йөз мең тикара* күчерсә, безнең эшләр бик тиз алга китәчәк.

— Ярый, бу мәсьәләне без шушы атнада ук хәл итәрбез. Хәзерге вакытта галәмдәге фикер экологиясен саклап калудан да мөһимрәк нәрсә юк.

Алар кул кысыштылар. Нәкъ шул мизгелдә Эмилиянең чак кына киселгән баш бармагына мәхәббәт турындагы фикер килеп кунды. Канга эләккән очракта, аннан котылу мөмкин түгел. Ул мәңгегә лептондулкын кырына — җанга кереп утыра.

— Уңышлар телим сиңа, Эмилия! — диде планета башлыгы, аны аркасыннан сөеп.

Галимә хатынның күңелендә сәер бер үзгәреш барлыкка килде. Ул комач кебек кызарды һәм, үзе дә сизмәстән, Орг Манның иреннәрен үпте.

— Мин сине яратам, Орг, — диде ул. Аның тавышы искиткеч йомшак һәм назлы иде. Ә маңгаендагы асман кебек зәп-зәңгәр күзе исә оялып кына читкә карады.

— Мин дә, — дип пышылдады планета башлыгы, рәхәт калтырый башлаган кулы белән аның сары чәчен сыйпап. — Беләсеңме, кичә мин авырый башладым бугай. Тик бу турыда әйтергә генә кыенсынган идем.

— Алайса, мине үзеңнеке ит, хәзер үк, ишетәсеңме?! — Эмилия үзенең күлмәк сәдәпләрен чишә башлады.

— Әйе, — диде Орг, галимәнең ярым шәрә күкрәгенә иренен тидереп. — Син — минеке. Мин сине яратам!

— Миңа уңайсыз, Ман.

— Төкер барысына да. Иң мөһиме — без бергә.

— Ә җирлеләрне юк итү? Галәмдәге фикер экологиясен саклау? Нәфрәт вирусы?

— Төкер, дидем бит инде.

* Т и к а р а — Аккүз планетасындагы акча берәмлеге.

— Без бозылдык. Безгә кичекмәстән нәфрәт таблеткасы эчәргә кирәк.

— Маташмыйк. Миңа рәхәт. Нинди татлы бит бу бозыклык!

Кинәт тәрәзә ачылып китте дә бүлмәгә, нечкә алтын җептән тукылган озын өрфия штораларны кабартып-җилфердәтеп, дымлы җил бәреп керде.

— Көнләшә, — диде бәхетле Орг елмаеп.

— Кем көнләшә бездән, сөеклем?

— Кем булсын инде, җил, әлбәттә.

Бераздан Адәм һәм Һава киемендә генә калган Орг белән Эмилия бер-берсенә кайнар мәхәббәт сүзләре пышылдый иде…

## СОҢГЫ РОМАН

Ишектә кулына киң портфель тоткан Оризон күренгәч, видеостереотелефоннан сөйләшеп утырган Гортек, күзләрен экраннан алмыйча гына, каршыдагы магнит кәнәфигә ымлады.

— Әйе, ул риза, Ливон әфәнде, — диде Гортек трубкага.

— Алайса, әсәр тиз арада басылырга тиеш.

— Тырышырбыз.

Экрандагы сурәт юкка чыкты. Гортек, тәрәзәдән төшкән кызыл кояш нурларыннан күзләрен чекерәйтеп, йомшак кәнәфигә чумган Оризонга мөрәҗәгать итте:

— Синең турыда сөйләштек. Мин сине риза, дидем.

Тегенең йөзе кара янды.

— Ә мин риза түгел, — диде ул һәм портфеленнән калын папка чыгарып өстәлгә ыргытты. — Бассагыз басасыз, басмасагыз… Мин романның бер генә юлын да үзгәртмәячәкмен!

Гортек, папканы читкә этеп, тәмәке кабызды, авызыннан берничә төтен боҗрасы чыгаргач, тагын тыныч кына сүз башлады:

— Миннән генә торса иде бу дөнья. Ливон әфәнде үз сүзеннән кире кайтмаячак. Син аның кем икәнен яхшы беләсең. Әсәреңнең чишелешен үзгәртүгә генә карап, синең иҗатыңа һичниндиди зыян килмәячәк. Әллә ни үзгәртәсе юк бит. Калифорниядә җир тетри. Даниэл белән Нелли һәлак булалар да — вәссәлам. Үзең турында уйламасаң, хатының белән кызың турында уйла. Аларның инде бер ай кислород сулаганнары юк. Үзең дә көннәнкөн саргаеп, кибеп барасың. Әсәрең басылып чыкса, син гаиләңне җиде-сигез елга кислород баллоннары белән тәэмин итәчәксең. Уйла, яхшылап уйла!

— Уйлыйсы уйланган инде. — Язучы дерелдек тоткан куллары белән өстәлдә яткан сигараны алып, авызына капты. — Кабызыйк әле.

Гортек, бармакларын шартлатып, утчагарын кабызды да күрсәтеп куйды:

— Син минем иң яхшы дустым. Болай киреләнүең миңа һич тә ошамый. Әйт, нәрсә булды сиңа?

— Беләсеңме, — диде Оризон, моңсу тавыш белән. — Бүген мин төне буе еладым.

— Еладың? Нигә?

— Кичә мин телеграмма алдым. Оризон куен кесәсеннән зәңгәрсу бланк чыгарып Гортекка сузды. — Укы, бәлки, нәрсә дә булса аңларсың.

Бүлмә хуҗасы күзлеген киде дә телеграмманы кычкырып укырга кереште:

*«Ашыгыч телеграмма.*

*Г-12 галактикасы, Цефей йолдызлыгы. Кызыл Йолдыз системасы, Тәхет планетасы. Канат шәһәренең 12 нче каты, язучы Оризон Вегога.*

*Мөхтәрәм Оризон әфәнде!*

*Җирдә тикшеренү эшләре алып барганда, мин очраклы рәвештә «Нью-Йорк Таймс» газетасында басылган бер мәкаләгә игътибар иттем. Анда Чернобыль электр станциясендә булган шартлау турында сүз бара. Мәкаләдә сурәтләнгән фаҗигале вакыйгалар сезнең «Җансыз дөнья» дигән фантастик әсәрегез белән аваздаш. Икенче төрле әйткәндә, сез уйлап чыгарган Чернобыль электр станциясе, аның директоры Сергей Климов һәм башка бик күп персонажлар тормышта да бар. Сез җирлеләр язмышын язасыз дип уйлыйм мин. Бәлки, мин ялгышамдыр, барысы да ныклап ачыкланганчы яңа әсәр язмыйча торсагыз, мин бик шат булыр идем. Язуыгызны дәвам иткән очракта, ул сезнең кешелек дөньясына каршы эшләнгән чираттагы җинаятегезгә әверелергә мөмкин. Тагын бер гозерем бар: берәр яңа әсәрегез булса, аның бер нөсхәсен миңа җибәрегез әле. Аның ярдәмендә сезгә бәян иткән гөманымның дөреслеген раслый алырмын дип ышанам.*

*Ихтирам белән экспедиция начальнигы Вукало Вуто.*

*Җирдәге ел исәбе буенча 2050 ел, 11 май.*

*Адресым: Киек Каз Юлы йолдызлыгы, Кояш системасы, Җир, Минск шәһәре, ундүртенче өчпочмак».*

Телеграмманы укып чыккач, Гортек тирләп чыккан озын борынын кулъяулыгы белән сөртеп куйды.

— Әкият! Син шуңа ышанасыңмы?

— Ышанам.

— Кызганыч. Мин сине мондый ук беркатлы дип уйламаган идем. Ә син җирлеләрнең безнең галактиканы яулап алырга җыенганнарын беләсеңме соң?

— Белмим.

— Аларга үз галактикалары гына аз, — дип сөйләнде Гортек, төкерекләрен чәчә-чәчә. — Бу җирлеләр безгә каршы хәтта мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә дә провокацияләр ясаудан баш

тартмыйлар! Фикер матди була алмый, Оризон. Моны безнең галимнәр инде күптән исбатладылар. Матдиләшкән суреттә дә без моны аларга каршы кулланырга тиеш.

— Ә гуманизм?

— Бала-чага булма, Оризон. Монда икенең берсе генә: йә алар безне, йә без аларны! Безгә, иң беренче нәүбәттә, үзебез турында уйларга кирәк. Озын сүзнең кыскасы, әсәреңне бүген үк Ливон әфәнде әйткәнчә үзгәрт.

— Үгетләмә мине, Гортек. Алар да бит безнең кебек үк Солярисус планетасыннан чыккан һомо сапиенслар. Аннары безгә дигән кислородны Җирдән ташуларын онытма.

— Алайса, Калифорнияне Югославия яисә… теге ни… Мексика дип үзгәрт. Бу илләрнең атамаларын мин уйлап чыгардым, син түгел. Шулай булгач, Җирдә андый мәмләкәтләр була алмый. Мин бит синең кебек җирлеләр язмышын яза торган илаһи зат түгел. — Гортек соңгы сүзләргә каһкаһәле басым ясады.

— Кем белгән, — диде Оризон, аның кыланышына һич тә үпкәләмичә.

— Йә, килештекме?

Оризон кашын җимерде.

— Миңа акча кирәк, Гортек, ишетәсеңме, акча!

— Димәк, син риза?

— …

— Әсәреңне иртәгәдән дә артык тоткарлама. Юкса соңга калабыз. Мин инде болай да булдыра алган кадәрен эшләдем.

— Кульязманы синдә калдырам. Мин аның өтерен дә үзгәртмәячәкмен. Үзләре карасыннар.

Оризон, тәвәккәл рәвештә, ишеккә атлады.

— Китәсең?

— Кызым янына — хастаханәгә барып кайтасы бар.

— Ул авырыймыни?

— Әйе. Кислород җитмәү аркасында.

Оризон чыгып китте.

«Менә бит принциплар ни эшләтә, — дип уйлады Гортек, видеоселекторга иелеп. — Җәһәннәмдәге җирлеләр өчен хәсрәтләнә бит, тиле».

— Эмма!

Экранда яшел чәчле, сары күзле сәркатип хатын сурәте күренде.

— Тыңлыйм сезне.

— Керең чык әле минем яныма.

Эмма озак көттермәде. Күбәләк кебек очып килеп керде дә, матур аякларын чалыштырып, әле яңа гына Оризон утырган кәнәфигә килеп кунаклады. Гортек аңа инде күптән битараф түгел. Әмма аңа, өйләнгән кеше буларак, бу матурлыкка читтән торып кына сокланырга кала. Чөнки бу планета законнары буенча, хатынга хыянәт кылган өчен үлем җәзасы бирелә.

— Менә нәрсә, матурым. Бер әсәргә чак кына үзгәреш кертергә кирәк иде, — диде Гортек, аның дилбәр сынына сокланып.

— Автор үзе булдыра алмыймыни?

— Ул авырый, ә китапны инде баса башларга кирәк. Әсәрнең ахыры мондый булырга тиеш: Калифорниядә җир тетри һәм Даниэл белән Нелли һәлак булалар. Булдыра алырсыңмы?

— Әлбәттә, беренче тапкыр гына түгел бит инде, — диде Эмма елмаеп. — Ә гонорары күпме булыр?

— Син дигәндә, аяк идәндә инде, матурым, ким-хур булмассың.

...Бер атнадан «Мәхәббәт һәм нәфрәт» романы китап булып басылып чыкты. Гадәттә, мондый чакларда Оризон көнендә үк йөгереп килә иде. Ләкин бу юлы ул никтер күренмәде. Гортекны ниндидер бер борчу хисе биләп алды. Шуңа күрә ул кичекмәстән дустының фатирына шылтыратырга карар кылды.

Видеостереотелефон экранында Оризонның елаудан шешенеп беткән хатыны күренгәч, Гортекның эче жу итеп куйды.

— Исәнме, Лали! Ни булды?

— Сез белмисезмени? — диде ачулы хатын, каш астыннан гына карап.

— Юк, мин берни дә белмим. — Гортек хәтта тотлыгып куйды. — Бер-бер хәл булды мәллә?

Лали, ике кулы белән битен каплап, сулкылдый-сулкылдый елап җибәрде.

— Нигә җавап бирмисең, Лали?.. Ни булды?!

— Ул... атылды, — диде хатын, телгә килеп.

— Ничек инде атылды? Нәрсә өчен?

— Нәрсә өчен икәнен син үзең дә бик яхшы беләсең.

— Кайчан атылды?

— Өченчекөн... Кичке якта.

Гортек, видеостереотелефонны сүндереп, йөзе белән өстәлгә капланды.

— Их-х, Оризон! — дип ыңгырашты ул, йодрыгы белән башын төеп.

— Гортек әфәнде. — Эмма видеоселектордан эндәшә.

Гортек, көч-хәл белән башын күтәреп, төймәгә басты.

— Нәрсә, Эмма?

— «Галәм» гәзитенең бүгенге санын карап чыктыгызмы?

— Юк әле, өлгермәдем.

— Оризон Вего...

— Беләм.

Гортек өстәлдә яткан газетаны куркып кына кулына алды. Беренче биттә ул-бу юк: Үрмәкүч планетасы гуманоидлары Кыз йолдызлыгындагы ундүрт пульсар йолдызны урлаганнар. Икенче-өченче биттә дә әллә ни күренми. Андромеда томанлыгының

Утлы Божра планетасындагы параллель дөньялар арасында сугыш башланган. Тәхет планетасына тиздән рәсми визит белән Аждаһа планетасы президенты киләчәк һәм башка шуның ише язмалар.

Оризон турындагы мәкалә ундүртенче биттә иде. Шактый саллы күренә. Яртысыннан күбрәк өлеше аның тәрҗемәи хәлен һәм иҗатын яктыртуга багышланган. Калган өлешендә автор тузга язмаган төрле гөманнар кора:

*«Күренекле язучы Оризон Вегоның фаҗигале үлеме әлегә барыбыз өчен дә табышмак булып кала. Өченчекөн аның фатирындагы өстәл тартмасыннан астронавт Вукало Вутоның ашыгыч телеграммасы табылды. Ул күренекле язучыга Киек Каз Юлы йолдызлыгының Кояш системасындагы Җир планетасында яшәүче Даниэл һәм Нелли исемле егет белән кызның исән-имин булулары һәм кавышулары турында яза. Телеграмманы ул «...мин хаклы булганмын» дигән сүзләр белән тәмамлый. Язучы бу җирлеләрне каян белә?*

*Мәгълүм булганча, аның Җирдә бер генә тапкыр да булганы юк. Мөгаен, анда язучының астраль тәне (рухы) булып кайткандыр. Әйтик, йоклаганда, һушын җуйганда... Галимнәрнең күпчелеге язучының үлемен аның Неллины яратуы һәм кызның башка кешегә кияүгә чыгуы белән бәйлиләр. Ләкин бу да бик ышандырмый. Табышмакны чишәргә Вукало Вуто үзе генә ярдәм итә алыр иде. Кызганычка, ул кайтыр юлга чыккач, метеорит яңгырына юлыгып, үзенең экипажы белән һәлак булды.*

*Тикшеренүләр дәвам итә».*

Бүлмәдә һава җитми башлагач, Гортек урамга чыкты. Көндезге сәгать утызлар булуга гына карамастан (монда бер тәүлек кырык ике сәгатькә сузыла), ясалма кызыл кояш инде офыкка тәгәрәгән иде. Унбиш-егерме минуттан эңгер-меңгер башланачак. Ә бер сәгатьтән шәһәр төн пәрдәсе астында калыр.

«Их, Оризон, — дип уйлады Гортек, бите буйлап аккан күз яшьләрен пиджак җиңе белән сыпырып. — Үз башыңа ашыккансың икән. Барысы да син теләгәнчә булды бит. Калифорниядә җир тетрәгән, Даниэл белән Нелли исән. Димәк, әсәрнең беренче эшләнеше үз көчендә кала. Эмма керткән төзәтмә тәкъдири көчкә ия түгел, кайтуга ук фантастик хикәя язам. Синең турыда, Оризон, җирлеләрнең бәхетле матур тормышы хакында. Бәлки, минем язганнарым да анда матди төс алыр».

Башка көннәрдә Гортек «МОБ-1» (микроочкыч башмак) белән кайта иде. Әмма бу юлы, сул аякның гравитация табаны төшеп калу сәбәпле, магнитоплан трассасына юнәлде.

Магнитопланда халык күп түгел иде. Үзе төшәргә тиешле Меркурий тукталышына җитәрәк, Гортек тамбурга чыкты. Анда бер исерек, пыш-пыш тәмәке тартып, вагон ишегенең алтын тоткасын сүтеп маташа иде. Яшел комбинезоннан үзе. Димәк, Җирдән

килгән. Шәһәрдә хәзер алар бик еш күренәләр. Кайсы турист, кайсы эш эзләп килгән. Шулай да күпчелек чәчәк сату белән шөгыльләнә. Кояш системасыннан алып кайтылган умырзаялар Ак-күз планетасында иң затлы бүләкләрдән санала. Мондагылары, ни гүзәл булмасыннар, синтетик сумала күбеге.

Гортек егетне оялтырга теләде.

— Нинди кыргыйлык! — диде ул, баш чайкап.

Теге, сискәнеп, аңа таба борылды. Ялгызы булуын аңлап алгач, ул теш арасыннан гына сытып чыгарды:

— Үз юлыңда бул, кәмшек танау!

Гортек, эшнең кая таба барганын аңлап, диварга беркетелгән кара микрофон астындагы төймәгә басты.

— Алло, полиция, — дип мыгырдады ул. — Унбишенче вагонда…

Ташбәбәк аны, сүзен дә әйтеп бетерергә ирек бирмичә, ишеккә китереп кысты.

— Сез ни кыланасыз? — дип акырды агарынган Гортек, муенына батып кергән көчле бармакларны каерырга теләп. — Алыгыз миннән кулыгызны!

Күзләрен кан баскан җирле, ике дә уйламыйча, көчле йодрыклары белән аның ике каш арасына китереп кундырды. Бичара Гортек шунда ук бер өнсез идәнгә тәгәрәде. Аннары ул үзенең эченә, башына типкәннәрен тойды. Калганын хәтерләми.

Гортек хастаханәдә генә аңына килде. Игътибарлы шәфкать туташы аның хәлсез кыймылдаган иреннәреннән бердәнбер сүзне аңлый алды:

— Каләм.

Туташ гаҗәпләнде:

— Каләм?

— Бетерәм җирлеләрне, — диде ул, үтәли ярсып. Бу юлы аның тавышы гайрәтле яңгырады.

Гортек, бөтен үчен, ярсуын салып, кәгазьгә беренче сүзләрне төшерде: *«Җир вакыты белән 2003 санәнең тугызынчы аенда Киек Каз Юлы галактикасында Кәрлә сары йолдыз (Кояш)…»* Җирлеләрнең бәхетенә, «сүнде» дигән сүзне язганда, чамасыз нәфрәт басымына чыдый алмыйча, карандаш очы шартлап сынды. Карандашны кабат очлаганда, язучының ярсуы шактый сүрелгән иде инде.

## СЕРЛЕ КЕШЕ

Күзнең матур бер көне иде. Казан каласының иске тимер юл вокзалыннан, алак-йолак каранып, корак-корак йөткереп, кулына иске чемодан тоткан бөкре бер карт килеп чыкты. Яше җитмештән узган булыр. Башына таланып беткән колаксыз бүрек, өстенә инде күптән сәдәп күрмәгән кырык ямаулы бишмәт, ая-

гына тишек чабата кигән. Кем булуын, кайдан килгәнен сорама. Бу миңа да, синә да, мөхтәрәм укучым, әлегә сер булып кала. Әйдә, аны бергәләп күзәтик, кылган эш-гамәлләрен күрик. Аннары, бәлки, нинди дә булса бер фикергә килербез. Тик алдан ук кисәтеп куям: минем рөхсәттән башка теләсә кая борыныңны тыкма, юкса борының кысылып калырга мөмкин. Ә хайвани инстинктлар тантана иткән җәмгыятьтә борын дигәннәре иллә дә кирәкле нәрсә санала. Бөкренең бертуктаусыз уйнап торган кечкенә яшел күзләренә кара, аларда автоген утыдай куырып ала торган зәһәрлек, мәкер һәм хәйлә бар.

Серле кеше гәзит-журналлар сатыла торган киоск янына килеп басты. Чират шактый зур. Ләкин ул чират торып маташмады. Чемоданын борчак чүмәләседәй ишелгән юан марҗа каршысына китереп куйды да, бишмәт кесәсеннән бер уч акча чыгарып, дорфа тавыш белән киоскер хатынга мөрәҗәгать итте:

— Миңа «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан», «Татарстан яшьләре» һәм м-м… «Татарстан хәбәрләре».

— Кончились, — дип җавап бирде сатучы, кулларын җәеп.

Читтә өелеп яткан татар гәзитләрен күрсә дә, сәер кеше тарткалашып тормады. Һәм бик дөрес эшләде. Чөнки моның бернинди файдасы юк. Ул киткәч, татарны бөтен вөҗүде белән күрә алмаган урыс хатыны аны яңадан кеше күзеннән качырачак. Шулай булган, шулай бара, шулай булачак. Хәер, анысын вакыт күрсәтер.

— Тогда дайте что есть! — диде серле кеше.

— Только «Вечерний дурман».

— Пойдет.

Ул, гәзитне алып, читкәрәк китеп басты. Аның бер кырыен ертып, махра төрде дә, авызыннан берничә зәңгәр төтен боҗрасы чыгаргач, бер күзен йомып, икенчесен кысып, әштер-өштер генә гәзитне карап чыкты.

— Зәгыйфьләр җитәрлек икән монда, — дип мыгырдады ул, канәгать елмаеп, һәм гәзитне чүп савытына томырды.

Син ничектер, укучым, ә мин аның нәрсә әйтергә теләгәнен аңламадым. Сабыр төбе сары алтын, түземле булыйк.

Серле кеше елак малаен мәктәпкә озатып, дөресрәге, өстерәп баручы яшь кенә ханымны күзәтә башлады.

— Не хочу, не хочу в татарскую гимназию! — дип чәбәләнә малай, әнисенең кулыннан ычкынырга теләп. — Все равно убегу!

— Күр, күпме кеше карап тора үзеңә! — дип сукрана ана. — Үзәкләремә үттең бит инде, юньсез!

Якында гына туңдырма саталар иде. Киребеткән малай тагын да катырак шыңшый башлады.

— Хосу мороженое!

— Елама, хәзер алып киләм! — диде анасы. — Шушында гына басып тор!

Ханым туңдырма алырга йөгерде. Серле кеше исә, форсатны

ычкындырырга теләмичә, имән бармагын кәкрәйтеп, малайны үзе янына чакырды.

— Хәзер мин сине кәнфит белән сыйлыйм, бәбекәчем, — диде ул, чемоданын ачып. — Сайла, кайсысы ошый?

Малай шикләнеп сорап куйды:

— Ты кто?

— Минме? Мин… теге ни… Микрәб бабаң булам. Җә, кайсысын аласың?

Күзләре ут булып янган бала, куанычыннан сикерә-сикерә, кычкырып ук җибәрде:

— Давай все!

— Бөтенесен дә ашап бетерә алмассың, — диде Микрәб, аның башыннан сыйпап. — Син бит инде болай да авыру малай. Хәзергә маңкортлык кәнфите дә бик җитеп торыр. Ә менә боларын мин сиңа үсеп җиткәч бүләк итәрмен, яме? Ач әле авызыңны… Менә шулай… Маладис!

Малай тач-точ кәнфит суыра башлады, Микрәб исә, чемоданын култык астына кыстырып, ишләп кенә трамвай тукталышына юнәлде.

Менә малайның әнисе килеп җитте.

— Мә, тот морожныеңны, елан!

— Һау-һау! — диде малай. Рәвешен китереп ырылдап та куйды.

— Кыланма, — диде әнисе, аны җитәкләп. — Әйдә, атла аягыңны, болай да соңга калдык.

Малай бүре булып улый башлады, кылана белә, каһәр. Киләчәктә менә дигән әртист чыгар үзеннән. Тик бераз арттырып җибәрә. Әнисенең сүзләрен колагына да элми — һаман шаяра. Абау, инде тешләшә дә башлады!

— Әччәч, нишләвең бу синең, газазил?! — Хатын чәчрәп читкә тайпылды.

Малай тагын да зәһәррәк ырылдый. Аңгыраеп калган анасы артка чигеп барды-барды да кинәт лап итеп, асфальтка утырды. Күзләре — тәлинкә! Малай исә, Микрәбнең трамвайга кереп барганын абайлап, өрә-чиный, аның артыннан җилдерде.

Трамвай кузгалып китте.

— Хуш, маэмай! — дип мыгырдады Микрәб һәм тәрәзәдән ипи сыныгы ыргытты.

Пассажирлар, трамвай артыннан куып килгән сәер малайны күрергә теләп, тәрәзәгә ябырылдылар.

— Мескен бала, — диде берәү. — Беренче тапкыр күрәм шундый авыруны.

— Нигә беренче тапкыр гына? — Микрәб чын күңелдән гаҗәпләнде. — Мондый маңкортлар шәһәрдә буа буарлык ич.

Аның ни әйтергә теләгәнен аңлаучы булмады. Хәер, тыңлаучысы да юк иде.

— Карагыз, карагыз, ул эткә әверелде! — дип кычкырдылар төркемнән.

— Җен бу, валлаһи, җен!

— Булыр, булыр, бик күп яздылар инде алар турында!

Микрәб янә тәрәзәгә күз салды. Трамвай артыннан чыннан да аклы-каралы бер эт чаба иде.

— Әйе, җен бу, җен! — диде ул, гаҗәпләнгән кыяфәт ясап, һәм, үзенең эшеннән тирән канәгатьләнеп, салон уртасына атлады.

Бичара бала, мин аны кызганам. Син дә кызган, укучым. Маңкортлык авыруына дәва юк. Ул гомеренең соңгы көненә кадәр үз анасын дошман күрәчәк. Газиз милләтенә каршы сугышучы өлкән маңкорт абыйлары аннан разый булачак.

«Балалар дөньясы» кибете янындагы тукталышта төшкәч, Микрәб тәти урыс бурзаен җитәкләп баручы урта яшьләрдәге чибәр ханымны үзенең кәнфитләрен алырга кыстый башлады.

— Кайсысын аласың? — диде ул, барысын да мактап бетергәч. — Менә монысы, «Явыз даһи» дигәне — унбиш, бусы — ун, бусы… м-м биш сум тора.

Чибәр ханым бармак аркасы белән сөрмә тарткан күзләрен ышкый — икеләнә.

— Исемнәре сәер, — ди.

— Нигә сәер булсын? — дигән була Микрәб. — Хикмәтле дисәң инде. Менә монысы — «Мәңгелек машина» дигәне, җенси дәртне арттыра. Ә менә бу кызыл укалысы бөтен күңелне йоклата.

— Алам! — Ханым, кабалана-кабалана, ак ридикюлендә актарына башлады. — Соңгы вакытта берни уйлыйсы килми, бабай. Телевизор карасаң, гәзит укысаң, прәме үләселәр килә. Харап итәләр инде Рәсәйне. Барысына да суверенитет кирәк.

— Алгач алгач, шәмәхә укалысын да ал инде, — диде Микрәб. — Этең шунда ук кешечә сөйләшә башлаячак.

— Чынмы? Бирегез, алайса, берне! Шаккаттырыйм әле Сашамны!

Эт кәнфитне чәйнәп тә тормыйча укасы белән йотып җибәрде. Тагын бирмәсләр микән дип, селәгәен агыза-агыза, әле хуҗасына, әле Микрәбкә карап торды-торды да коеп куйган Майновский тавышы белән тезеп тә китте:

— В бывшем Союзе остануться только губернии и только губернии. Всех татар отправлю в Монголию. — Эт арткы тәпиләренә басып, хуҗасына усал карап, өстәп куйды: — Тебя тоже!

— Нәрсә, нәрсә? — дип чәрелдәде ханым. — Монголия дисеңме? Аһ син, бет капчыгы! Хәзер мин сине…

— Молчать, татарская морда! — Бурзай эт, тешләрен ыржайтып, аңа таба килә башлады. — А не то копыта переломаю!

Нәкъ шул чакны әллә кайдан гына пәйда булган аклы-каралы бер урам эте, колакларын салындырып, койрыгын болгый-бол-

гый, шуышып килде дә аның тәпиләрен яларга кереште. Микрәб бу этне таныды. Бу — аның кулыннан кәнфит ашаган малай иде.

— Смотрите, какое прекрасное поколение подрастает, — диде бурзай сокланып. Аннары бүз күбәләге төсенә кереп абынасөртенә баскычтан үрмәләгән хуҗасына әйтте. — Далеко не убежишь, миллион посажу, миллион расстреляю. А остальное вот эта дворняжка сделает.

Ул арада бер төркем халык җыелды.

— Барып чыктык, — дип мыгырдады түшенә депутат значогы таккан бер ир-ат. — Этләр дә кешечә сөйләшә!

— Ни гаҗәбе бар? Дәүләт башына да менеп кунакладылар әле, — дип төрттерде кемдер. — Шуңа күрә эт тормышына калдык та инде.

— Сез ни димәкче? — диде депутат, әлеге сүзләрнең хуҗасын күзе белән бораулап. — Дәүләт башында этләр утыра димәкчеме?

— Эткә җитәсең бар әле! — Нечкә генә муенлы, сап-сары тешле бер сәрхуш әйтте моны.

— Ничек инде? Мин дә сөйләшә беләм.

— Шул шул менә. Сөйләргә остардыгыз, эшләргә кеше калмады.

— Әллә мин эшләмимме? Беләсең килсә, мин гомерем буе колхозда мал врачы булып эшләдем.

— Алдапма, авылыңа кайтып кермәгәнеңә дә бишбылтыр инде, кулларыңа кара, эшем иясе!

— Дөрес, — дип кычкырдылар халык арасыннан. — Колхозында эшләсәң мең шөкер дә бит, закон язу белән мал дәвалау бер түгел ул. Анда баш кирәк.

Микрәбне тәмам истән чыгарганбыз. Ә ул инде, ялт-йолт карапып, Бауман урамына борылды.

Бара торгач, Микрәб «Татарстан» кинотеатры янында үткәнсүткән кешеләргә телен күрсәтеп утыручы утыз-кырык яшьләрдәге бер бәндәгә игътибар итте. Килеш-килбәтенә караганда, хәер эстәүчегә һич тә охшамаган. Акылы зәгыйфь дип тә әйтеп булмый. Карашы мәгънәле, хәтта акыллы күренә.

— Син нигә телеңне чыгарып утырасың? — дип сорады аннан Микрәб.

Бакырбаш бөердән чыккан тавыш белән әйтте:

— По-русски говори!

— Нигә тел күрсәтәсең, дим, — диде Микрәб урысчалатып.

— Ничек инде нигә? Акча эшлим. Метр ярымга җитә минем телем. Унлык түлә, сиңа да күрсәтәм.

— Яле, яле, карыйк. — Микрәб аңа унлык сузды.

Теге, гадәти эш эшләгәндәй, телен чыгарып җилкәсенә салды.

— Ошыймы? — дигән була үзе. — Тиздән Америкага очам. Гиннесслар китабына яздырып кайтам.

— Һәй, мондый телне ничек үстерә алдыгыз? — дип сорады читтә басып торган бер туташ.

— А, чибәрем, моның өчен көне-төне гайбәт сатарга кирәк. Менә инде ничә еллар тел чарлыйм, татар милли хәрәкәте узаманнары, Ичкериянең бәйсезлеген саклаучы каһарманнар турында төрле уйдырмалар таратам. Телем көне белән бер карышка озыная.

— Тапкан мактанырлык нәрсә, — диде Микрәб. — Бу дөньяда озынрак телләр дә бар.

Әлеге сүзләрне ишеткәч, озынтелнең йөзе сытылды.

— Юк сүз!

— Юк сүзме? — Микрәб, чемоданын ачып, аңа зәңгәр кәнфит тоттырды. — Аша менә моны!

— Нигә ашыйм мин аны?

— Белерсең.

Озынтел кәнфитне теләр-теләмәс кенә авызына капты. Аннары чыраен сытып әйтте:

— Әче.

— Түзәргә кирәк булыр, — диде Микрәб. — Хәзер телең тагын да озынаер.

— Нәрсә, нәрсә? — диде теге, кәнфитне тач-точ суырып.

Шул мизгелдән искитмәле хәл булды. Мактанчык бәндә, адәм теленә әверелеп, асфальтка сузылып ятты. Ул һаман саен үсте, киңәйде, калынайды. Урамда — ыгы-зыгы, буталыш, елаш һәм кычкырыш китте. Беркемнең дә сәер җанвар тырнагына эләгәсе килмәде. Яше-карты, башын-күзен акайтып, кинотеатр, кибет ишекләренә, подъездларга һәм телефон будкаларына ыргылды.

Ниһаять, Куйбышев мәйданындагы җир асты юлына җитәрәк, тел үсүдән туктады, хәрәкәтсез калды. Ә кешеләр, күпкатлы йорт тәрәзәләреннән, кибет ишекләреннән башларын тыгып, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, төрле куркыныч гөманнар корырга керештеләр.

— Инәпләнитәннәр һөҗүмедер бу, җәмәгать.

— Булыр сиңа, пычагым! Гап-гади адәм теле икәнен күрмисең мәллә?

— Кемнеке?

— Шайтан белсен аны. Озынтелләр күп хәзер Русиядә.

Ярый, алар гәпләшә торсыннар, ә без яңадан Микрәб артыннан иярик. Әнә аның янында яшь кенә милиция сержанты һәм барыбызга да бик яхшы таныш булган эт хуҗасы басып тора.

— Менә ул минем бурзаемны харап иткән кеше, — ди ханым, елак тавыш белән. — Кулга алыгыз аны тизрәк!

Сержант документ таләп итте. Микрәб исә гаҗәпләнеп сорап куйды:

— Сез мине танымыйсызмыни?

— Күрсәтегез документыгызны! — Егет үҗәт. — Шулай бик нык танышасыгыз килсә, эчке эшләр бүлегендә танышырбыз.

Ханым һаман тынычлана алмый, тәртип сакчысына өр-яңа мәгълүматлар бирә:

— Сез аның чемоданын ачып карагыз. Андагы заразаның игечиге юк!

— Зараза синең үзеңдә дә җитәрлек, апшагым, — дип мыгырдады Микрәб һәм бишмәтен салып сержантка ыргытты. — Рәхим итеп карагыз.

— Ах ты, нахал! — дип чәрелдәде эт хуҗасы. — Мин моны болай гына калдырмыйм!

Сержант бишмәт кесәсен актара башлады. Ул арада Микрәб җиргә сеңгән су кебек юк булды. Кырык ямаулы бишмәт исә таушалып беткән Советлар Союзы картасына әверелгән иде.

— Что за чёрт! — диде теге, күзләрен акайтып. — Күз буучы булды мәллә?

Ханымның сөрмә тарткан күзләре аныкыннан да зуррак иде. Бизгәк тоткандай дер-дер калтырап, һаман бер сүзне тәкрарлый:

— Качты, тәки качты…

Микрәбнең кеткелдәп көлгәне ишетелде:

— Сез мине әле бик озак оныта алмассыз.

— Син кайда? — Сержант, кобурасыннан пистолет чыгарып, тирә-юньгә күз салды. Якында нибары бер мәче мыраулап утыра.

— Минме? — диде тавыш. — Мин сезнең һәрберегездә!

Сержант, сүгенә-сүгенә, чемоданны ачты. Эчкә күз салгач, ул андагы һәр кәнфитнең укасында «Made in USSR» (СССРда ясалды) дигән язу ярылып ятканын күрде.

## ШОМЛЫ ГАСЫР

Ике меңенче елны бөтен дөньяны яулап алгач, Русия президенты Майновский Андромеда томанлыгындагы Туккүз планетасына катгый таләп җибәрде. Аның эчтәлеге мондый иде:

*«Әй сез, ач күзләр!*

*Туккүз планетасы элек-электән Русия җире булган. Әгәр тиз арада бөекросслар дәүләте составына кермәсәгез, башлыгыгызны Лефортово төрмәсенә утыртып, барыгызны да айга сөрәчәкмен».*

Әлеге таләпне алгач, зур җыелышка килгән аксөякләр арасында бәхәс купты. Берәүләр: «Шундый ерак урнашкан дөньяга да дәгъва белдерергә батырчылык иткәч, җирлеләр бик югары үсешкә ия инде, алар безне барыбер коллыкка төшерәчәкләр»; икенчеләре: «Һөҗүм башланганчы, үзебезгә көтмәгәндә генә сугыш башлап җибәрергә кирәк»; өченчеләре: «Әгәр бөтен Җир шарын яулап алган икән, Майновский тиле түгел. Аның белән кичекмәстән сөйләшүләр алып бара башлау һәм дуслык мөнәсәбәтләре урнаштыру дөресрәк булыр», — дигән фикердә тордылар.

Бәхәс алты көн, алты төн дәвам итте.

Җиденче көнне мәсьәлә тавышка куелды. Ниһаять, Җир президенты Майновский белән сөйләшүләр алып бара башларга кирәк диючеләр төркеме җиңү яулады. Зур җыелыш Җиргә парламентёр итеп көнкүреш министры Көн Карны җибәрергә булды. Ул Җирне яулап алган даһи юлбашчының бөек халкына бүләк итеп җылы кием-салым кәрванын да озатып барырга тиеш иде.

Җыелыш тәмамлангач, Көн Кар, хатыны Мәнмөн белән саубуллашырга дип туп-туры өенә чапты. Онытып җибәргән икән, Мәнмөне Кызыл планетадан ике атнасыз кайтмаячак бит. Картаеп беткәч кенә университет тәмамлап йөргән була.

Көн Карның тамагыннан аш узмады. Магнит караватка сузылып ятты да: «Уф Алла, исән-сау кайтып житеп булырмы?» — дип ыңгыраша башлады.

— Әфәндем!

Стереовидеотелефон экранында үзенең урынбасарын күргәч, Көн Кар җикеренеп әйтеп куйды:

— Нәрсә кирәк?!

— Га… гафу итегез, — диде урынбасар, мескен тавыш чыгарып. — Мин җылы кием-салым мәсьәләсендә шылтырата идем.

— У-у, кара җан, сөенәсең инде, ә?! — Көн Кар, йодрыгын болгый-болгый, урыныннан сикереп торды. — Сине җибәрергә кирәк иде анда, сине-е! Күптән минем урынга утырырга хыяллланасың инде!

Урынбасарның чебен таеп егылырдай шома башында бөрчекбөрчек тир бәреп чыкты.

— Ыһм… Теге ни, әфәндем…

— Нәрсә ни?! Сөйлә тизрәк!

— Русиялеләр ничә аяклы, ничә куллы дип соравым иде. Шунсыз фабрикаларга фәрман юллап булмас бит.

— Әнә галимнәр башлыгы Сөлем Калемгә шылтырат. Инде егерме ел буе телескоптан Җирне күзәтә. Ул барысын да белә торгандыр, — диде министр, суына төшеп. — Бер атнадан ике миллион данә тун, өч миллионлап итек, дүрт миллион данә бүрек әзер булсын. Син мине аңладыңмы?

— Аңладым, әфәндем, бик аңладым. Хушыгыз!

Стереовидеотелефон экраны пелт итеп сүнде. Анда инде зәңгәрсу бер нокта гына җемелдәп тора. Көн Кар янә караватка сузылып ятты. «Чыннан да, ничә башлы микән бу җирлеләр?» — дип уйлады ул.

Күпме яткандыр, урынбасар тагын элемтәгә керде.

— Гафу итегез, әфәндем, — диде ул, ишетелер-ишетелмәс кенә тавыш сыгып. — Шылтыраттым мин Сөлем Калемгә. Безнең кебек үк ике аяклы, ике куллы икән ул русиялеләр. Тик менә…

— Нәрсә менә?! Сөйлә!

— Бүрек белән маташмаска иде, әфәндем.
— Аh син, йонлы колак, чимал юк димәкче буласыңмы?!
— Юк, юк, әфәндем, чимал җитәрлек. Сөлем Калем әйтә, русиялеләр көн дә баш кисү белән шөгыльләнәләр, аларның бүрек кияргә вакытлары юк, ди.
— Шулаймыни? — дип мыгырдады Көн Кар, үз-үзен кызганып. — Алайса, миңа дигәнен дә тектереп маташма. Җиргә төшкәч киеп өлгерә алмавым ихтимал.

## ЯХШЫГА ЮРЫЙК, МИНГОЛ

Төштә бер центнерлы үрдәк, кыяр түтәлендә хикәя, агачта акча үстерү начарга булмас, Мингол, яхшыга юрыйк. Соңгы вакытта мин үзем дә бик сәер төшләр күрәм. Әйтик, кичә миңа менә мондый төш кергән иде.
Имеш, Идел яры буйлап барам икән. Барам, барам шулай, бара торгач, балык тотып утырган бер урыс картына тап булам. Тыныч кына узып китәсе дә бит, юк шул, кызыксыну үзенекен итә.
— Чиертәме, абзый? — дип сорыйм тегеннән.
— Чиертә, пычагым, — ди бу, йөзен бозып. Үзе hаман черт итеп суга төкерә. — Балык түгел, бака да юк монда.
Комда аунап яткан күгәргән консерва банкаларын, су өстендә елтыраган май-мазут тапларын абайлагач, аңладым мин монда нигә бака да яшәмәгәнен.
— Бир әле кармагыңны, — мәйтәм. — Үзем тотып карыйм әле. Яшь вакытта бик маhир идем мин бу эшкә.
Ялындырып тормады, бирде. Бик эшлекле кыяфәт ясап, симез генә бер суалчанны кармакка киертеп куйдым да кармакны суга болгадым.
Бер минут уза, ике минут... Берзаманны калкавычым выжт итеп төпкә китмәсенме. И өстерим кармакны, и өстерим! Көчем җитмәгәнне күреп, теге хәсрәт балыкчы да булыша башлады!
Өстерәп чыгардык тәки. Валлаhидыр газим, каршыбызда балык түгел, дер-дер калтырап, иптәш Урманов басып тора! Су атасы дип уйларсың, өстеннән шыбырдап су ага.
— Бәрәч, иптәш Урманов, сезме бу? — дим, исем китеп.
— Мин, мин, Хәйри, — дип җавап бирә теге, елмайгандай итеп. Аннары елак-сытык тавыш белән ялвара башлый. — Харап итмә инде син мине, туган, кеше күзе күргәнче, тизрәк суга җибәрә күр, — ди.
— Алай ярамас бит, — мәйтәм. — Кеше генә түгел, чебен дә үтергәнем юк минем. Әйдә, туган, рәхмәтеңне әйт тә...
Тегенең күзләре яшьләнде.
— Син генә коткара алмассың инде мине, — ди. — Татарстаннан кудылар. Мәскәүдә дә рәт калмады. Гомер бакый Мәс-

кәүгә хезмәт итеп яшәгән түрә бит мин. Шуны гафу итә алмыйлар. Хәзер менә кирәгем беткәч, Мәскәүгә дә ярамый башладым. Башка барыр урыным юк. Яшим дисәң, шул су астында гына яшәргә кала инде. Бөтен өмет гекә чепедә генә, якташ, — ди.

— Анысы нәрсә була инде? — дим, колагымны тырпайтып.

— Икенче төрле әйткәндә, путч була ул, Хәйри. Ягъни тиздән демократиягә кәнис булачак. Илдә янә коммунистик диктатура көтелә. Аннары менә синең кебек нахалларны Черек күлгә олактыра башлаячакбыз.

Үлдем дә киттем шушы сүзләрдән.

— Аллам сакласын, — мәйтәм, авыз суым корып, — нинди нахал булыйм ди мин? Сезне кармакка эләктерү уемда да юк иде.

— Беләм мин сине, — ди теге, бармак белән янап. — Кайчан карасаң, шунда Ирек мәйданында «азатлык!» дип кычкырып йөрисең. Каплarбыз әле без, исән булсак, синең авызыңны, капларбы-ыз!

Ачуым чыкты. Нәрсә булса да булыр дип, тоттым да болгадым тегене елгага.

— Вәт әкәмәт, вәт әкәмә-әт! — дим, башымны чайкап. — Ниләр генә булмый бу дөньяда. Ирексездән кеше үтердем бит, ә. Ни эшләргә? Шулай дип милициягә җәвит итәргәме? Бетә бугай газиз башкайларым.

Шулай ух-вах килеп утырганда, су өстендә тегермән күсесенә охшаган иләмсез бер зат пәйда булды.

— Кем чакырды мине? Мин булам Әкәмәт, — ди бу. Тавышы кемнеке дип әйтим соң? Ну, прәме Левитан инде менә!

— Белмим, — дип мыгырдыйм, котым очып, — сине беркем дә чакырмады.

— Алдашма, син чакырдың мине, — ди җирәнгеч зат. — Минем исемем Әкәмәт. Гыйфрит булам мин. Әйт кенә, теләсә нинди әмереңне үтәргә әзермен!

Шулай дигәч, батыраеп киттем тагын.

— Алайса, — дим тегеңә, важный кыяфәт ясап. — Мәскәүдә путч оештырган теге хәчтерүшләрне китер. Аларга бер-ике сорау бирәсем килә.

— Була ул, — диде дә гыйфритем, җиргә сеңгән су кебек, юк булды.

Форсаттан файдаланып тәртә каерам дип торганда гына кайтты да житте тәре баганасы! Муенына теге нине... вице-президент Чинаевны атландырган.

Нихәл кыласың инде, Мәскәү кунагы белән әңгәмә корып җибәрдек. Сорау бирәм тегеңә, ызначит.

— Нәрсә, агайне, демократия ошамый башладымы? — дим. — Яңадан коммунизм төзергә тотынабызмыни?

— Аны без синнән башка гына төзербез инде, — дип җавап бирә путч башлыгы. — Тулада исәпсез-хисапсыз тимер беләзек-

ләр ясаттык. Шуларның берсе синеке булыр, шаять. Монда балык тотып вакыт әрәм иткәнче өеңдә сохари киптереп утыруың яхшырак булыр.

— Аһ, әле син шулаймы? — дим, кызып китеп. Һәм, аяк тибеп, гыйфриткә кычкырам. — Анда, су астында, Урмановка берүзенә генә күңелсездер, болга хәчтерүшне елгага!

Гыйфрит бик уңайсызланды. Мескен генә тавыш чыгарып колагыма пышылдый:

— Син мине гафу ит инде, хуҗам, — ди. — Мин үз туганыма кул күтәрә алмыйм инде, — ди.

— Алайса, икегез дә күземнән югалыгыз! — дип ыжылдыйм тегеләргә. — Юкса...

Күрәм, икесе дә юк булдылар. Җиһанны шомлы караңгылык басты. Яхшылабрак карасам, елга ярында түгел, урман аланында басып торам бит, каһәр. Якында гына бер кәҗә белән бер сарык казан асып учак ягалар.

Килдем мин болар янына. Хәл-әхвәл сорашып алгач, сөйләшеп киттек. Бичаралар, бәйсез дәүләт төзергә җыеналар икән.

— Гомер буе абзарда яшәп булмый ич, — диләр. — Хуҗа бүген нәрсә ашатыр, иртәгә кемгә сатып җибәрер дип яшәү дөрес хәл түгел. Ничә йөз еллар буена «мә» дип яшәдек, инде «микимки», ягъни «минеке» диярге дә вакыт җитте. Ошбу аланга дуңгызлар килгәнче безнең ата-бабаларыбыз яшәгән. Хәзер аны кире кайтарып алырга кирәк.

Шул мәлне куаклар арасыннан, мыркылдый-мыркылдый, дуңгыз көтүе килеп чыкты.

— Шушы үләтләр дә безнең урманда бәйсез дәүләт төзү төземәү турында референдум үткәрергә җыеналар бит, ә, — дип көлделәр төнге кунаклар.

— Үткәртмәбез!

— Болай авыз ачып йөрсәк, үткәреп куюлары да ихтимал.

— Хәл итик булмаса үзләрен!

— Шәп булыр иде. Инде күптән кәҗә ите ашаган юк.

Ниһаять, башлык сүз алды.

— Тәңре безнең белән. Әгәр бу хәерчеләр бүре башы күрсәтсәләр, һич тә шүрләп калмагыз. Чүтеки үз урманыбызда тәртип урнаштырабыз бит.

— Бетерәләр икән болар безне, — дип пышылдыйм кәҗә белән сарыкка. — Ычкыныйк без моннан тизрәк!

Ә аларның исләрендә дә юк. Дуңгызлар ишләп кенә учакны бoҗрага ала башлагач, кәҗә бытырдап торган казаннан бүре башы урынына симез генә дуңгыз башы чыгарды.

Моны күреп, кыргыйлар хәйран калдылар.

— Комачауламыйк без боларга, — дип мыркылдады дуңгыз башлыгы. — Бусы инде бүре башы гына түгел. Үзебезне дә ашап куймагайлары. Үткәрсеннәр үзләренең референдумнарын. Юкса

Карабахтан да кайнаррак булачак монда. Башка төрле җайларга кирәк бу юлы сарык белән кәҗәне.

Дуңгызлар китеп баргач, күрәм, яңадан өйдә мин. Кемдер ишек дөбердәтә. Үзең беләсең, Овражная урамында яшим бит мин. Анда һәркемнең үз йорты.

Чыгып ишекне ачтым. Яшь кенә бер егет көрәк сорый.

— Машина застряла, дед. Ты уж извини, — ди.

Яхшылабрак карасам, егет түгел, теге Әкәмәт булып чыкты бу. Әллә танымый, әллә танымаганга салыша... Бирдем мин моңа көрәкне.

Кереп ятуым булды, яңадан дөбердәтәләр. Чыктым. Тик бу юлы ишекне ачарга кыймыйм. Көрәкне ишек янында калдырырга кушкан идем бит. Юньлелек белән йөрмидер бу гыйфрит, мин әйтәм.

— Кем ул анда? — дип кычкырам тегеңә.

— Бу мин — Лукьянов! — дип кычкыра берәү ишек артыннан.

Коелдым да төштем, агайне. Әкәмәт алып килгәндер инде, бер-бер хәл кылырга җыеналардыр. Шулай да сер бирмим.

— Нәрсә, алырга килдегезмени? — дип кычкырам төнге кунакка. — Алай гына ала алмассыз, кәмшек танаулар. Чинаевыгыз белән бергә сәнәккә эләргә дә күп сорамам!

— Төнлә борчып йөргәнгә ачуланма инде, Хәйри, — ди бу, мескен тавыш белән. — Иптәш Чинаев сиңа сохари киптерергә кушкан булган, шуны безгә биреп җибәрә алмассыңмы? Иртәгә аны да, мине дә «Бутырка»га ябачаклар, — ди.

Беткән баш беткән, биреп җибәрим инде мин боларга бер капчык сохарины дип, өйгә кереп киттем. Керсәм, өйдә түгел, Бауман урамында басып торам, имеш. Ул җыелган халык, исәбе-хисабы юк! Уртада нидер өелеп ята. Ипи дисәң ипи түгел, шоколадка да охшамаган.

— Карале, агайне, нәрсә соң бу? — дип сорыйм берәүдән.

Сәер нигъмәтне чәйнәп-чәйнәп тә йота алмаган адәм борын астыннан гына мыгырдап куйды:

— Ильцин берите ыскульке влизит, диде, суверенитетны йотабыз, туган.

Барыбер йота алмады. Авызы кечкенәрәк шул. Гомере буе Мәскәүне туйдырган татарның авызы тәмам кечерәеп калган. Йота алучылар да булды булуын. Тик шундук косып чыгаралар. Әпәй түгел шул ул суверенитет, аны ашап булмый.

Әлеге тамашадан туеп, тизрәк китеп бардым. Ни күзем белән күрим, китап нәшрияты янындарак өч яшүсмер асфальтта җәелеп утырган базык кына гәүдәле бер ирнең башына кирпеч белән сугалар. Ник бер ыңгырашып карасын! Берни булмагандай чарт-чорт көнбагыш ашап утыра.

— Син нигә башыңа кирпеч белән суктырасың? — дип сорыйм тегеннән.

— Импортный кирпеч кайтарткан идем, — ди бу. — Берәү сәвит кирпечен катыштырып җибәргән. Шуларны аеру белән мәшгульбез. Ватылганы сәвитнеке, ватылмаганы чит илнеке.

— Болай башсыз да калырга була бит, — мәйтәм. — Аны башкача аерып булмыймыни?

— Нинди баш турында сөйлисең син? — ди. — Безнең илдә башлы кеше буламыни?

— Ничек инде булмасын?! — мәйтәм, гаҗәпләнеп. — Әлбәттә, була.

— Була әбиеңнең әкияте! Башыбыз булса, мондый башсыз җәмгыять төзер идекмени без? Син яхшылабрак кара, кемдә дә булса баш барын күрәсеңме?

Тирә-юньгә күз салдым. Менә могҗиза, урам тутырык башсыз кешеләр йөри! Үземнең башым да әллә кая киткән. «Бетерә икән хатын, — дип уйлыйм, хәсрәткә батып. — Өйгә башсыз кайтып булмас, эзләргә кирәк». Тик кайда онытып калдырганымны һич кенә дә хәтерләмим.

Шулай аптырап торганда, янымнан кулына зур чемодан тоткан элекке СССР Оборона министры, Советлар Союзы маршалы мәрхүм Устинов узып бара.

— Здравия желаю, иптәш маршал! — дим, тегене сәламләп. — Кая юл тоттыгыз?

— Тимер юл вокзалына, — дип җавап бирә Устинов. — Менә шушы чемоданны поезд белән Әфганстанга җибәрергә кирәк иде.

— Нәҗибулла әфәндегә дигән медальләрдер инде, — мәйтәм.

— Медальләрне җибәрдек инде, — ди бу. — Хәзер берничә мең кеше башы гына җибәрәсе калды.

— Шаяртасыз, — дигән булам елмаеп. — Шуның кадәр кеше башы бер генә чемоданга сыеп бетмәс.

— Нигә сыймасын? — ди Устинов елмаеп. — Ышанмасаң, ачып кара!

Чемодан эченә күз салдым да имәнеп киттем. Кеше башының исәбе-хисабы юк, агайне. Күбесе унсигез-унтугыз яшьлек егетләр. Бу мөртәт минем башны да алып тыкмаган микән дип, шулар арасыннан үземнең башны күзләргә тотындым.

— Нигә текәлеп каттың әле син? — ди иптәш маршал. — Әллә берәр танышыңның башын күрдеңме?!

— Таныш башлар юк-югын да, үземнең башны эзли идем әле, — мәйтәм. — Кайдадыр онытып калдырганмын каһәрне.

— Борчылырлык урын юк, — ди теге, эре кыланып, — җаның теләгәнен сайла!

— Бик шат булыр идем дә, кесәмдә сукыр бер тиен дә юк, — мәйтәм.

— Бушка бирәм, миннән бүләк булыр, — ди Устинов. —

Безнең сәвит илендә кеше башыннан да арзан нәрсә юк, кирәк булса, тагын табам мин, — ди.

Бик кыстагач, сайлап алдым мин бер башны. Тик күңел һаман тыныч түгел. Хатын танымаска мөмкин ич. Туктале, мәйтәм, ул эштә чагында өйдән эзләп карарга кирәк. Шунда онытып калдыргандырмындыр. Ә бусы запаска булыр. Безнең илдә ун башлы булу да комачау итмәс.

Менә шундый хәлләр, Мингол. Ярый, дәвам итәм төшемне.

Кайтып җиткәч, бөтен өйнең астын өскә китердем. Табып кына булмый бит каһәрне! Инде бик аптырагач, бер-бер баш табылды дип хәбәр бирмәсләрме дигән өмет белән телевизорны кабыздым. Как раз «Вести» программасы бара. Юк, юанырлык һичбер хәбәр әйтмиләр.

Менә берзаман экранда Ильцин күренде. Ни күзем белән күрим, өстәлнең бер читендә минем баш тора. Колаклары гына тырпаеп калган. Маңгаенда бәясе дә бар: «Мәскәүгә — бушлай».

— Татарны буйсындырдык, инде Чечняда тәртип урнаштырырга вакыт, — ди бу, зәһәр елмаеп.

Инде ни эшләргә? Баш Мәскәүнеке, хатын эштә. Кайтып, башыңны да югалтып йөри башладың дип, пичтәрне төя башлаганчы чыгып качарга кирәк.

Шулай гасабиланып арлы-бирле йөренә торгач, тәрәзәгә күз төште. Бусы инде һич акылга сыймый — йортым һавада эленеп тора!

Тәрәзәне ачып, тирә-юньгә күз салдым. Менә сиңа ичмаса могҗиза: берәү җир белән күк арасында йорт салып маташа.

— Агайне, сиңа нәрсә, җир җитмиме? — дип кычкырам тегеңә.

— И туган, дөньядан артта калгансың син, — дип җавап бирә теге, кайгылы тавыш белән. — Татарстан теге килешүгә кул куйды ич. Һава гына безнеке инде хәзер.

Тәрәзәне ябам гына дигәндә, баш очымда хәрби вертолет пәйда булды. Бер хәрби башын тыгып кычкыра:

— Әй Хәйри, синдә запас башлар бар дип ишеткән идем, хакмы бу?

— Бар барын, — мәйтәм. — Тик күп түгел, берәү генә.

— Алайса, бир, — ди теге. — Мин Русиянең Оборона министры Грачев булам. Тегендә, Чечняда, конституцион тәртип урнаштырыр өчен как раз бер баш җитми.

Алып болгадым мин моңа башны. Үз теләгең белән бирмәсәң, барыбер тартып алачак.

Тәрәзәне шарт итеп ябып куйдым да караватка сузылып яттым.

— Вәт әкәмәт, вәт әкәмә-әт! — мәйтәм.

Шулай диюем булды, каршымда тагын теге Әкәмәт басып тора. Күзләре утлы күмер булып яна.

— Кем чакырды мине? Мин булам Әкәмәт, — ди бу.

— Бик вакытлы килдең, агайне, — дим моңа. — Башны һич эзләп таба алмыйм, булыша алмассыңмы?

— Була ул! — диде дә гыйфрит, җиргә сеңгән су кебек юк булды.

Керфек кагарга өлгермәдем, яңадан пәйда булды бит.

Кулында — ике баш. Берсен таныдым. Минеке инде. Икенчесен менә һич кенә дә таный алмыйм.

— Кайдан таптың минем башны? — дип сорыйм Әкәмәттән.

— Кайдан булсын инде, чеченнар белән тауларга табан чигенеп барышы иде.

— Афәрин, — дим, газиз башкаемны сыйпап. — Йөзгә кызыллык китермәгән, алайса.

Ә баш нәрсә, үпкә белдерә:

— Син, Хәйри, мине бүтән мәскәүлеләргә биреп җибәрә күрмә инде, — ди. — Барыбер качып китәчәкмен, — ди.

— Юк, юк, мин сине бүтән беркайчан да, беркемгә дә бирмәячәкмен, — дим. Аннары Әкәмәткә сөаль бирәм:

— Ә бусы кем башы?

— Генерал Воробьевныкы, — ди гыйфрит. — Моздокны чеченнар утка тота башлагач, башын тумбочкага качырып куйган иде. Шуннан чәлдем. Кирәк булса, Грачевныкын да алып кайтып бирә алам. Ул, һава һөҗүме башланганда, башын карават астына качырырга ярата.

— Юк, юк, кирәк түгел, — мәйтәм, борынны җыерып. — Казанда экология болай да бик начар хәлдә.

Менә берзаманны тәрәзә артында Ильцин йодрык болгап тора.

— Аң бул, Хәйри, — ди. — Чечняны җиңгәч, синең йортыңда да конституцион тәртип урнаштырырбыз, — ди.

— Ай-һай, белмим шул, — дим, эчем пошып. — Чечня түгел бит ул минем хатын, аңа вертолет та, бомба да кирәк түгел, очып кына менеп атлана.

— Ач ишекне, юкса ватып ачам, — дип кычкыра Ильцин.

«Тукта, — мәйтәм, — тавышы хатынныкы бит моның». Уянып китсәм, Мәчтүрәкәем, чыннан да, тәрәзә шакылдата. Иртәнге сменадан кайтышы икән бәгырьнең.

## МУНЧА

Кышның чатнама суык бер төне. Ай яктысында җемелдәп яткан ап-ак кар яңа акча кебек шыгырдый. Бу шыгырдау салкын һава аша һәр тарафка шундый нык ишетелә иде ки, гүя бүген бөтен авыл икеәллык хезмәт хакын алган да, сөенә-сөенә, акча санау белән шөгыльләнә. Кызганычка, гап-гади кар шыгырдавы гына инде бу. Әнә авыл башыннан, җырлый-җырлый, ике кеше

кайтып килә. Бер-берсен бүлдереп, кычкыра-кычкыра сөйләшеп кайтуларыннан, аларның шактый исерек икәннәрен аңларга була. Һәр тарафта, һау-һау килеп, этләр өрә, этләрнең кинәт болай шау-шу куптаруларыннан котлары алынган мәчеләр багана башына үрмәли. Йортларда ут бер кабына, бер сүнә. Клубта кино күрсәтмиләр, артистларның инде күптән килгәне юк, яшьләр дә кичләрен гармун шыңгырдатып йөрми. Шуңа күрә мондый кызыкны берәүнең дә ычкындырасы килмәде, барысының да күзе тәрәзәдә булды.

Исерек дигәннән, әйдәгез, иң әүвәле алар белән танышып алыйк. Берсе аның өстенә кыйммәтле тун, башына чәшке бүрек кигән, аркасына иске мылтык асканы — Иблис, икенчесе — үзенең иске бишмәте белән колаксыз иске бүрегеннән башка яшь алмаучы Җәмил карт. Юк, Иблис дип мин шаяртмадым. Аның белән, чыннан да, Иблис үзе кочаклашып бара.

Капка төпләренә килеп җиткәч, Җәмил карт Иблисне суырып үпте.

— Син миңа ошыйсың, бр-рат! Кем син?

Теге читенсенеп кенә җавап бирә:

— Иблис мин, туган, Иблис!

Җәмил, гаҗәпләнеп, бүреген тагын да батырып куйды.

— Менә бу исем ичмаса! Мин сине яратам. — Ул Иблисне тагын кочаклап үпте. — Безнең күршедә Трактор да бар. Быел илле яшен тутырды. Узган айда түбән очта Ваучер да туды. Кайсы авылныкы син? Чурайданмы, Мултаннанмы? Юк, безнең якныкы түгел син! «К»ны нечкәртеп әйтәсең. Чистай мишәре мәллә?

Иблис мут елмаеп әйтте:

— Мишәр түгел мин, туп-туры тәмугның үзеннән килдем. Командировка!

— Ә-ә. — Җәмил карт аны шаярта дип уйлады булса кирәк, һәм җиңеннән өстерәде. — Киттек, кызык итик әле хатынны, пәриләр барына ышанмый иде ул.

Тәмуг кунагының хәтере калды.

— Ничек инде ышанмый? Минем барлыгыма ышанмыймы? Ышандырабыз без аны, кирәк булса! Киттек!

Капкадан кереп, болдыр янына килеп баскач, Иблис сак кына сорап куйды:

— Хатының явыз түгелме?

— Явыз булмаган кая, уклау белән менә болай гына кундыра. — Җәмил карт, мавыгып китеп, ялгыш кына тегенең танавына китереп сукты.

Иблис карга мәтәлде, чәпке бүреге читкә тәгәрәп китте.

— Син мине кыйнарга алып кайттыңмыни? — диде ул, елак тавыш белән.

— Гафу ит, бр-рат, сугам дип сукмаган идем. — Җәмил карт, Иблиснең мөгезен күреп, аны капшарга керешә. — Нәрсә бу?

— Нәрсә булсын, мөгез, кәнишне. Шуның белән генә сөзәм мин кире бәндәләрне.

— Алай икә-ән... Хатының утырттымы?

— Тумыштан ук бар инде ул миндә.

— Шулай, шулай, тумас борын куя хәзер яшьләр мөгезне. Безнең баш агрономның да шундый мөгезе бар. Бер генә түгел, берничә. Хатыны көн дә берне куеп тора. Бичараның башы инде бүреккә сыймый башлады. Шаяртмыйча гына әйт әле, кем син?

Иблис, үпкәләп, авызын турсайтты:

— Син миңа ышанмыйсыңмыни? Әйттем ич, Иблис дип!

— Ышанам, нигә ышанмаска, оча торган тәлинкәләр барлыгына да ышанам, хәзер бөтен нәрсәгә дә ышанырга була. — Хуҗа кеше йодрыгы белән ишек дөбердәтә башлады. — Мәчтүрә, ишекне ач, мин бу!

Ишек артында хатын-кыз сукранганы ишетелде:

— Тагын исергән, чукынчык! Ачмыйм! Әнә мунчада йокла! Сагынгандыр инде пәриләрең!

Карт, авыр сулап, болдыр баскычына килеп утырды да Иблискә сүз катты:

— Бар, утын алып кил! Мунча ягабыз хәзер.

Теге, берни дә аңышмыйча, колагын якынрак китереп куйды:

— Нәрсә алып кил дисең?

— Утын, дим, тәмуг сарыгы!

— Нәрсә соң ул?

— Көләсең мәллә? — диде карт, ачуы чыгып. — Тегендәге әтрәк-әләмнәрне казанда кайнатканда нәрсә ягасың?

— Газ.

— Шыттырасың, газ сезгә түгел, безгә дә күптән түгел генә керә башлады әле. Безнең йортка кадәр килеп җиттеләр дә, фәлән юк, төгән юк, дип туктап калдылар. Брежнев исән булса, мич башында гына ятасы кеше идем мин. Әйткән диләр аны, мин үлеп бер биш ел узгач, артымны үбәрсез әле, дип. Ә без аны, давай, хурларга, мыскылларга.

Аны игътибар белән тыңлаганнан соң, Иблис моңсу гына әйтте:

— Коммунистлар властьта вакытта, мин дә мондый ятим түгел идем.

— Син менә хәзер Брежневның артын үбәр идеңме?

— Үбәр идем. Кайда ул? Китер аны монда! Хәзер үк үбәм! — Тәмуг кисәве Җәмилнең битен үбеп алды. — Тфү! Ә битен үпмәс идем. Теләсә кем белән үбешә иде бит ул, заразы!

Җәмил карт инде хыял диңгезендә йөзә:

— Сездә газ ягалар, дисең, алайса?

— Таптың шаккатырлык нәрсә. Африкадагы кебек буздә, малай. Йөрисең шунда казаннар арасында, негр кебек.

— Алдашасыңдыр син, брат.

— Валлаһидыр, таллаһидыр, агайне! — Иблис чукынып куйды. — Ә хәмер елгаларының, хур кызларының исәбе-хисабы юк.

Җәмил куен кесәсеннән чәкүшкә белән стакан чыгарып куйды.

— Кил, утыр, бераз эчәкләреңне җылытып ал.

Тәмуг кунагы, мылтыгын баскыч баганасына терәп, аның янына килеп утырды.

— Син нәрсә, керәшен мәллә? — диде карт, стаканны Иблискә сузып.

— Нигә шулай дисең?

— Чукынганга әйтәм.

— Ә-ә... — Иблис бүтән анык кына берни дә әйтмәде.

— Ярый, урыс ни, керәшен ни, миңа барыбер. Иннокентий дип эндәшсәм, үпкәләмәссеңме?

— Эндәш сана, начар исем түгел бит. — Салкын аракыны эчеп куйгач, Иннокентий калтырый ук башлады. — С-суы-ык!

Җәмил карт көлде генә:

— Сездә җылы дисең инде, ә?

— Җ-җылы, би-ик ж-җылы!

— Казаннарга су кайдан агызасыз?

— Краннан.

— Рәхәт яшисез икән. Ыслышуй, таныш-белешлек белән генә миңа да шуннан су кертеп булмыймы?

— Өч көнлек дөнья мәшәкатьләре белән башыңны катырма, агайне. Син алгарак карап яшәргә өйрән. Безгә килгәч тә рәхәтләнерсең әле суга. Аерым җиз казанга салырбыз үзеңне.

— Теләгең изге икән, — диде карт, каш астыннан карап. — Мин инде ничек тә булса күктә урын табарга тырышырмын, Иннокентий.

Ишектә иңнәренә иске шәл салган хуҗабикә күренде. Тыңлап торган, димәк.

— Ачуланма инде, хатын. — Җәмил бу сүзләрне йомшак, назлы итеп әйтергә тырышты. Ләкин исереклек үзе үк дорфа бит инде ул, тавыш барыбер бөердән чыга. — Хәзер мин сине Иблиснең үзе белән таныштырам! Бүген урамда таныштык.

Мәчтүрә, Иннокентийны күздән кичереп, каһкаһә белән әйтте:

— Охшаган, би-ик охшаган! Ә син Хозер Ильяс инде, име?!

Җәмил күкрәген киерде.

— Нәрсә, охшамаган мәллә? Кеше талаганым юк, эчсәм дә, чистны яшим!

— Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла!

Җәмил шундук Иннокентийның колагына пышылдады:

— Утчыствың ничек әле синең?

— Нәрсә дисең?

— Ух, әбиеңне алгыры, бабаңның исеме ничек, дим?

— Миңа тегендә Иблис дип кенә эндәшәләр.

— Надан! — диде карт, кул селтәп. — Нишләп кенә ятасыз икән сез тәмугта! Газ, имеш!

Иренең кыланмышыннан туйган Мәчтүрә, башын чайкый-чайкый, сукраныш куйды:

— Эчә-эчә саташа башлагансың инде, исерек чирмеш!

Җәмил аңа ялвара ук башлады:

— Керт инде, хатын! Туңып үләм бит. Ант итәм менә, бүтән исен дә иснәмәячәкмен!

— И-и, тукран тәүбәсе, күпме антлар иттең бит инде-е! Юк инде. Юк, бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карый. Картлык көнемдә бер терәк булыр, дигән идем, булмады. Бәхетем киредән тегелгән, күрәсең. Нинди хатлар яза иде бит Воркутадан!.. Ярый, шул кирәк миңа, бер аягың белән кабергә баскач, кияү эзләп йөрмәссең.

Җәмил картның йөзен болыт каплагандай булды, исерек булса да, хатынының сүзләрен бик авыр кабул итте ул. Шулай да җавапсыз кала торганнардан түгел, әйтәсе сүзен әйтте:

— Син дә шул ук оялчан, иште, назлы Мәчтүрә булыш тоела идең хатларыңда. Болай мунчада йоклатып интектерәсеңне белсәм, эземне дә басмый идем авылга.

— И-и, әшәке җан, мәктәптә укыганда ук өмет өзгәннәр иде бит инде синнән!

— Арттырасың, хатын, арттырасың.

— Нигә, дөрес түгелмени? Укытучы Хәмит абыйны мәчеткә кем бикләде?

Җәмил, елмаеп, дүртенче класста ук булган вакыйганы Иннокентийга сөйли башлады:

— Хәмит абый чәчемне кыркымакчы иде, мин качтым. Ә ул, давай, минем арттан. Мәчеткә кадәр куып барды. Ә мин бик тере малай идем ул чакта. Ишек артында качып калдым да шалт тегене йозакка!

Бер кулын Сталинградта өздергән иде, мәрхүм. Иртән бирер инде кирәкне дип куркып кына килдем мәктәпкә. Юк, тырнак белән дә кагылмады. Тик чәчне барыбер кыркыды. Озын чәч үстерергә рөхсәт итмиләр иде ул чакта. Нигә кирәк булгандыр инде миңа ул чәч, белмим. Аннары үз бүлмәсенә алып кереп, кызыл билле прәннек белән сыйлады. Тәмле булды инде. Сугыш вакыты бит, күргән нәрсә түгел.

Мәчтүрә елмайгандай итеп әйтте:

— Әле аларын да хәтерлисең икән.

— И көнләштегез инде миннән! — диде Җәмил, аны котыртып.

— Көнләшмәскә ни, андый прәннек безгә бәйрәм көннәрдә генә эләгә иде ич. — Карчык авыр сулап куйды. — Ач заманнар булса да, тәртип бар иде ул чакта. Авылда исерекләр булмады, булганы да синең кебек үрмәләп йөрмәде.

— Шулаймыни? — диде Иблис гаҗәпләнеп. — Ә мин кайда булдым икән ул чакта?

Җәмил карт аны ишетмәде. Күңелен яшьлек хатирәләре биләп алган иде.

— Карчык, син бит Кәбиреңне мәктәптә укыганда ук ярата идең, әйеме?

— Кит, ул чакта нинди ярату булсын ди? — диде Мәчтүрә оялып.

— Ярата идең, ярата идең, — диде карт, бармак селкеп. — Үчекләп тә йөрделәр әле үзегезне.

Карчык тагын авыр сулап куйды.

— Үчекләсәләр дә, үчекләмәсәләр дә, барысы да үткәндә калды инде, картым. Кайтмады Кәбир, Сталинградта һәлак булды.

— Кайтмады шул, кайтмады-ы, — диде Җәмил карт, кайгылы чырай ясап. — Җиде йөздән артык сөлектәй таза ир кайтмады.

Аннары моңсу тынлык урнашты.

— Карчык, мин бит сине яратам, — диде Җәмил, күңеле тулып.

— Күрсәттең инде ятратканыңны. — Мәчтүрәнең дә тавышы калтырап куйды. — Яраткан кеше болай кыланмый ул. Эчмәгән көнең бик сирәк, күршеләрдән оялыр идең, ичмаса.

— Мин дә яратам! — Исерүдән башы эшләми башлаган Иблис, хисләнеп китеп, Мәчтүрәне үпмәкче булды. Ләкин Җәмил аны шундук карга төртеп екты.

— Тик тор, тәмуг кисәве, әйләндереп җибәрмәгәем тагын!

— Гафу ит, агайне, — диде күзләре кылыйланган Иннокентий һәм, үрмәләп килеп, янә болдыр баскычына кунаклады.

Җәмил, аның дөньяда барлыгын онытып, хатынына мәхәббәттә аңлаша башлады:

— Яратам мин сине, аппагым, яратам! Төрмәдән чыгып, авылга кайтуга ук тәкъдим ясарга уйлаган идем мин сиңа, тик ул һаман Кәбирне кәтә диючеләр булгач кына җөрьәт итмәдем. Аннары син кем идең дә, мин кем идем ул чакта? Син — коммунист, агитатор, активистка, ә мин...

Мәчтүрәнең күзләре яшьләнде.

— Җитте, картым, җитте. Ул чакларны искә төшерсәм, йөрәк авырта башлый. Кер әйдә!

Инде барысы да җайланды кебек, ләкин ул арада телгә янә шайтан суы хуҗа була. Җәмилдә тагын кирелек уянды.

— Кермим әле менә, — диде ул вәкарь белән. — Мин мунчада йоклыйм. Туңып үләм шунда!

Хуҗабикә ишекне шап итеп ябып кереп киткәч, Иннокентий борын астыннан гына мыгырдап куйды:

— Юләр син, агайне!

— Ие, юләрнең дә юләре икән шул, — диде Җәмил, акылына килеп. — Хәзер, чыннан да, мунчада йокларга туры килә инде.

Иннокентий, утырган җиреннән көч-хәл белән торып, баскыч баганасына терәтелгән мылтыкны аркасына асып куйды да калтырана-калтырана әйтте:

— Ки... киттек му... мунчага!

Җәмилгә мылтык бик таныш булып тоелды.

— Каян алдың бу нәмәрсәне? — диде ул, күзләрен чекерәйтеп. Аннары эчтән генә уйлап куйды: «Бик мут күренә бу Иннокентий, бер-бер карак булып чыкмагае». — Кытай Мансурының мылтыгы ич бу!

Иблис гаҗәпләнеп сорап куйды:

— Каян белдең?

— Белмәскә ни, безнең авылда мылтык бер анда гына ич. Бабасыннан — гражданкадан калган мылтык. Элек аны Чыпчык Мансуры дип йөрттеләр. Аракы эчсә, чыпчыкларны чүпли башлый иде. Мин чыпчыкныкы түгел, бүреләрнеке мин, дип гаярьләнә. Әүвәле аның нәселен, чыннан да, бүренекеләр дип йөрткәннәр бугай. Менә шул революционер бабасыннан башланган инде чыпчыклар нәселе. Бүтәкә кадәр генә булса да, күгәргән мылтыгы белән бөтен авылны дер селкетеп торган. Бәләкәй кеше явыз була бит ул. Батрактан сразу авыл сәвите итеп куйганнар тегене. Мансурында да, йөз грамм кабуга, бабасы каны уяна. Кошлардан издевательства өчен утыртып та караганнар үзен, юк, барыбер үзенекен итте. Авылдагы бөтен чыпчыкларны кырып бетермичә туктамады. Шуннан бирле моңа Кытай Шпионы дигән кушамат тагылып калды. Ул елларда Кытайда культур революция бара иде ич. Анда да чыпчыкларны бик каты кырдылар.

— Булды андый заманнар, булды, — дип елмайды Иннокентий.

Җәмил карт кинәт сагаеп калды.

— Тукта, син каян белдең әле анда мылтык барын?

— Белмәскә ни, көздән бирле аулап йөрим ич үзен. Тәмугта янсам янам, тюцаны барыбер атып үтерәм, дип кычкырып йөрдейөрде дә, үтермәде. Ә мин тиле, ышанып, аңа тәмугта иң кайнар, иң зур казанны сайлап куйган идем. Шул Кытай Шпионы аркасында план да үтәлмичә калды. Тегеләй дә өйрәтәм, болай да котыртам, юк, һич кенә дә тәвәккәлли алмый. Соңыннан бу, киек казлар дип, су буенда кеше казларын атып йөрде. Хәзер менә, рәхәтләнеп кайнар казанда ятасы урында, сары йортта ята.

— Бер генә ятуы түгел инде. — Җәмил карт, кул селтәп, махра кабызды. — Соңгы тапкыр чыкканында шәһәргә барып, коммунистлыкка язылган иде. Кызыл көннәрдә түбәгә менеп баса да «Интернационал»ны җырлый башлый.

Шул мәлне авылның икенче башында берәүнең «Интернационал» җырлаганы ишетелде:

Кузгал, уян, ләгънәт ителгән
Коллар һәм ачлар дөньясы!..

Җәмил кеткелдәп көлеп җибәрде.

— Ишеттеңме? Тагын кайтып җиткән. Аның тавышы бу. Бабасы бик идейный кеше иде. Дөрес булса, Смульныйда Ленинның үзе белән кул биреп күрешкән, диләр.

— Булмас, — диде Иблис, вәкарь белән. — Минем андый кеше белән күрешкәнем юк.

— Синең турыда сүз бармый бит әле, Ленин белән күрешкән, дим мин сиңа.

— Ә син мине кем дип белдең? — Иннокентий ишегалды уртасына басты, бер кулын кесәсенә тыкты да, икенчесен югарыга күтәреп, бөек юлбашчы рәвешен китерде. — Товалищи матлосы и клестьяне!.. Таныдыңмы инде?

Алай карады карт, болай да карады, аптырагач, башын кашып әйтте:

— Охшаган да, охшамаган да. Тукта, портретын алып чыгыйм әле.

Җәмил мунчага кереп китте. Иблис, ничек басып торса, шулай басып тора бирде. Әртистлек талантын күрсәтергә теләпме, инде Брежнев булып сөйли:

— Дорогие товарищи, прежде всего, позвольте выразить чувство высокой благодарности за вашу...

Ул арада култык астына Ленин портретын кыстырган Җәмил карт пәйда булды. Мөкиббән китеп, тегене күзәтә.

— Ну әртист! Хәзер Брижнив булдың инде, ә?

— Ә нигә булмаска? — диде Иннокентий, эшлекле кыяфәт белән тамак кырып. — Йә, ничек анда портретта?

Җәмил, бер портретка, бер аңа карап, өйрәтергә тотынды:

— Кулыңны югарырак күтәр... Булды... Хәзер күкрәгеңне алгарак чыгар... Менә шулай... Вәт, хәзер коеп куйган юлбашчы булдың инде. Юк, барыбер нидер җитеп бетми.

Шул мәлне мунчадан чын Ленин килеп чыкты! Ике кулы да, нәкъ портреттагыча, кесәдә, йөзе җитди, хәтта ачулы дип әйтергә мөмкин. Иблис тирәли бер-ике тапкыр әйләнде дә, аның күтенә тибеп, Җәмилдән портретны тартып алды.

— Күтеңне туңкайтма, иптәш! — диде ул, теш арасыннан сыгып. — Хәер, революция ясагач, барыбер туңкайтырга туры киләчәк.

Юлбашчы янә мунчага кереп китте. Тегеләр икесе дә шаккатып басып тора бирде.

Бераздан Җәмил пышылдап кына сорап куйды:

— Кем булды бу?

Иблис тә кычкырып сөйләшергә базмады, чак кына ишетелердәй итеп әйтте:

— Үзе!

— Охшаган, бик охшаган.

Иннокентий куркыш кына мунча ишеге янына килде, башын эчкә тыгып карады.

Юлбашчыга дәшә:

— Иптәш Ленин! Иптәш Лени-ин!

— Да, брат, власть алмашына бугай, — диде Җәмил карт, башын чайкап. — Теге тиле бүген юкка гына «Интернационал»-ны җырламаган икән. Капкага тизрәк кызыл әләм элеп куярга кирәк.

— Аны хәзер генә каян табасың? — Шулай диде дә Иблис, сагаеп, бармагын ирененә куйды. — Тс-с!

Авылның икенче башында янә җырлаган тавыш ишетелде:

Җимерик дисәң коллык, җәберне,
Яулыйк дисәң син барын да,
Дөрләт утны, тизрәк тимерне
Сугып кал утлы чагында.

Иблискә шул гына кирәк тә, куен кесәсендәге блокнотны ботарлады да, аны ишек төбенә куеп, шырпы белән ут төртте. Моны күреп, Җәмил яна башлаган кәгазьләрне тибеп очырды һәм, сүгенә-сүгенә, тегенең танавына китереп сукты.

— Нишләвең бу синең, мәлгунь?!

Иблис, шыңшып, читкә барып утырды.

— Соң, учак дөрләтегез, ди ич!

— Дөрләтермен мин сиңа, анаңны еккан нәрсә!

— Чү! Кызма әле син, туган, — диде Иннокентий, аны юмалап. — Кызыл әләм элеп куярга кирәк капкага.

Җәмил әләм артыннан мунчага кереп киткәч, ул, Ленинча кыланып, бер кулы белән бөеренә таянды.

— Һаман да таң атмаган икән әле бу Рәсәйдә, — диде ул, тел шартлатып. — Нигә шулай бик караңгы монда, ә?

Бераздан, мунчадан кеше башы сөяге төшерелгән кара әләм күтәреп, Җәмил килеп чыкты.

— Анархистлар байрагы ич бу! — диде Иннокентий, йөзен сытып.

— Тфү! — Җәмил карт янә мунчага юл тотты.

Ә тәмуг кунагы, мылтыгын аркасына асып, инде маршировать итә:

— Ать-два, ать-два...
Дошманга каршы сугышка
Ленин чакырган безне.
Татбригада атка менде
Сакларга илебезне.
Ать-два, ать-два...

Җәмил карт озак тормады, мунчадан чыккан уңайга, кулындагы кызыл әләмне югары күтәреп, Иблис белән маршировать итә башлады:

— Ать-два, ать-два...

Ниһаять, тавышка уянып, Мәчтүрә карчык килеп чыкты.

— Нәрсә, революция башланды мәллә? — дип кычкырды ул, исерекләрне оялтырга теләп.

Җәмил белән Иннокентий һаман маршировать итүләрен беләләр:

— Чык, хатын, иреңне сугышка озатасың хәзер!

Мәчтүрә куркып калды. Ул йоклап ятканда, радиодан берәр яман хәбәр бирүләре дә ихтимал бит.

— Һай Ходаем, ул нинди сугыш тагын?

— Безнең сугыш, хатын. Ленин терелде. Президент бәреп төшерелде. Ать-два, ать-два... Хәзер председательнең калхузны талап салган өч катлы коттеджын тартып алабыз, аннары...

Мәчтүрә, болар аракы эчеп юләрләнә башлаганнар дип уйлап, сукранырга тотынды:

— Тиле дип уйлаган идем мин сине, тик мондый ук шыр тиле дип белмәгән идем!

Революция белән тәмам мавыгып киткән Җәмил аны ишетмәде, терсәге белән кабыргасына төртә-төртә, Иннокентийны өйрәтүен белде:

— Турырак атла, тәмуг сарыгы!.. Ать-два, ать-два... Менә шулай!

Аннары Җәмил янә Мәчтүрәгә дәште:

— Ышанмасаң, хатын, әнә мунчага кереп кара, анда Ленин үзе утыра. Атакыны шушыннан башлыйбыз, диде. Бар, бар, күзеңне акайтып торма, кереп хәлен бел. Партбилетым һаман да матрас астында, сине бер генә минутка да онытып тормадык. Хрущев, Горбач, Ельцин вакытларында да би-ик идейный кешеләр булып калдык, диген. Гомерең буе китапханәдә эшләп җыйган теге хәерче мең сумыңны кассада яндырган Гайдарны нишләтәбез дип сора!

Тамаша күпме дәвам итәр иде, белмим, әмма әтәч кычкырып җибәргәч, Иннокентий җиргә сузылып ятты.

— Нәрсә, һава һөҗүме башланды мәллә? — диде Җәмил аптырап.

Иблис тотлыга-тотлыга әйтте:

— Ә-әтәч кычкыра.

— Кычкырса соң?

— Кайтып китим мин булмаса, агайне. — Курыккан Иннокентийның тавышы бик мескен чыга.

Җәмил аны шундук якасыннан өстерәп торгызды, сүгенә-сүгенә яңакларга кереште:

— Тор, анаңны еккан нәрсә! Революция башланмас борын качарга җыенасыңмы?! Дезертир!

Ачуы чыккан Иблис тырнакларын аның бугазына батырды:

— Кычкырма, карт тиле, бөтен авылны аякка бастырасың бит!

Җәмил инде ярдәм сорап акыра:

— Иптәш Лени-и-ин, революцияне буала-ар!

Иннокентий җиргә төртеп еккач кына тынды карт. Аннары торып, өстендәге карны каккалый-каккалый, гасабилы тавыш белән мыгырдап куйды:

— Бар, кит, көчләп тотмыйм! Түлке, кара аны, мылтыгыңны миңа биреп калдырасың!

Тәмуг сарыгы мылтыкны Җәмилгә сузды:

— Мә, сагынганда шуңа карап искә алырсың. Тик миннән башка бу революция җиңеп чыга алмаячак.

Коралны кулына алуга, Җәмил көпшәне Иблиснең корсагына терәде:

— Революцияне сатмакчы булдыңмы?! Киттек мунчага — Ленин янына!

— Нишләтмәкче буласың? — Иннокентий мылтыкны биргәненә үкенеп куйды. Ышанасың икән бу картка, ике дә уйламыйча чакмага басачак.

— Анысын революцион трибунал хәл итәр, иптәш дезертир!

Трибунал дигән сүзне ишеткәч, Иннокентий, ычкынып китеп, акыра ук башлады:

— Кем, минме дезертир?! Бик беләсең килсә, мин — коммунист, мин — Социалистик Хезмәт Герое! Ә син кем?! У-у, деревня!.. Колхоз!

— Күтәр кулыңны!..

Иннокентий тагын да катырак әйтмәкче булган иде, ләкин картның акайган күзләрен күргәч, буйсынырга булып, кулларын өскә күтәрде.

— Менә шулай, — диде Җәмил. — Ә хәзер мунчага юл тотыйк.

— Ярый, исән булсак, бер күрешербез әле, агайне. Мин сине кыямәт көнгә тикле казанда кайнатачакмын! — Иннокентийның йөзе бер агарды, бер яшелләнде.

— Атлавыңны бел!

Шул мәлне революция каһарманының кулына күктән кәгазь бите килеп төште. Ашыгыч телеграмма иде бу. Җәмил, як-якка шикләнүле караш ташлап, укырга тотынды.

*«Иптәш Әлмиев!*

*Сез иң булдыклы агентны кулга алгансыз. Аны кичекмәстән ирекә чыгарырга әмер бирәм.*

*Мәскәү, ВЧК, Дзержинский, 1919».*

Телеграммага Иблис тә күз салып өлгергән иде.

— Ышандыңмы инде минем важный кеше булуыма? — диде ул, тантана итеп.

Җәмил, һичбер нәрсә аңламыйча, колак артын кашып куйды.

— Тукта, тукта, нигә унтугызынчы ел әле ул?
— Сиңа барыбер түгелмени? ВЧК дип куелганмы?
— Куелган.
— Пичәте бармы?
— Бар.
— Шулай булгач, сиңа тагын ни кирәк?
— Соң, без ике меңенче елга кердек бит инде.
— Керсә соң, димәк, почтада озак яткан.
— Ә Әлмиеве кем?
Иблис, гасабиланып, кул гына селтәде.
— Белмим, белергә дә теләмим! Бир мылтыкны!
— Ашыкма, агайне. Трибунал башлыгының фамилиясе дер бу. Күтәр кулыңны!.. Менә шулай!.. Мунчага атла! Нишләтергә икәнен Әлмиев үзе хәл итсен.
Арестант, башын горур күтәреп, шигырь белән җавап бирде:

Без бүгеннән дошман!
Дуслыгымны саклар өчен,
Йөрәгемдә бер хис тапмадым.
Бел!
Бүгеннән соң,
Син һәм синең кебекләргә
Пуля саклап йөри башладым.

«Аңгыра булса да, Такташны яттан белә», — дип уйлады Җәмил гаҗәпләнеп.
...Мунча эче шактый иркен иде. Иннокентийның күзенә иң беренче булып түшәмдә асылынып торган кәрәчин лампасы, ләүкәдәге көмешкә куу аппараты һәм Ленин портреты чалынды. Ә юлбашчының үзеннән җилләр искән.
— Иптәш Ленин, сез кайда? — дип мыгырдады кәефе кырылган карт.
Иблискә шул гына кирәк тә.
— Кыяфәтең бик куркыныч иде бит, чыгып качкандыр, — диде ул, аны мыскыллап. — Революция, Ленин, имеш! Революцияне аны бөтен авылны аякка бастырып ясамыйлар. Шыпырт кына эшләнә андый эшләр. Синең кебек сер тотмас үрдәк белән нинди революция ясап булсын!
Җәмил аның күтенә китереп типте.
— Тавышыңны күтәрмә! Син лучшы ләүкә астын кара!
— И тинтәк, Ленин кадәр Ленин ләүкә астында качып ятармы? — дип ыжылдады Иннокентий, авырткан күтен уып.
— Утыр ләүкәгә, телеграмма килгән икән, трибунал башлыгы Әлмиевнең үзен көтәбез. Бер-бер йомышы килеп чыккандыр, хәзер кайтыр, Алла боерса.
— Белмим, малай, трибунал кадәр трибунал сыя алмас бу хәерче мунчага.

— Яхшысын үзең салырсың, гарешкә олактырмасалар, — диде Җәмил һәм ачу белән өстәп куйды. — Таладылар безне демократлар! Кассада бәдрәф салырлык та акчабызны калдырмадылар. Марш ләүкәгә!

Иннокентий каһкаһә белән әйтте:

— Чабындырмакчы буласың мәллә?

Җәмил карт, аны ләүкәгә төртеп менгерде дә, мич каршына утырып, махра кабызды. Иблис исә, исерек күз яшьләренә буылып, күкрәк төя башлады:

— Китер трибуналыңны! Мин барыбер, яшәсен революция, дип үләчәкмен! Яшәсен революция-ә!

— Акырма, базар бакасы! — Карт, чыраен сытып, мич авызына төкерде.

— Әллә җибәрәсең генәме, ә? Тәмугта юксынганнардыр инде мине. Теләсәң, сине үзем белән алам. Урынбасарым булырсың. Ятарсың шунда җен кызлары белән типтереп. Җен дигәч тә, син уйлама, бик чибәрләр алар. Бу дөньяда нинди рәхәтлек күрдең соң әле син, йә?

— Рәхәтлек күреп булмады инде, анысы хак, — дип авыр сулады Җәмил.

Иблис ләүкәгә сузылып ятты.

— Ыскучно монда, агайне. Хет гармуныңны уйнап җибәр инде. Җырлат, елат бер рәхәтләнеп, үләр алдыннан.

Ни гаҗәп, бу юлы аның үтенече җавапсыз калмады. Хуҗа ләүкә астыннан ике рәтле гармун тартып чыгарды.

— Гармун җәлке түгел, — диде ул. — Нинди җыр җырлыйсың?

— «Алмагачлар»ны җиффәрт!

Җәмил, гармунны бер-ике тапкыр шыңгырдатып алгач, уйнап җибәрде. Иблис исә, дәртләнеп, җыр сузды:

Алмагачта була, диләр,
Сандугачлар оясы.
Җир шарында нурлар сибә
Коммунизм кояшы.

Җырлап аргач, ул, көрсенеп, мыгырдап куйды:

— Их, барыбер ыскучно...

— Шыңшыма, — диде Җәмил. — Әбиеңдә кунакта түгелсеңдер. Революциягә хыянәт иткәнсең икән, җавабын да тота белергә кирәк. Фрунзе әнә, патша хөкүмәте атарга хөкем иткәч, төрмәдә француз телен өйрәнеп яткан.

— Патша йомшак булган, патша-а, — дип мыгырдады Иннокентий. — Котовскийны гына ал әнә, алты жандармны үтергән бит. Безнең заманда үтереп карале син бер милиционерны, дөньяга ник туганыңа үкенерсең. Карале, тел дигәннән, син миңа нинди тел өйрәнергә киңәш итәр идең?

— Инглиз телен, әлбәттә.

— Ә нигә инглиз телен?

— Узган ел күрше Сәлим малае университетка укырга кергән иде. Беркөнне урамда сөйләшеп тордык, тиздән бөтен җирдә инглизчә сөйләшә башлаячаклар, ди. Гәзиттә эшләүче кеше булып чыгачак, ахры.

— Журналист була, димәк. Аңа татар теле дә бик җитеп тора. Нәрсә дип язган әле берәү татар журналистының хәле турында?.. М-м... Яшим инде мин дә. Зәңгәр төтен белән тулган бүлмә. Кара диңгез күрмәгән малай дөнья турында сүз йөртә. Әйтерсең каләмем Пентагонга акыл кертә. Әйтерсең каләмем әхлак индерә җиргә. Әйтерсең сугышлар анда бетә. Әйтерсең каләмемне татар абзые көтә. Аның үз эше, ул мал асрый, көтү көтә. Әйтерсең каләм белән Казан суы чистара. Әйтерсең милләт агара.

Яшим инде мин дә... Зәңгәр төтен белән тулган бүлмә. Минзәләдә булмаган малай сәнгать турында сүз йөртә. Әйтерсең каләмем аңа зур яңалык кертә. Әйтерсең лә каләмемне Голливудлар, «Нью-Йорк Таймс»лар көтә. Маршруты: Казан — Балтач. Шуның белән сәфәр бетә.

Абзар артына да китә алмагач, ни пычагыма татар журналистына синең инглиз теле?

Иннокентийны дикъкать белән тыңлап утырган карт, баш чайкап әйтеп куйды:

— Иблис булсаң да, хак сүз сөйлисең. Заманалар үзгәрде, ә без һаман да шул ит-сөт һәм бәрәңге турында сөйләүдән, язудан ары китә алмыйбыз.

— Соң, дөнья күрмәгән бозау үз абзары турында гына яза инде. — Иннокентий пафос белән янә сөйләргә тотынды. — Бозау да ярата, диләр үз абзарын, мин яратмыйм сине, Казаным! Читлектә уза яшьлек, мәҗбүр итә заманым. Мин кош түгел, мин бер бозау, яшим инде җан биргәнче. Таң аттырып, көн уздырып, әҗәл арттан килгәнче. Аһ, туйдырдың, абзарым! Җирдә бар җылы диңгез-утраулар, бар хөрмә җимешләре, матур кошлар, зур елгалар. Бер генә тапкыр килдем бит дөньяга, ник мөкиббән мин һаман абзарга? Сорар Ходай беркөн, ниләр күрдең, ник чыкмадың дөньяларга, нигә җырлар багышладың гел абзарга, ник мәдхия кылдың бозауларга? Тамак өчен яшәп һаман гомер уза, уйлар авыр, үкси күңел, йөрәк туза. Үз илендә матур, диләр, бәрәңге бакчасы да. Ә гомер һаман уза, күпме җырлар туар тагын бәрәңге бакчасында?!

Җәмил тел шартлатып әйтте:

— Шәп, бик шәп әйтелгән!

— Нигә шундый моңсу бу дөнья, агайне, ә? Сөйләп җибәр әле үзең турында. Син бик күпне күргән кеше бугай.

— Нәрсәсен сөйлисең инде аның, безнең маршрут Казан–Балтач кына булмады инде. Егерме тугызда тудым. Гаиләдә жи-

денче бала идем. Әти, мәрхүм, яшьләй үлеп китте. Ярым ялангач, ярым ач булып үстек. Чабата да юк иде кияргә. Кырык беренче елны сугыш башланды. Алты абыемны да фронтка алып киттеләр. Кырык икедә үземне дә ФЗӨгә димләп килделәр. Ул вакытта синнән сорап тормыйлар иде, көчләп алып китәләр иде. Качтым. Өч көн Шода урманнарында адашып йөрдем. Китәсе булган шунда берәр шәһәр җиренә. Юк шул, әни сагындырды, кире кайттым, юләр. Шул көнне йортыбыз каршына, тузаннар туздырып, тарантас җигелгән ат килеп туктады. Авыл сәвите Фәизә белән комсомол секретаре Рәхим мине алырга килгәннәр. Тарантаска бәйләп ташладылар да туп-туры Казанга!

ФЗӨдән тагын качтым. Ундүрт яшьлек сабый гына бит әле. Арчага кадәр кайтып җиттем җитүен. Анда тагын эләктерделәр. Колония тормышы башланды. Төрле балалар бар иде, әшәкесе, әйбәте дигәндәй.

Беркөнне аннан да качтым. Шуннан соң барысы да чуртыма тәгәрәде. Юлымда домушниклар белән очраштым. Бер төндә алты кибет бастык. Җиденчесендә эләктерделәр. Шуннан бирле гел зәңгәр тәрәзәле йортым, әнием төшкә кереп интектерде. Ничә еллар узды, һаман да шул бер төшне күрәм, агайне.

Төрмәдән чыккач, авылга кайттым. Әни инде дөньяда юк, сугышка киткән абыйларым исән кайта алмады, тәрәзәләргә аркылы-торкылы такта кадакланган.

Авыл сәвите Фәизәне фронтовик абыйсы, кеше канын җитәрлек эчкәнсең инде дип, бик каты чыбыркылап, кычыткан арасына ыргыткан, дип сөйләделәр. Хурлыгыннан авылдан ук чыгып сызган, хәсис. Бик кабих адәм иде, бөтен авылны калтыратып тотты. Басудан кайтканда, хатын-кызларның ыштаннарына кадәр тикшерә иде. Җиде балалы Хәлимә апаны бер уч борчак өчен биш елга төрмәгә утыртты, мөртәт. Кире кайтмады Хәлимә апа, шунда үлеп калды. Район үзәгеннән килгән бөтен налуг инспекторлары гел шул Фәизә йортында куныш ята иде. Төнлә урамга чыксаң, аның чыкылдаганы ишетелә. Тагын бик әшәке ике бригадир хатын бар иде әле безнең авылда. Кызыл бәйрәмнәрдә башларына бүрек, өсләренә телогрейка, күтләренә сырган ыштан киеп, урам буйлап гармун уйнап йөриләр иде. Менә шулар булды инде авылның беренче исерекләре. Алла бар ул, икесенең дә башы төрмәдә бетте. Бәрәңге үзләштереп эләктеләр. Тик менә Фәизәгә генә талак та булмады. Казанда яши хәзер. Дөрес булса, бер муллага кияүгә чыгып, мәчеттә абыстай булып йөри, ди. Мулла дигәннәре дә сугыш елларында безнең авылга налуг инспекторы булып килгәләгән кеше икән, дип сөйләделәр.

Авылда каласы килмәде. Йортны берәүгә шалкан бәясенә генә саттым да киттем Воркутаякларына. Пенсиягә кадәр шахтада эшләдем. Уемда туган авыл да Мәчтүрә генә иде. Бервакыт, ни булса да шул булыр дип, аңа хат яздым. Озак көттермәде, җавап

хаты язды. Бергә яшәргә риза, дигән. Ул чакта дөнья инде шактый болгана башлаган иде. Фатирымны ташлап кайтырга туры килде. Себер ягы бит, алыштырып булмады. Гомерем буе бөртекләп җыйган ничәмә-ничә мең сум акчам да кычкырып янды кассада. Авылга кайткач, нарат бүрәнәләрдән зур йорт салырмын, Мәчтүрә белән картлык көнендә генә булса да бәхетле көннәр кичерермен, алма бакчасы булдырырбыз, умартачылык белән шөгыльләнермен, дип хыялланган идем, юләр. Хәзер инде бернәрсәгә дә күңел үсми. Бердәнбер юаныч — урыс әчесендә генә.

Аны тыңлап бетергәч, Иблис тамак кырып әйтте:

— Аллаһы нәрсә дигән әле үзенең хәдисләрендә?.. М-м... Байлыкка табынма, кош кебек яшә, аягыңны сузган чакта бернәрсәне дә үзең белән алып китә алмассың. Шулай булгач, бер дә борчылма, агайне.

Шыгырдап ишек ачылды. Ни күрсеннәр, ишектә тагын Юлбашчы басып тора!

Җәмил, җәһәт кенә сикереп торды да, мылтыкны кулына алып, үрә катып калды. Юлбашчыга бу ошады, елмаеп, аңа кулын сузды:

— Исәнмесез, иптәш!

— Здравия желаю, иптәш Ленин!

— Тамагыгыз тукмы?

— Бик тук түгел инде, шулай да түзәрбез.

— Борчылмагыз, барысы да тәртип булыр, бу юлы без башка юлдан китәрбез! — диде Юлбашчы, бөеренә таянып.

— Нинди юлдан ул, иптәш Ленин?

— Урта Азия аша туп-туры Һиндстанга!

— Анда нәрсә эшлибез?

Шул мәлне Иблис теш арасыннан гына сыгып куйды:

— Нәрсә булсын, Һинд океанында күн итек юабыз инде.

Һичбер нәрсә аңламаган Җәмилнең күзләре челт-челт итеп йомылып алды.

— Монда гына юып булмыймы соң аны?

— Мин сезнең тел төбегезне аңладым, — диде Юлбашчы. — Чечняда юдык, монда да юарбыз, Алла боерса! Шәп итеп юарбыз!

Җәмил тагын нindидер сорау бирмәкче булган иде, өлгермәде, Юлбашчы, кесә сәгатенә күз салып, чыгу юлына борылды.

— Соңга калам икән, Надюша чәй куйган иде. Сау булып торыгыз, бераздан мин яңадан керермен.

Юлбашчы чыгып китте. Җәмил, трибунал башлыгын искә төшереп, аның артыннан ук ишеккә ташланды.

— Иптәш Ленин!

Юлбашчы капкадан гына чыгып бара иде әле.

— Нәрсә булды?

— Иптәш Әлмиев кайчан килеп җитәр икән?

— Тиз генә булмас. Ул Ильцинның әмере белән Мәскәүдә Югары Совет депутатларын тупка тота. Аңа нинди йомышыгыз бар?

— Мунчада бер тәмуг кисәве трибунал көтеп ята.

— Килегез әле бирегә.

Җәмил йөгереп килүгә, Юлбашчы аның колагына пышылдады:

— Патрон әрәм итмәгез, асарга гына тырышыгыз!

— Аңладым, бик аңладым, иптәш Ленин!

Мылтыклы кеше мунчага кергәч, Иблис вәкарь белән сорап куйды:

— Куып җиттеңме?

— Җиттем, — диде Җәмил карт.

— Нәрсә ди?

— Трибунал башлыгын сораган идем, Мәскәүдә депутатларны тупка тотып ята икән. Ә сине атарга киңәш итмәде.

— Менә күрдеңме? — дип кычкырып җибәрде Иннокентий. — Үз туганын ничек аттырсын ди ул?

Җәмил күзләрен акайтты.

— Асарга кушты ул сине, вәт! Патруныңны эканумияләү, бау белән генә матап, әле Кыпкы Сарайны аласы бар, ди.

Коты очкан Иннокентий илереп акыра башлады:

— Үтерәлә-әр!

— Акырма, анаңны саткан нәрсә! — дип ыжылдады Җәмил. — Хәзер үк үтерергә җыенган кеше юк бит әле сине.

Теге тагын да катырак бакыра:

— Җәзаларга җыенасың, ызначит?! Яшәсен революция-ә!

Аптырагач, Җәмил мылтык түтәсе белән кизәнде.

— Әнәк эте сыман шыңшып ятма. Монда синнән башка да ми кайный, — диде дә ул, ишек бусагасына утырып, үзалдына сөйләнә башлады. — Ошамый әле бу миңа. Һиндстанга кадәр барып итек юып йөрергә тинтәк түгел ич мин. Ну ахмак та икән бу Ленин!

— Унҗиденче елдагысы мондый ук ахмак түгел иде, — дип чыелдады Иннокентий. — Ә бусы шыр тиле. Кичә телевизордан чыгыш ясаган иде…

Җәмилнең авызы ачылып калды.

— Шулай дидеме?

Иннокентий авызын мыскыллы кыйшайтып әйтте:

— Шулай диде шу-ул! Берәү генә түгел хәзер бездә юлбашчылар. Кайсысын гына алма, барысы да Ленин. Берсе әнә Чечняда итек юып караган иде, хәзер юынудан башы чыкмый. Җибәр мине! Юкса кара аны, бөтен гомереңитек юып узачак!

— Ярый, хәзергә син ирекле, — диде карт. — Ләкин трибунал башлыгы килеп җиткәнче, мунчадан бер адым да атламыйсың!

Иннокентийга шул гына кирәк тә, бау ярып кергән беләкләрен уа-уа, ләүкәдән сикереп төште дә биергә тотынды:

— Быр-р-р, с-суы-ык!

Шулай биеп торган булды да тәмуг кисәве сизмәгәндә генә Җәмилнең аркасына менеп атланды.

— Эләктеңме? — дип кычкырды ул, әче тавыш чыгарып. — Хәзер барысы да мин әйткәнчә булачак инде!

Җәмил берни дә майтара алмады, муенга чытырдап ябышкан, каһәр.

— Төш өстән! Бу тиленәр илендә синнән башка да җилкәдә утыручылар күп.

— Син гарешкә ашканчы утырам әле мин монда, аннары күз күрер.

— Озаккарак китә икән, — диде карт сукранып. — Кара, син бит әле мине урынбасарың итмәкче идең.

Иблис җавапны таба белә, вәкарь белән генә картка әйтте:

— Итмәкче идем дә, киресен уйладым хәзер. Урынбасарларым болай да җитәрлек минем. Сталин, Берия, Вышинский, Ягода... Күп инде, күп, санарга бик озак.

— Урынбасарларың күп булгач, эш тә калмагандыр инде үзеңә?

— Эш җитәрлек, — диде Иннокентий. — Якты дөньяга чыгыш, илбашларының башын бутау, адәм затларын юлдан яздыру белән шөгыльләнәм мин. Күптән түгел менә КПСС тарихын өйрәнә башладым. Алдынгы тәҗрибәсез булмый, агайне. Сез мине дә уздырып җибәргәнсез кайбер гамәлләрегез белән. Прәме көнләшеп үләрлек! Рәсәй телевидениесен карау да бик ярдәм итә. Алдау дигәндә, алардан да маһир белгеч юк.

Кинәт ут сүнде. Мунча эчен караңгылык басты. Иблис Җәмилнең башына китереп сукты да галибанә тавыш белән җикеренергә кереште:

— Юри сүндердеңме утны? Кабыз хәзер үк!

Карт, тәмуг кунагын каһәрли-каһәрли, кәрәчин лампасын кабызды.

— Әшәке җан син, Иннокентий!

Тегенең ачуы чыкты.

— Күп сөйләшәсең, агайне, — диде ул, тешен шыкырдатып. — Кара аны, авызыңны йоммасаң, телеңне кисеп ыргытмагаем!

Чарасыз калган карт елап җибәрде:

— Ярый, җитмеш ел түзгәнне хәзер генә түзәрбез инде.

— Түзмичә кая барасың? Тагын да катырак кыскартырбыз әле без сезнең телегезне! Хак сүз әйтә теге пеләш, Монголиядә черетергә кирәк сезне! Иртәгә үк бер почмакка икуна асып куй. Аннары сине чиркәүгә алып барып чукындырырбыз. Син — Женя, хатының Матрена булыр.

— Син буг белән дус түгел бит, ниткән чукыну ул тагы?
— Дус булмаса соң, аның каравы син дә тәре белән дус түгел ләбаса.
— Әнә тегендә берәү тора ич инде, — диде Җәмил, Ленин портретына ымлап. — Шул җитмәгәнмени?
Иблис йомшарды һәм уйчан гына тавыш белән әйтте:
— Күндерден, шул җитеп торыр, ахры.
— Кик-ри-кү-үк! — Әтәч кычкыра.
Тәмуг кисәве тагын гасабилана:
— У-у, норсыз! Сөймим шул әтәч тавышын! Киттек, әшәр итеп керик үзен!
— Бердәнбер әтәчемне дә күпсенмә инде, — дип сыкрады карт. — Мин бит синең тәмугыңа барып хуҗа булып йөрмим.
— Әллә хуҗа булыр идеңме? — Иблис тагын аның башына китереп сукты. — Чабата кайтарма, купканны үтә! Юкса...
Күнде карт, кара кайгыга батып, кетәклеккә юл алды.
Әтәч бик гаярь булып чыкты. Хуҗа эләктереп алам дигәндә, муен йонын кабартты да Иннокентийның борынына килеп кунды. И чукый, и чукый тегене!
— Үтерәлә-әр! — дип чыелдады Иблис һәм, Җәмилнең өстеннән төшеп, абына-сөртенә, кетәклектән чыгып сызды. Шунда каядыр бәрелеп, мөгезе дә шартлап сынды бичараның.
Хуҗа кеше мунчага килеп керсә, Иннокентий, ләүкәдә йөзтүбән капланып, әтәчне сүгеп елап ята:
— У-у, афәт! Чак кына күзсез калдырмады-ы! У-у, гомереӊ буе тавык күрмәгәеӊ нәрсәңә!
Җәмил көлде генә.
— Мә, бүтән ташлап йөрмә бу нәрсәңне! — диде дә мөгезне ләүкәгә томырды.
Иблис тагын да үкеребрәк елый башлады:
— У-у, бандит! У-у, үтерүче!
— Җә, үкермә шулкадәр, мунчаны агызып җибәрәсең бит! Миндә бер дигән җилем бар, ябыштырырбыз.
Шулай дигәч, Иблис торып ук утырды:
— Ябыштыр инде син, туган, ябыштыр.
— Тамбов бүресе сиңа туган, вәт! — Җәмил, сәкегә утырып, гармун шыңгырдатырга кереште.

Әтәч менгән киртәгә,
Армиягә китәргә...

— Зинһар, җырлама бу җырны! — дип үтенде Иннокентий, борын җыерып. — Әтәч дигән сүзне ишетсәм, кан басымым күтәрелә башлый.
Җәмил аңа йодрык белән янады:
— Тагын шаярырга уйласаң, беттең дип уйла. Иманыңны алам!

Тәмуг сарыгы инде йон уңаена гына сыпыра:

— Чү, агайне! Иманлы адәм буларак, син мине тәрбияләргә генә тиеш. Хәер, барыбер файдасы булмаячак. Иблис бит мин. Әнкәй, мескен, миннән тумас борын ваз кичкән, диләр.

Бераз, ух-вах килеп, елап утыргач, Иннокентий тагын шигъри дулкынга күчте:

— Гомер узган саен, чын хакыйкатьтән ерагая барам. Соң, балачак чын хыяллар иле түгелмени? Чын пакьлек, чын шатлыксөенечләр иле түгелмени? Иң эчкерсез күз яшьләре анда түгелмени? Ерагая барам хакыйкатьтән, ерагая барам. Еллар узган саен, кая барам, кая якынаям? Ихлас хисләр юк инде, ялган белән тулды дөньям. Соң, бүгенем ялган түгелмени, ялган шатлыксөенечләр түгелмени? Күз яшьләре генә чын, һәм барысы да ялган!

— Болай нечкә күңелле дә кебек инде үзең, — диде Җәмил, Иннокентийның талантына сокланып. — Гомереңне әшәкелеккә багышламаган булсаң, синнән бер дигән нәфис сүз остасы чыгар иде, валлаһи!

— Кем, минме нечкә күңелле? — диде Иннокентий, күзен акайтып. — Бик беләсең килсә, әшәкелек эшләмичә торсам, минем бөтен йокым кача. Узган ай әнә, бер сукырны трамвай юлы аша чыгарып куйгач, аны трамвай юлына бөкләп салмаганыма үкенеп, чак кына инфаркт алмадым.

— Хулиган син!

Илһамланып киткән Иннокентий шигырь белән генә җавап бирә:

— Мактасалар, мин хурланам, хурласалар, мин мактанам. Әйе, дуслар, шулай юхаланам. Минем дә бар күз яшьләрем, качып елаганым бар. И адәмнәр, сез белмисездер, ташта да бар бит ул моңнар. Юкса ярылмас иде диварлар, ишелмәс иде сарайлар. Моңы булган Җирдә гел бар! Димәк, мин — бар, димәк, мин — бар!

— Сиңа тагын моң! Бу барлыктан Алла сакласын инде барыбызны да, — диде Җәмил, черт итеп төкереп.

— Син фәлән, син төгән дип, җанымны ашамагыз, йөрәгемне кисмәгез. Шундый булып туган, шундый булып килгән җиргә фәкыйрегез. Очкычларны, корабларны үзгәртеп була, ә мине булмый. Сүтәргә уйласагыз, кире җыясыгызны уйлагыз... Җыя алмассыз шул. Шулай булгач, түзегез инде бераз, түзегез. Вакыты җиткәч, үзем китәрмен. Ишетәсезме, үзем китәрмен!

Җәмил арды булса кирәк, авызын ачып иснәнде дә, гармунны сәке астына тыгып, сузылып ятты.

— Ярый, син китә тор, ә мин бераз черем итеп алыйм. Сәгать алтыда торып фермага барасы бар.

— Ә мөгезне кем ябыштыра?

— Телең белән ябыштыр, шәп ябыша, диләр.

Иблис сынган мөгезен теле белән ялый-ялый ябыштырырга азаплана, ә Җәмил аны күз кырые белән генә күзәтеп ята. Озак маташты тәмуг сарыгы. Ниһаять, ул, үзен алдаганнарын аңлап, мөгезне ачу белән идәнгә томырды.

— И тәмуг сарыгы, тел белән әйбер ябыштырганнарын кайда күргәнең бар? — дип көлде карт.

— Соң, үзең әйттең ич. — Иблис, аңа каш астыннан гына карап, борын тартып куйды.

— Җилем белән ябыштыралар аны, ахмак!

— Алайса, чыгар җилемеңне!

— Чыгармыйм әле менә. Минем йокым килә.

— Мөгезсез килеш тәмугка ничек кайтып кермәк кирәк? — диде теге ачуланып. — Кайтмыйм, яңа мөгез үсеп җиткәнче шушында утырам!

— Утыр сана. — Җәмил, авызын ачып, тәмле генә иснәнеп куйды. — Мин синең кебек урамда җил куып йөрмим, сәгать алтыга фермага барырга кирәк.

Ул бүрәнә тарттыра башлагач, Иблис, кулларын уып, пышылдап кына шигырь сөйләргә тотынды:

— Узды язлар, җитте көзләр, урамда инде кар ява. Кемдер минем каберемдә карга таяк белән яза: «Һәм барысы да тәмам, барысы да сезгә кала».

Җәмилнең чын-чынлап йокыга киткәненә инануга ук, ул, чүгәләп, идән ярыгына кычкырды:

— Әй, сез, кәмшек танаулар! Менегез тизрәк!

Идән ярыгыннан күз дә йомганчы бер карт гыйфрит һәм ике яшь җен килеп чыкты. Кулларында — инкыйлабка кадәрге телефон.

— Тыңлыйбыз, галиҗәнап! — диде карт гыйфрит, үрә катып.

Тәмуг хуҗасы, сәкедә йоклап яткан Җәмилгә күрсәтеп, галибанә тавыш белән боерык бирде:

— Бәйләргә!

Төнге кунаклар аны ых дигәнче бәйләп ыргыттылар. Өстәвенә, кычкыра-чәбәләнә башлагач, авызына чүпрәк тә тутырып куярга туры килде.

Карт гыйфрит тагын хуҗасына мөрәҗәгать итте:

— Нишләтергә кушасыз, галиҗәнап?

— Җәзаларга!

— Тырнак суырта торган җайланма тәмугта калды, галиҗәнап.

— Булдыксызлар! Алып китегез, алайса, тизрәк тәмугка! Тик карагыз аны, иң кечкенә, иң уңайсыз, иң кайнар казанга бөкләп салыгыз үзен!

Кинәт, шыгырдап, ишек ачылды. Анда тагын Юлбашчы басып тора. Бик уңайсыз вакытка туры килде, каһәр.

— Тфү, тфү! — диде ул, күзләрен уып. — Бу нинди җеннәр

тагын? Материя — беренчел, аң — икенчел. Димәк, Алла да юк, Иблис тә юк.

Иннокентий, диварга эленгән мылтыкны алып, затворны тартып куйды.

— Кем, минме юк? Хәзер күрсәтәм мин сиңа үземнең барлыгымны! Уздырдым дисең инде мине, ә? Тот капчыгыңны, конкурентларны тиз юк итәм мин.

Юлбашчы, һичбер нәрсә аңламыйча, кепкасын салды, кулъяулыгы белән тирләгән баш түбәсен сөртте. Маңгаенда, мин сиңа әйтим, мөгез тырпаеп тора! Моны күреп, каушап калган гыйфритләр әле аңа, әле Иннокентийга карадылар. Кыен хәлдә калган тәмуг сарыгы, мөгезе юклыгын күрсәтмәскә тырышып, кулы белән маңгаен каплады. Ләкин бу аны коткармады, карт гыйфрит, коты алынып, Юлбашчының аягына егылды.

— Кичерегез, галиҗәнап! Кепкадан булгач, танымадым, валлаһи, танымадым!

— Зыян юк, иптәш, — диде пролетариат башлыгы, вәкарь белән. — Бу контраны бәйләп хәзер үк ЧКга озатыгыз!

Гыйфритләр шундук Иблиснең өстенә ташландылар. Тәмуг хуҗасы каршылык күрсәтә: акыра, тибенә. Әмма көчләр тигез түгел, барыбер бәйләп салдылар.

— Сез нәрсә, хуҗагызны танымый башладыгызмы? — дип чыелдавын белде Иннокентий.

Карт гыйфрит, аның кыланышын колагына да элмичә, Җәмил тарафына ымлады.

— Ә бу бәндәне нишләтергә?

Юлбашчы, авызына чүпрәк тутырылган Җәмилне бер кат күздән кичереп, елмаеп куйды.

— Авызын томалап дөрес эшләгәнсез. Мин васыять итеп калдырганча булган. Нигә монда шулай бик караңгы? Мин бит сезгә якты киләчәк вәгъдә иткән идем.

— Караңгыда эш итүе җиңелрәк, — дип куштанланды карт гыйфрит.

— Караңгы аңнар белән эш итү исә тагын да уңайлырак, иптәш. Миңа кичекмәстән телефон бирегез!

Карт гыйфрит аңа шундук телефон тоттырды.

— Рәхим итегез, галиҗәнап!

Юлбашчы, телефон тоткычын әйләндереп, трубканы колагына куйды:

— Алло!

Тавыш:

— Президент тыңлый!

— Кем дисез?

Тавыш инде ачулы:

— Пре-зи-дент!

— Ул нинди президент тагын?

— Бәйсез Россия президенты.
— Тфү, каһәр, тагын переворот! Әйткән идем мин Дзержинскийга, эсерларның берсен дә исән калдырма, дип... Нәрсә, Россияне берәресе басып алган иде мәллә? Кемнән бәйсез соң ул? Акларданмы, большевиклардანмы?
— Үз-үзеннән.
— Аңламыйм, берни дә аңламыйм.
— Ичкерия белән эшне бетерик инде, аннары аңлатырбыз.
— Шаяртмагыз, иптәш. Әгәр сез контрреволюционер икән, турыдан-туры әйтеп сөйләшегез.
— Әлегә, әфәндем, без үзебез дә аңламыйбыз кем икәнебезне. Тәмам буталып беттек. Әллә демократиягә таба барабыз, әллә фашизмга — белгән юк.
— Миңа кичекмәстән Дзержинскийны бирегез!
— Дзержинскийны чүплектән алып, яңадан Любян мәйданына бастырып куячаклар, аны шуннан эзләп табарсыз.
— Ул үзендә булмагач, тизрәк Сталинны бирегез! Кемдер миңа мавзолейда йоклап ятканда шәп кенә мөгез куйган, гаеплене табарга кирәк.
Тавыш кеткелдәп көлеп куйды:
— Мин куйдым аны.
— Син? — Юлбашчы зәңгәрләнеп китте. — Аһ син, сәяси фахишә!
— Нигә шулай борчыласыз? Модада бит ул бездә мөгез кую. Сталин үлде — куйдылар! Хрущев китте — куйдылар! Брежнев үлде — куйдылар! Черненкога да, Горбачка да куйдылар! Үлгәч, миңа да, минем варисыма да куярга онытмаслар.
— Ә халык нәрсә карады?!
— Аңа да мөгез куйдык. Берне генә түгел, икене хәтта.
— Һәм ул берниндидә каршылык күрсәтмәдеме?
— Күрсәтмәде, әлбәттә. Беренчесен коммунизмга барабыз дип, икенчесен демократиягә барабыз дип куйдык. Мөгез куйган саен сөенә генә безнең халык.
Чыдар әмәле калмаган Ленин трубканы идәнгә томырды.
— У-у, контра! — Аннары ул Җәмилнең авызындагы чүпрәкне суырып алды. — Рәхәтләнеп сөйләш, мылтыклы кеше, революцион ситуация тудырыр өчен, безгә бик күп сөйләргә кирәк булачак. Аннары, вакыты җиткәч, без аны үзебез томаларбыз.
Карт гыйфрит, дөрес аңладым микән дип, сак кына сорап куйды:
— Җибәрергә кушасызмы, галиҗәнап?
— Кул-аягын чишегез дә хатыны кулына тапшырыгыз. Диктатура алдыннан демократияле уйнап алырга кирәк, — диде дә Юлбашчы зур-зур адымнар белән чыгып китте.
Ишекнең шап итеп ябылуы булды, тагын әтәч кычкырды:

— Кик-ри-кү-үк!

Җәмил карт күз ачып йомарга да өлгермәде, Иннокентийдан һәм җеннәрдән җилләр исте. Әйтерсең алар бөтенләй булмаган. Кем белә, бәлки, болар барысы да саташу галәмәтедер?

Юлбашчы, бүген башка юлдан китәбез, дигән иде, ләкин Җәмил карт бу юлы да фермага, сукрана-сукрана, шул ук кар баскан бормалы тар сукмак буйлап китеп барды.



# МӘХМҮДИЛӘР

*Дүртьюллыкка сыйдырылган яисә билгеле бер рифма-ритмга гына буйсындырылган шигырь минем өчен читлектәге кош кебек. Фикер шул читлектән очып чыга алмый, аның чын ирке, чын рухы кысыла. Шуңа да мин шигырьләремне кәгазьнең буеннан-буена язам, фикерләрем рифма-ритмга түгел, киресенчә, рифма-ритмнар минем фикергә буйсына.*

### Соңгы сүз

Туктап алды беркөн йөрәк. Соңгы сүзем булыр ниндирәк? Юк, бусы артык гади, бусы томанлырак. Шул, шул, соңгы сүзне әйтүе һәрчакны катлаулырак.

Их син, йөрәк, ашыгасың бигрәк! Килгән юлым томанлы, кыйблам кая югалды? Узганнарым бик ерак, китәр юлым моңсурак: яшәүдән соң яшәүгә ышану кыенрак. Соңгы сүзне әйтүе һәрчакны катлаулырак.

Соңгы сүзем булыр нинди?.. Тормышым томанлырак... Әй йөрәк, син тукта инде, синең сүзең саллырак.

### Дөнья

Аһ, нигә караңгы, нигә пычрак соң бу дөнья? Шулай булгач, нигә җирдә чишмәләр ага, нигә кояш чыга? Шулай булгач, нигә кирәк былбыл җыры?! Шулай булгач, нигә кирәк бишек моңы?! Барыбер караңгылык баса барысын да, барыбер пычрак суда бата барысы да.

Аһ, нигә караңгы, нигә пычрак соң бу дөнья? Нигә диңгез шаулый, кая чакыра? Күлләвектә тама сабый яше, күлләвектә яшен батыра.

* * *

Уйландыра шул дөнья... Уйлап та, уйламыйча да яшәргә була монда. Яратып та, яратмыйча да яшәргә була. Уйланылмаган дөнья... Үз күчәрендә әйләнеп, уйланып тик утыра.

* * *

Сүнмәскә иде болай бик тиз, бетмәскә иде. Курай бирегез миңа, наз, аракы... Шәмдәл яна моңсу гына, сүнәм инде, диде. Язылмаган фикер кала тау чаклы.

Язылганын аның аңламагач, язылмаганын кем аңлар?

* * *

Сагыш булып ята диңгез, аңа сезнең белән күңелсез. Бу диңгезнең күңел яраларын, кипкәч кенә, ахры, күрерсез.

* * *

Сүкмә инде, гел шәрабтә һәм гөлләрдә булды минем күңелем. Гөнаһсыз яшь алмыйм һәм сагыштан охшап калам елак балага. Хәмер эчеп, шигырь язмый үлеп китсәм, рәнҗемәссең, бәгърем. Мин гөнаһлы — адәм булгач. Шуңа да Алла булып килмәдем дөньяга.

## Март

Төнлә тышта буран язды шигырь. Дулап капка ачты, япты, елады. Тәрәз төпләрендә ап-ак карлар түгел, намус үзе, ахры, дулады. Мич башында тыңлап ятты аны авыл. Тик аңлаучы гына булмады.

...Басуларда ап-ак буран түгел, намус үзе бик нык дулады. Ә көндезен, тәмам хәлдән таеп, гөрләвекләр булып елады.

## Каләмдәшкә

Акча бирмиләр, имеш. И энем, син бит юләр! Сөенеп яшә, әле ярый һаваны банкларда бирмиләр. Әле ярый кояшны Мәскәүдән китермиләр. Әле ярый Казан суын банкта эчермиләр. Әле ярый аякка да салым салмый хакимнәр. Әле ярый хатыннарны банкларда бирмиләр.

## Күләгәләр

Өйгә кайтып барыш. Алда — кеп-кечкенә күләгә. Минем кебек портфель тоткан, плащ итәге селкенә. Мин туктасам, ул да туктый, мин кузгалсам, терелә.

Инде менә кайтып җиттем, юкка чыкты күләгә. Тәрәзәгә күз салам, күренәме күләгә? И Ходаем, һәр тарафта күләгәләр селкенә! Берсенең бер йөзе юк, таный алмыйм берсен дә!

### Яшь каләм иясенә

Син өлгермәгән әле, син әле яшел алма. Сукмә агачыңны, үпкәләмә дөньяга. Өлгереп, агачыңнан җиргә өзелеп төшәрсең. Бәлки, аннан ераккарак тәгәрәп тә китәрсең.

### Мәгънә

Туунын мәгънәсе нәрсәдә? Үлемнең мәгънәсе нәрсәдә? Җир нигә әйләнә? Ник моңсу бу җирдә, әйт сәнә?! Яшәүнең мәгънәсе нәрсәдә?! Китүнең мәгънәсе нәрсәдә? Сәбәпләре бар мәллә, сәбәпләре юк мәллә? Сәер бит барысы да, сәер бит мәгънәсе дә.

### Син киткәч

*Ркыя Әгъләмовага*

Яшем кипте, хәмер генә калды ләхетеңне чылатырлык. Җирдә юктыр башка хәсрәт андый, мине кабат кузгатырлык. Кояшсыз көн булып йөрим. Кояшсыз төн мәллә? Белмим, белмим... Җимешсез көз кебек үз-үземне сөймим, язлар кебек көлмим. Сайрар талы шартлап сынган ятим бер кошмы мин? Сакла, Ходам! Җиһанда юк башка кыйблам. Сынган талда һаман дога кылам.

* * *

### Анда

*Ичкериядәге вакыйгаларга карата*

Анда... сугыш бара. Диктор радиодан кычкыра: фәлән кадәр дошман үтерелде, фәлән кадәр танк яна. Мактана, әйтерсең лә тавык боты тәкъдим итә миңа.

### Мәдхия

Их, бергенәләрем сез минем, әтием, әнием, Зөһрәм, нәнием, шигырем! Сездән башка тар булыр иде күңелем, сездән башка буш булыр иде гомерем.

Бергенәләрем сез минем, Илем, Иделем! Сездән башка ятим булыр иде шигырем!

Әле ярый бар син, Тәңрем! Әле ярый бар Илем, Иделем! Әле ярый бар әти-әнием! Әле ярый бар Зөһрәм, нәнием! Әле ярый бар янда шигырем!

## Сүтелә тарих

Кабан артында мөәзин кычкыра азанын. Сүтелә йортлар, сүтелә тарих... Алгы тешен коялар Казанның.

## Гайбәтчегә

Пләмәнле үгез, диләр мине. Болай начар түгел үзе, ләкин шигем бар. Мин пләмәнле үгез булгач, димәк, сезнең арада меңнән артык сыер бар.

## Синең өчен — шигырь

*К.М.га*

Кызыкма син алтын-көмешләргә, кызыкма син ул бай бәндәләргә. Җир астында ята күп хәзинә, адәм гомере була тик бер генә. Бездән соң да булыр якут ташлар, бездән соң туар явыз затлар: алтын өчен кеше үтерерләр, намус утын шулай сүндерерләр. Кызыкма син алтын-көмешләргә, кызыкма син ул бай бәндәләргә. Аяк асты тулы гел хәзинә, аңа хуҗа Шайтан үзе генә. Бездән соң да алтын чыгарырлар һәм комсызлар юкка куанырлар: бу шигырем кыйммәт көмешләрдән, көлеп яшим мәнсез бәндәләрдән.

Сөям сине, җаным, чын күңелдән! Син баш тарта күрмә шигырьдән! Бу газәлем синең өчен генә, ул да синең кебек берәү генә. Сәгать сугар, сулыр әле йөзләр, күккә багар безнең моңсу күзләр. Хисләр мәңге, мәңгелек шигырь! Балчык йотмас аны, үлмәс мондый фигыль! Гөлләр үстер, бу да матур шөгыль. Һәм беркөнне ерак оныкларың әйтер: «Бу — саф алтын, бу — чын шигырь!»

## Иман эзли оя

Тышта бүген яңгыр коя, тамчылары тишә оя. Качырырга күз яшьләрен тели микән әллә дөнья?! Һәр тамчыда — сагыш көе! Һәр тамчыда – гел үпкәләү! Адәм шуны аңлар микән, кирәкми Күкне җәберләү! Адәм һаман Шайтан белән, Адәм аның ялчысы. Күкләр дә бит рәнҗи белә, шартлый утлы камчысы. Һәрбер адәм моны белә, һәрбер адәм моны күрә. Тик нигә ул Шайтан белән җырлый икән бер көйгә?!

Тышта бүген яңгыр коя, Адәм һаман оя кора. Затлы ташны ташка салып, яши һаман явызланып. «Әлһәм» белән эшең башла, Күкләргә бер караш ташла. Күрәсеңме, Ходай безгә үзе кулын биргән, Ходай үзе карый безгә өмет белән. Һәр тамчыда — бөек Ата! Һәр тамчыда Иман ята. Тик нигәдер тамчыларга Шайтан аяк белән баса.

Тышта бүген яңгыр коя, тамчылары тишә оя. Шайтан бүген пычак кайрый, Иман эзли бүген оя!

## Тузан

Олы юлның тузаны ла... Мин китмәм андый юлдан. Сагындыра гел авылым, сагындыра шул тузан. Авыл капкасына чыкма, мин китәм тимер юлдан. Керфегеңә яшь кунмас ла, кунмас аңа ул тузан. Мин китәм, ә син каласың, буласы инде булган: кайтасы күперләремне соңгы сүзләр яндырган.

Олы юлның тузаны ла... Тимердән чыкмый тузан. Үксеп елый кош баласы, оясы инде тузган.

## Сөю

Таңга кадәр бер җыр сузды сандугач. Аннан тынды, бераз елады. Юк, чыкмады, бәгырь, тәрәз дә ачмады, гөлләр генә аны тыңлады. Монда җыр көчсез, хисләр дә артык бер нәрсә. Икеләнә һаман ярсу күңел: «Китәргәме? Әйе, китәргә!»

Китте... Ул юк монда хәзер. Сайрамый кошкай бу якта. Ятлар гына җырын суза сандугачкай кунган ботакта.

## Мин Җирнеке түгел

Төне буе Ай кызы инештә су коенды. Аның белән ул суда йолдызлар да юынды. Аһ, нидер булды дөньяга, җиһанга нидер булды! Шушы җиләс җылы төндә МӘХӘББӘТ үзе туды. Чәчләреңне тараганда, күзләремә яшь тулды. Алардан якты йолдызлар, саф мәрҗәннәр коелды. Әгәр Җир кызы булсаң, мин сине үбәр идем. Таңга кадәр су буенда газәлләр сөйләр идем. Тик син озакка килмәдең, син бит Җир кызы түгел. Сине сөеп инде мин дә хәзер җирнеке түгел.

* * *

Саргайган яфраклар коела, җил йөри аларны таратып. Вальс әйләнә дөнья, миләшләр чайкала, ирен кызартып.

Саргайган яфраклар коела — китәләр дөньяны яратып. Ялвару һәм сыкрау юк монда, җил йөри аларны юатып.

Саргайган яфраклар коела, сагыштан йөрәкләр ялыкты. Кем елый, кем итә тантана, ә кемгә тик гөмбә вакыты.

* * *

Без аерылган юллар сабышында үсеп калды көфү каеннар. Нигә икән безнең язмышларны аердылар икән бу юллар? Нигә икән ике юл чатында каеннарны бергә кочмадык? Күгәрчендәй, галәм сулышында, канат җәеп, парлап очмадык? Көзләр җиткәч, яфрак

очышында мин күрәмен кебек үземне. Яфраккайның җирне кочышында ялгыз үткән гомер түгелме?

Язган безгә, язган очрашырга: туфрак булып кабат кавышырга!

## Тәүбә

И бала, елама, ник елыйсың? Нәрсә, кем сине шомландыра? Аһ, бала, син дөрес сөйлисең, бу дөнья тиз туйдыра.

Кемнән курыктың, нарасый? Җиргә үкенеп тума. Күр, балалар кар ашый, анда Кар кызы туа.

Дөнья матур, дөнья киң ул, гел кара төстә түгел. Син — КЕШЕ һәм гел КЕШЕ бул, гел йолдызларга үрел.

Ә без инде соңарганбыз, бик чиста түгел күңел. Без инде нык тапланганбыз, без инде КЕШЕ түгел!

## Матур кызга

Алдана күрмә, читтә торсын синнән вәсвәсәләр. Матур син дип әгәр бәйләнсәләр, кач тизрәк бер тарафка, ышанма һәр ташбашка. Өзелгән чәчәкләрне утыртмыйлар кире туфракка. Өзелгән чәчәкләрне саталар бездә һәр чатта.

## Казымагыз чокыр

Гомере кыска, дип көлмәгез гөрләвектән. Күпме генә чокыр казысаң да, ул барыбер агар, ул үз юлын табар. Язгы җилләр аны яклар, язгы карлар аны саклар. Юлы тар булса да, аның үз көе, үз җыры бар. Нигә бездә җыры булганнарга тирән итеп чокыр казыйлар? Казымагыз җырга чокыр, мин үтенәм сездән, абзыйлар!

## Эзләмә мине

Кыска булыр, ахры, синең гомер, дигән идең. Әйе, беләм, мин бит инде күптән җирдә түгел. Моңсу миңа. Мең газаплар белән дөнья чигеп, ничек якты булсын инде күңел! Тыңла: ул киткән, дигән хәбәр булса, елама, түкмә күз яшең. Бөдрә таллар сагыш булып исәр, син аларны гына сөярсең. Миңа кадәр чыккан-баткан кояш миннән соң да шулай балкыса, сөен, димәк, син бәхетсез түгел. Димәк, тилермәгән әле дөнья.

Исемемне эзләмә җирдән, Күктән, мәрмәр таштан... Кирәк түгел моңсу иза! Адәм гомере — гөрләвек гомере, ул охшаган кыска юлга. Исемнәре Күктә теркәлсә дә, җирдә языла тик комга.

## Казан әле йокламаган

Казан әле уянмаган, уянмаган әле тал-тирәк. Шигырь язып төне буе, төпчек тартып йөрим мин тинтәк. Шигырь туа... Казан әле йокламаган, сөенергә әле иртәрәк.

## Күкләр генә белә

Чын сөюләр була бераү генә, икейөзле була сүзләр генә. Чын сөюләр җиргә каян килә? Күкләр генә белә моны, Күкләр генә белә.

## Утка салмагыз

Бүләк иттем сиңа шигыремне, матур теләк хәтта теләдем. Ә син укымадың бугай аны, шуңа сыкрый бүген йөрәгем. Әй дусларым, укымыйсыз безне! Туган телем, милләт, нишләдең? Ник газәлле халык булган килеш, хәреф танымый күзләрең? Укыгыз сез безнең шигырьләрне, яшьләр юсын ятим күзләрем. Шушы булыр безгә бер юаныч, шушы булыр Тукай бүләге!

## Яңа сүз

Яңгыр ява тыштa. Күк гөмбәзен тырный кемдер. Нинди үпкәсе бар аның? Дулый, шаша ни өчендер. «Әпипә»гә бии тамчылар, бии халык, бии шагыйрь: «Бас, кызым, Әпипә, бие гел син безнеңчә!» Кемнәр, милләт, сине биетә? Кемнәр камыт сиңа киертә?.. Һәр тарафта — киртә. Әллә язмыш, әллә күрмеш йөртә...

* * *

Сине эзләп Җиргә төшкән идем. Әгәр бу син булсаң, күрер идең, сизәр идең карашымны. Бу син түгел, башка бер гөл булган янда. Мин аңладым хәзер генә, мин ялгызым Җир шарында. Хәтта этнең дә бар анда пары. Ә мин ятим, җаным, йөзем дә гел сары. Сине күрер өчен килдем Җиргә бары. Һәм күрмичә китәм... Син кайда-а?!

* * *

Мин дә эчтем, дуслар. Булды инде тукыш-орышлар. Дурак дигән исем алып, узып китте күпме вакытлар. Ничек яхшы булыйм, баштан сыйпаучы булмагач! Ничек тыныч булыйм, хәмер суы дару булмагач! Шулай да мин яхшы булганмын бит, зәмзәм суын эчеп аңгырайгач. Хәзер менә күрәм барысын да, йөз граммнарны түгә башлагач. Сезләр моны ничек кабул итәр? Мин айныдым инде, сезне кем айнытыр, аек исерекләр?!

* * *

Нигә эчәсең, дип сорадың. Имеш, дөнья матур, дөнья рәхәт. Кайда соң ул рәхәтлек, күрсәт! Йә син ахмак, йә мин тинтәк. Әле ярый хәмер бар эчәргә... Аннан башка хәят моңсу һәм кабахәт.

## Юксыну

Нигә киттең җирдән? Сагындым Сине! Рәсемеңне дә югалттым кичә. Чү! Әнә ап-ак бер болыт йөзеп килә. Анда — синең чалымнарың. Менә бусы синең чәчләр, бусы — күзләрең, бусы... Елмаеп карап торасың югарыдан. Озакка дип килмәдең шул җиргә. Тагын таралasың, тагын юкка чыгасың.

## Үкенү

*Рәшидәгә*

Тирә-ягым чиста һәм бай пакьлыкка. Үзем генә кара нокта мин шушы аклыкта. Нишлим соң, агара алмадым барлыкта. Шуңа да бик омтылам юклыкка. Юклыкта була алмый кара нокта. Булса да, казанда кайнатырлар, чистартырлар, һич юкта.

## *Сүгенү*

Көз инде минем Казанымда... Күпме машина, күпме кыз — берсе дә минеке түгел. Аяк асты тулы күпме пычрак — барысы да минеке!

## Ходайга бер сүз

Барыбыз да туабыз анадан. Бер юл белән киләбез дөньяга, китәбез төрле юллардан. Еллар уза... Сөенеп китә берәү юклыгына, икенчесе курка аңардан. Курыкмагыз югалудан. Барлыгыгыздан куркыгыз, андагы наданнардан. Сакла, Ходай, сакла барлыкка кайтулардан. Юклыгыма тизрәк чакыр, тизрәк коткар барлыгымнан.

## Мәхәббәт төнендә

Ташны тишеп гөл үстерә тамчы. Тып та тып, тып та тып. Без — бүлмәдә. Шык та шык, шык та шык! Таш та тишмим, гөл дә үстермим. Тамчыларым ташка түгел, гөлгә тама: тып та тып, тып та тып!

## Җилгә мәдхия

Алмагачыннан өзелеп төште алма. Кем өзде?! Җил малае инде. Бакчадан бакчага йөри. Өзә дә өзә, өзә дә өзә... Тик һаман

канәгать түгел. Алманың иң матуры кайда? Аһ, җил баласы, матурлык кирәк түгел аңа. Аңа өзелгән алмалар саны кирәк. Берәү, икәү, өчәү... Никадәр күбрәк, шуның кадәр яхшырак. Ә нигә өзмәскә? Ул өзмәсә, башкалар күрәчәк, башкалар өзәчәк. Буй җитмәслекләре дә бар алмаларның. Андыйлар үз тиңнәрен көтә-көтә алмагачында кортлый. Корт тимәгәннәре көзенә кадәр агачында кала.

## Азгынлыкмы?

Бозык син, диден. Алайса, нигә бал кортлары иртән гөл таҗына куна? Мин бит синең яфрактагы иртәнге чыкны үптем.

## Үзгәрми

Ата, ана, иши... Киресен укырга теләсәң дә, шул ук изге мәгънә. Чын нәрсәнең асылы үзгәрми шул бер дә, үзгәрми икән хәтта сүз дә.

## Сау бул

Син хат көттең миннән, ә мин хат язмадым: моңа артык бер эш итеп карадым. Бүген таңда йолдызларны эзләп йөрдем, хисләремне җанда барладым. Күк йөзенә кара болыт иңде, никтер Ай кызын анда күрмәдем. Ул да күңелем кебек ятим иде, кичер, анда сиңа урын бирмәдем. Әйе, авыр миңа әйтү бу турыда, мин бер Мәҗнүн булып йөргәнмен.

Синнән башка узып китте күпме язлар, синнән башка узды җәйләрем. Күңелемдә ява салкын карлар, синнән башка узсын көзләрем.

## Алар — безнең көннәр

*К.М.га*

Акрын уза, дисең, көзге елак төннәр. Шулай була күрсен, шулай диик безләр. Озак уза күрсен кышлар, язлар, көзләр. Алар — безнең гомер, алар — безнең көннәр. Санамыйлар бугай көнне тик юләрләр. Бүген һәр минутын саный кайберәүләр. Безгә бит артыгын Аннан җибәрмиләр, кайтасыңмы син, дип сорап йөдәмиләр.

Ярлар да бар яшәү дигән киң дәрьяда — мизгел дә кадерле безгә бу дөньяда. Алла юлы серле, күренми җиһанда. Кыла күр гел дога, юлга соң чыкканда. Намазлыкка утыр, йоклыйм дип ятканда, «Әлһәм»еңне укы, юрганың тартканда. Тик бер генә тапкыр туабыз дөньяга. Һәм адашкач беркөн, кайтабыз Аллага.

Акрын уза, дисең, көзге елак төннәр. Шулай була күрсен, алар синең көннәр. Бүген һәр минутын саный кайберәүләр. Безгә бит артыгын Аннан җибәрмиләр.

## Пычак телле хатынга

Уйла, дустым, авыр сүз әйткәнче. Кирәк түгел мондый явызлык. Тешли торган эткә киерткәнче, сиңа кирәк икән авызлык.

## Синсез моңсу миңа

*Рәшидәгә*

Чәчәкләрсез болын җансыз була, сандугачсыз моңсу урманнар. Синсез миңа бөтен дөнья кара, кара нокта — Кояш, йолдызлар.
Синсез миңа бик күңелсез җирдә, синсез яшәү җирдә бик сәер. Су сипмиләр кипкән гөлгә, кирәк түгел аңа бу хәер.
Су сипмиләр кипкән чүлгә:
Гөлсез дөнья кирәк кемгә?

* * *

Сафлык... Бармы икән дөньяда? Юктыр... Еллар узып, кояш та хәтта тотыла.

* * *

Их, иртәнге томан! Йөзәсең дә йөзәсең... Тәрәзәдән сине күргәч, әллә нишләп китәсең. Парга әйләнгән күз яше кебек, бәгырьләрне өтәсең. Дөнья шундый, тәрәзәдән карап, кайтмаганнарны көтәсең.

## Сабыр төбе — сары сагыш

Пәйгамбәрләр сабыр иткән, сабыр итеп әҗер алган — Ходай моны үзе язган.
Татар, мескен, сабыр иткән, сабыр итеп илсез калган — Ходай моны күрми калган.
Татар, мескен, сабыр иткән, сабыр итеп телсез калган — Ходай моны сизми калган.
Пәйгамбәрләр сабыр иткән, сабыр итеп әҗер алган — Ходай моны үзе язган.

* * *

*Мәк чәчәген өздем ялгыш кына,*
*Чүп үләне белән бутадым.*
*Җыр*

Чүп үләне булмый дөньяда, рәнҗемәсен миңа гөлләр. Гөлләр генә үссә бакчада, гөл ашарлар иде кәҗәләр. Чүп үләне булмый

дөньяда, гаеп итмәсен шагыйрьләр. Бу дөньяда була бары чүп бәндәләр, чүпле шәһәрләр. Үпкәләмәсен миңа гөлләр, үпкәләмәсен кешеләр. Нинди бөек рәссамнар да тере үлән ясый белмиләр. Чүп үләне булмый дөньяда!

## Иртәгә очрашырбыз

Кич. Трамвай. Уйлап кайтам: күпме хатын урамда! Котыртасың син, Шайтан! Матурлар күп дөньяда. Әйе, матурлар алар бик күп, мин фәкыйрь берәү генә. Чыдаса чыдар аларга бары тик игәү генә. Инде күптән тузган идем, тимердән булган булсам. Әле ярый Адәм бабам ясалган ла балчыктан. Аһ, нишләр идем мин яңадан җиргә килсәм! Нишләр идем шушы җирдә бер сукыр булып йөрсәм! Матурлыкка битарафлар гел өендә утыра. Матурлыкка гашыйкларга килешми мондый муштра. Яратам мин хатыннарны, яратам чын күңелдән. Их, кызганыч, бер китәсе булыр җиремнән.

Мин бүген ардым бик каты, син көчсез бүген, Шайтан. Бармыйм инде беркая да, хатын янына кайтам. Матурлыкны күрә белә чын ир-егетләр генә. Хатыннарны да саклагыз, алар бит берәү генә. Хәер, ни сөйлим әле мин? Ник нотык укыйм сезгә? Беткән баш беткән, дусларым, кирәк инде төшәргә. Сау бул хатын, исән булсак, очрашырбыз иртәгә.

## Шагыйрь сүзе

Күпме кеше тыңлый мине бүген... Тик барысы да сукыр, барысы да чукрак, барысы да үлгән. Кул чапмагыз, чәчәк өймәгез өскә, мин әле исән.

* * *

Мәхәббәтем бу дөньяга бетеп бара. Өстәлемдә каләм дә юк хәзер, кәгазь дә юк анда. Ә нигә дип сабый күңеледәй пакь нәрсәне газапларга? Күпме генә вәгазь укысаң да, тарих ул үз юлы белән бара. Бездән соң да ышанырлар ул Аллага, бездән соң да табынырлар ул Шайтанга. Караклыктан дәвам алган дөнья гел кызыга зур алмага. Берәү бүлә-бүлә аргач, икенчесе туа дөньяга. Һәрбер чорның үз залиме — охшаганнар бер анага — алма урлаган апага.

* * *

Син бел, мин акылдан язам бүген акрын гына, үз-үземне сөймим һәм үләмен ялгыз гына. Шигыремне салып тормыйм калыбына, ул да гаҗиз күптән минем чыбыркыма. Шигырь дә кош

кебек, дустым, ул да сөйми читлек сурәтен. Чыксын, әйдә, очып зинданыннан һәм иреклә булып сөйләсен. Син ирекле, Шигырь...

* * *

Синең хыянәтең бик табигый. Син дә күпләр кебек буласың самими. Сине дә мин кояш дип атадым, сине дә бит мин әүлия дип санадым. Иман саклау авыр шул дөньяда. Куәт күбрәк, ахры, Шайтанда!.. Аһ, мин шаһит булдым кичә кояшым тотылганга. Кемгә соң хәзер ышанырга? Кемгә соң хәзер табынырга?

* * *

Тән үлсә дә, үлмәстер, синдә, адәм ул мең начар гадәт.
Яшәешнең мең мәгънәсе мәгънәсезлектән, ахры, гыйбарәт.

* * *

Ялган һәрвакыт матур, шуның өчен ул көчле, кодрәтле. Дөреслек ул һәрвакыт шыксыз, шуның өчен көчсез, михнәтле.

* * *

**Бәхет кошы**

Бәхет кошын назлаганым, керде, җаным, бүген төшкә... Нинди татлы бу саташу! Ничек түзим бу бәхеткә?! Уянганда, күзләремнән кайнар яшьләр тәгәрәде, очып китте бәхет кошы, аңламады хәлләремне. Шулай да мин бик сөендем, канатландым көне буе. Әйтерсең лә кулларымда бәхет кошы кауры.

* * *

Көлеп кенә яшәп булмый, елау кирәк. Аңлар өчен адәм хәлен, димәк, кайгы кирәк. Гарип рухлы булмас өчен — бер елмаю, китек йөрәк булмас өчен — саф мәхәббәт. Түбән җанны сөймәс өчен — чиксез нәфрәт, икмәк тәмен белү өчен, нәни ачлык әйбәт. Тормыш ямен күрү өчен — туклык, яшәү ямен белү өчен үлем килә кинәт. Бар да кирәк. Без бит кеше. Дөнья тану аның эше.

* * *

Киселгән каен яныннан узып барам... Ни булды сиңа, КЕШЕ?! Яфрак өзсәк тә, еларга тиеш җаннар бит без. Йә әйтегез, кайсы рәссам тере яфрак ясый алган? Хәтта без бөек дип атаган рәсем дә

табигатьтән генә урланган. Алай да җансыз, алай да үле... Пумала белән генә терелтеп булмый җилне, ясалган кояш та җылыта алмас йөзне. Шуңа сөймим мин бүген сезне, шуңа сөймим мин бүген үземне.

* * *

Аһ, төнге күк йөзе! Нинди гүзәл болып син! Күпме чәчәк, күпме төс! Йөрсәң иде шунда адашып.

* * *

Күктәге кояшка, таудагы һәр ташка, йөрәктәй яфракка, сызык-каш офыкка, гөлләрнең таҗына — барсына, барсына язасым килә бүген серле мәхәббәт сүзен!

Таныйрсыңмы хисләремне, үбәрсеңме кояш булып күзләремне!..

## Ак болыт мин

*Д.Ф.га*

Моңаясың, саргаясың, тынлыкка чумган күлдәй. Сызланасың, юксынасың, тамчы су көткән чүлдәй. Адашып йөргән болыт мин, тик җилгә генә ярыйм. Яратсам да, сагынсам да, тамчы су булып таммыйм.

Назлы кичләрне сагынсаң, кабат йолдызлар сана. Адашып арган болыт мин, йөз яра булдым сиңа. Бушана да ак болыткай, җил белән китә сәфәр. Елама син, рәнҗемә син, бу хисләр берчак бетәр.

Адашып йөргән болыт мин һәм үз-үземне сөймим. Тәрәзләр чиртеп төннәрен, бер гөлне генә сөймим. Чәчәкле болыннарымны мин киткәч кемнәр таптар? Тәрәзләр чиртер назланып, йолдызлар санап алдар.

Ядкәр итеп йөрәгеңә, салдым, җаным, йөз яра. Сагынма син, саргайма син, йолдызлар сиңа кала. Тулган ай калыккан чакта, мине көтеп алданма. Тамчы су булып таммамын, булсаң да син мең яра.

* * *

Яшенле яңгыр бүген йөрәккә ярамады. Кемдер үксеп елый-елый, күк гөмбәзен тырнады.

* * *

Мин еладым... Мескен икән, димә. Күкләр дә бит елый белә, күкләр дә бит бер ишелә...

* * *

Галәм — гәүдә, җир — йөрәк. Йөрәк тибеше туктаса, үле гәүдә ник кирәк? Җирне сакларга кирәк. Кирәк!!!

* * *

Мин сагындым сине, туган йортым. Күгәргән кадак та синдә сагыш уята.

* * *

Бик матур килде мәхәббәт язы. Арага керде тик кабер ташы. Җылымны өреп, җан бирә алмам. Юк инде өмет, көт мине, алмам.

* * *

Атылдың да сүндең син дә, йолдыз. Нинди озын гомер, нинди мескен очыш!

* * *

Дөньяда начар бәндәләр бар, дип зарланма, офтанма, моңланма. Галәмдә бихисап йолдызлар бар, тик караңгы анда да.

* * *

Яшьлек, чыннан да, юләрлек ул, ялгышларны төзәтми. Ай-йолдызлардан башка, аңа берни дә кирәкми.

* * *

Киләчәктә бәхетсез итәр өчен, Шайтан мине кечкенә бәхетләр белән алдаган. Сыеныр урыным бармы минем алда? Каберемнән мәхрүм итмә, Ходам!

**Каләмдәшләргә**

Инде сәгать бишне сукты, вакыт җитте торырга. Бу күңелдә шундый якты, шөкер кылып ятам Ходайга. Әле ярый бүген эшкә барам, дусларымны күрәм яңадан. Әле ярый бүген сугыш чыкмый, чәчәк исе бөрки бакчадан. Әле ярый бүген эшкә барам, танышларны сагынып уянам. Бүген мине тагын сүгеп китәр кичә кереп чыккан графоман. Аннан тагын килер, тагын сүгәр, мин

шәп язам, дияр Тукайдан. Нишлисең бит, дөнья шундый хәзер, күкрәк кагып яши һәр надан. Нихәл итмәк кирәк, бүген татар шундый, белмәгәнен яза күбесе. Бездә хәзер шагыйрь булды бугай һәр колхозчы, колхоз рәисе. Бездә роман яза һәркем, каләменең булмый тик ние. Композитор, җырчы булды һәркем, аңлашылмый гына тик көе.

* * *

Гомер үткән саен, кырык бердә яуда калган егерме биш яшьлек бабам искә төшә.

**Йолдыз атылгач**

Кемдер төпчек ыргытты башыма. Шул кирәк сиңа, йөрмәссең. Үз-үзеңне мактап, башкаларны гел сүкмәссең. Килеп җиткәч, бернак ахырыңа, син дә: «Ходай», — дип сөйләрсең. Өлгерергә кирәк җылы сүз әйтергә. Юкса белмәссең, әйтәсене әйтми үлеп китәрсең.

* * *

Үлем мәңгелек белән, яшәеш көрәш белән бөек. Тик исеңдә тот: үлемнең дә, көрәшнең дә төрлесе була.

* * *

Күзләре болытлы... Түгәрәк тамчылар, югандай сагышны, гөлләргә тамдылар. Хат килде кич кенә, аязды күзләре. Нур уйный күзендә... И якты үзләре!

**Сабый йокысы**

Бу галәмгә әллә чәчәкләр сибелгән? Буялып зәңгәргә, йолдызлар үрелгән. Йолдызлар болыны югалыр таң аткач. Каршылап кояшны, уяныр бәләкәч. Чәчәкләр өзде ул төшендә болыннан. Тәкыя үрде ул ай-йолдыз нурыннан.

* * *

Бик адашып йөргән чаклар була. Кайчак калам кара урманда. Һәр тарафта — кап-кара төн! Кычкырасым килә илереп, күңел тула, телим бүген качып еларга. Ышан, дустым, шундый теләк була, сабый кебек килә елыйсым. Дөнья булгач, бар да була, сөйләп кенә булмый барысын.

* * *

*Р.Ф.га*

Җир астыннан алтын эзләп арган адәм чеп-чи ахмак, юләрдер ул. Балчык казып, эзләмимм мин җирдә байлык һәм матурлык. Син затлырак, синең күзләр төнлә дә нур сибә, аһ, ник якты бу нур! Мин оялам, бу сүзләрне әйтү — үзе бер батырлык.

Күз карашың диңгезләрдән тирәнрәк, йолдызлардан мәгънәлерәк. Димәк, барыннан да өстенрәк. Димәк, барыннан да кыйммәтрәк.

* * *

Мәкаль укып яттым бүген. Күпме акыл туплагансың, кешелек! Тик нигә соң һаман ахмак син, нигә җирдә җиңә әшәкелек?

* * *

Әйе, жаным, кайный минем каным. Рухым һаман-һаман ябыга. Бу мин инде, кая акты салым? Бу мин инде — һәм гел фаҗига.

* * *

*Ләбиб Леронга*

Шигырь, әкият язасың, шаржларың да ярый. Ркаилең — Ломоносов, ә Ләисең — Кандалый.

* * *

Кайда яшәү мәгънәсе, дип сыкрама. Ул дөньяда, җаным, бер генә. Кеше килә бүтән килмәс өчен, гомер бирәү, Алла — бер генә.

* * *

Их, дөнья! Без гел көзне мактыйбыз. Имеш, ул — өлгергәнлек төсе. Өлгергән җимеш өзелеп җиргә төшә. Димәк, өлгерү — бозыла башлауның башы. Мин дә күптән җиргә төштем һәм алмадай инде каралдым. Өлгердем, димәк.

* * *

И гөрләвек, сиңа инде тумас борын күпме чокыр казып куелган!

* * *

Узды гомер... Урманда түгел, чүлдә түгел, сөю юлында йөрдем адашып.

* * *

Бер тилене күрдем... Сабан туе белән саташа. Җырлый, көлә, кем beləндер көрәшергә маташа. Беренче батыр мин, ди, синдәйләрне бөкләп салам. Шөллисеңме? Йөрмә янда, билсез калырсың, балам!

Кызганмадым мин тилене, көнчелек туды җанда. Рәхәттер лә бу саташу, гел җиңүче булганда. Һичбер көчеңне түкмичә, Наполеон буласың. Булмаган алтыннарга да куанып утырасың.

Алай дисәң, без дә, дустым, бер дә акыллы түгел. Дан-шөһрәт артыннан куа бу нәфес һәм бу күңел. Гомер уза акча туплап, уза дәрәҗә яулап. Дөнья — үзе саташудыр, саташып арган газап.

И Ходаем, тилерт мине, газаплар очсын җилгә! Мин дә саташып үлимче, бәхетле булып җирдә.

## Шомырт күзем син

*К.М.га*

Күзләреңнән шомырт исе килә, бал кортыдай шуңа үреләм. Салкын көзләр генә кара чәчең сөеп узган инде, бер генәм.

Шомырт чәчәк атып арган чакта, бәхет юрый иде бу күзләр. Ак чәчәктә иде безнең яшьлек, ак чәчәктә иде иртәләр.

Үткәннәргә бер борылып кара, яшьлегеңә сау бул дигәндә. Йөрәгемдә сызлый татлы яра, май төннәре җиргә иңгәндә.

Бакчаларда гөлләр инде сулган, шомыртларны төргән ак томан. Көзге яңгыр елап инде арган, язлар булмас, ахры, яңадан.

Шомыртыбыз тагын чәчәк атар, таң җилләре безне көтәрләр. Йолдызларны башка ярлар санар, чәчкәләрне безнең өзәрләр.

Үткәннәргә бер борылып кара, шомырт күзем, кара карлыган. Йөрәгемдә сызлый татлы яра, яшьлегем — ак томан, ак томан.

## Кукмара вальсы

Кукмарамның матур тавы урман белән төрелгән. Сәлам сиңа, моңнар ягы, җырлар белән чигелгән. Һәр чәчәктә, мең бизәктер, һәр чәчәктә — мең сагыш. Җанга туган як кирәктер, төшкә керә һәр арыш.

Кукмарамны сагындым ла, сагыныш арам инде. Нихәлләр бар, ничек анда? Таулары тарта мине. Бер менәрмен әле тауга, жыяр-

мын шунда чәчәк. Анда минем арган җанга чишмәләр наз бирәчәк.

Кукмарамның тауларына бер менәрмен, елармын. Каеннарның тузларына, сагындым, дип язармын. Бүген хат алдым әнкәйдән, бездә шомырт өлгергән. Аерылмагыз Кукмарадан, анда баллы бөрлегән.

## ФӘЛСӘФӘ ДӘФТӘРЕННӘН

### Интеллект — очраклы продукт түгел

Аллаһының барлыгын тагын бер кат исбат итәм. Махсус белеме булмаган адәм баласы сафтан чыккан телевизорны очраклы рәвештә генә төзәтә алмаган кебек, автомашина белән эш итмәгән кеше машина моторын очраклы рәвештә генә сүтеп кора алмаган кебек, табигать тә акыл-интеллекттан мәхрүм булса, бу кадәр гакыллы адәм баласын очраклы рәвештә генә барлыкка китерә алмаган булыр иде.

### Юклык ул бар, чөнки ул юк

Булган әйберне юк итеп була, юк әйберне юк итеп булмый. Нәрсә соң ул галәмдәге төпсез бушлык (пространство)? Аны тотып та, тоеп та булмый. Җиһандагы җисемнәргә карап, без аның биниһая чиксез булуын гына күзалларга тырышабыз. Бушлык (пространство) һәрчак булган һәм булачак. Чөнки бушлыкны юк итү мөмкин түгел, чөнки ул юк. Шул ук вакытта бу бушлыкны бар дип санарга кирәк. Ник дигәндә, анда миллиардлаган күк җисемнәре эленеп тора. Менә сиңа табышмак: ул бар да, ул юк та.

### Син — бәхетле кеше!

Кичә, мин хәерче, дип исерек күз яшең түктең. Ә син үзеңнең миллионер икәнлегеңне дә белмисең икән әле. Әнә Америкада үлем көтеп яткан бер мультимиллиардер бавыр сатып алырга тели. Хәтерем ялгышмаса, адәм баласының бу әгъзасы бер миллион доллар исәпләнә. Ә моңа бавыр, йөрәк, үпкә, күз, колак ише әгъзаларны да китереп кушсаң? Һи, ярты Американы сатып алырдай акча җыела түгелме? Ә бу байлыкны сатарга кирәкми. Сөенеп яшә: син иң сәламәт кеше. Эчүеңне ташла да хатының янына кайт, балаларыңны кочагыңа алып, алардан гафу үтен. Алар исән-имин булганда, алтын-көмешкә төрелгән йортың, затлы машинаң булмау бәхетсезлекмени? Үзең исән булганда, алар исән булганда, син иң бай һәм иң мөһиме — иң бәхетле кеше!

## Иң үтмәс товар

Бу заманда иң үтмәс товар намус булыр иде, минемчә. Аны иң арзан бәягә сатып кына түгел, көчләп бушлай бирсәң дә алмаслар иде. Чөнки ул күпләргә яшәргә комачау итә.

## Итне ничек әзерләргә?

Шикәр авыруыннан интеккән кеше күп ашый, тиз симерә. Андыйларның организмында җыелган шикәрне фәкать инсулин гына эшкәртеп тора. Ә нигә шикәр авыруын авыл хуҗалыгында кулланмаска? Бозауларда ясалма рәвештә шикәр авыруы булдырсаң, алар тизрәк һәм яхшырак симерер иде. Рәсми медицина шикәр авыруы йогышлы түгел, ди бит.

## Менә бу ичмасам хәстәрлек

Хуҗа Насретдин үзен җирләгәндә кабергә йөзтүбән салып куюларын үтенгән. Янәсе, кыямәт көнне дөньяның асты өскә килгәч, ул йөзе белән өскә карап ятачак. Шәп фикер, ләкин минеке тагын да шәбрәк. Әгәр үлә калсам, мине җиргә башым белән тыгып куегыз. Кыямәт көнне, җирнең асты өскә килгәч, барча әрвахлар да ятып торганда, мин аякта басып торырмын...

## Патша нәрсә әйтергә теләгән?

Заманында Петр Беренче болай дигән: «Прапорщик не офицер, курица не птица, женщина не человек». Бу гыйбарә белән ул хатын-кызны һич кенә дә кимсетергә уйламаган. Ягъни урыс патшасы: «Женщина не человек, женщина — сверхчеловек», — дип әйтергә теләгән.

## Алласызга җавап

Алласыз бәндә, аның юклыгын исбат итәр өчен, гаять хәйләкәр вә мәкерле сорау уйлап тапкан. Ул болайрак яңгырый: «Аллаһы үзе күтәрә алмый торган ташны ясый аламы?» Әйе, Аллаһы үзе күтәрә алмый торган ташны ясый ала дисәң, адәм баласында шундук шик туа. Аллаһы үзе күтәрә алмый торган ташны ясый алса, ул нинди Алла инде, янәсе. Андый ташны ясый алмый, дип җавап бирсәң дә, Аллаһының кодрәтенә шик туа башлый. Бу очракта, мин сезгә, алласызларга болай җавап бирергә киңәш итәр идем: «Әйе, Аллаһы үзе күтәрә алмый торган ташны ясый ала, ләкин теләсә күтәрә, теләмәсә күтәрми».

## Шикәрле фикер

Адәм баласының тәнендә химик матдәләр үзара реакциягә кереп, энергия (җылылык) хасил була. Димәк, химик матдәләр алмашы аның фикерләү сәләтен дә булдырып тора. Бу нәрсә дигән сүз? Лимон ашасаң, башта лимонлы фикер, шикәр ашасаң, шикәрле фикер, борыч ашасаң, борычлы фикер туа лабаса.

## Бик тә гуманлы фикер бу

Сугыш коралларын гуманлы һәм гумансызга аера башладылар. Раббым, химик сугыш кораллары гап-гади бомбадан кайсы ягы белән мәрхәмәтлерәк? Хәнҗәр мәрхәмәтлерәкме, мылтыкмы? Берсе азлап, икенчесе күпләп кыра. Димәк, сугыш максатларында кулланылган очракта, аларның икесе дә кеше үтерә. Шул да булдымы гуманизм? «Гуманлы сугыш коралы» дигән оятсыз термин онытылырга тиеш. Фәкать тыныч тормышка хезмәт итә торган эш коралы гына гуманлы була ала.

## Тиләләргә — Нобель премиясе

Коточкыч үтерү кораллары уйлап тапкан галимгә Нобель бүләге бирелә икән, дөнья белән фәкать акылдан язган кешеләр идарә итә дигән күңелсез фикер туа.

## Яңача сугышырга кирәк

Тарихта әхтәри ярып (карта уйнап), атасының бөтен байлыгын оттырган җилбәзәк уллар булганлыгы билгеле. Ә нигә бу тәҗрибәне дәүләтләр арасында үзара аңлашу рәвеше итеп файдаланмаска? Әйтик, дәүләтләр арасында зур киеренкелек туган һәм мөнәсәбәтләрне сугышсыз ачыклап булмаслыгы аңлашылган очракта, бу хәлдән, алдан килешү төзеп, кәрт уйнап чыгу да мөмкин бит. Мисал өчен, Америка президенты белән Русия президенты әхтәри ярырга утыра. Русияле җиңелә икән, Америка гаскәрләре ун яисә егерме елга (бу килешүдә каралган булырга тиеш) Русияне басып ала, аның байлыкларын ташый. Шартнамә срогы чыккач, американлы белән русияле янә карта уйнарга утыра. Бу юлы урыс җиңеп чыксын ди. Аннары инде Русия гаскәрләре билгеле бер вакытта Американы басып ала. Шулай иткәндә, шәһәрләр дә җимерелмәс иде, үлем-хәтәр, канлы күз яшьләре дә булмас иде. Әгәр карта уены ошамаса, рәхим итеп, шахмат тактасы артына утырыгыз.

## Без шулай яши башларга тиеш

Кеше кайчан пенсиягә чыгарга тиеш? Бездә, алтмышка җитеп, тәмам хәлдән тайгач, үләр вакыт җиткәч кенә ял бирелә. Бу дөрес түгел. Минемчә, адәм баласын, туган көненнән башлап, кырык яшенә кадәр дәүләт карарга тиеш. Бу чорда ул фәкать спорт, ял итү, уку, интеллектны баету, фәнни һәм иҗади хезмәт белән шөгыльләнү, сәяхәт итү, гаилә кору, бала тәрбияләү кебек мәшәкатьләр белән генә мәшгуль булсын иде. Ә кырык яшьтән соң ул, пенсиядән чыгып, яраткан эш урынында эшли башлаячак. Шулай иткән очракта, кеше җәмгыятькә, фәнгә һәм производствога күбрәк файда китерә алыр иде. Чөнки кырык яшьтә кеше инде бөтен яктан да формалашып беткән була.

## Кәҗә хайван түгел, ә кабырга нәрсә?

Борынгы Римда, ерак походка чыкканда, һәрбер легионда кәҗә көтүе булган. Легионерлар бичара кәҗәне ит-сөт, мамык чыганагы буларак кына түгел, хатын-кыз итеп тә файдаланганнар. Ләкин бу гайре табигый хәл адәм баласының башка гөнаһлары арасында тоныкланып кына кала. Мисал өчен, Аллаһы Һаваны, чыннан да, Адәм кабыргасыннан ясаган икән, үз кабыргаңа төне буе мәхәббәттә аңлашу, аны үбү, аның белән җенси мөнәсәбәткә керү коточкыч гамәл түгелмени?

## Интеллект акыл билгесеме?

Балык акыллымы, адәм баласымы? Әлбәттә, балык. Ул борчак кадәр мие белән дә һичбер адашмыйча диңгез-океаннар аша төрле материкларны урап, туган сулыкларына исән-имин әйләнеп кайта. Юкса анда аны нинди генә дошманнар сагаламый. Ә без, нинди зур баш миенә ия адәм балалары, шәһәр җирендә дә адашмыйча йөри алмыйбыз.

## Баш авыртканда туган фикер

Казан каласының Бауман урамына чыксаң, әллә кайчан үлгән кешеләрне дә очратырга мөмкин.

## Акыл каян бирелгән

Бу җиһанга үле материя итеп карау үзе бер гакылсызлык. Әгәр инде без аның, чыннан да, үле һәм интеллектсыз (акылсыз) материя булуын танырга телибез икән, бу очракта акылсызлыкның акыллылыкка караганда акыллырак булуы шиксез.

## Ярату формуласы

Мәхәббәт — гап-гади эгоизм ул. Әгәр син хатын-кызның гәүдәсенә, эчке дөньясына, рухына хуҗа булырга омтыласың икән, кибеттән иң матур курчак алып кайтып, башка кызларны көнләштерергә хыялланган сабый өммәтендә каласың.

## Санама

Нигә санарга, нигә кушарга, нигә бүләргә? Табигатьтә барысы да исәптә. Ул — иң бөек хисапчы. Болытлар да тиккә генә арлы-бирле акмый, җил дә тик торганда гына исми, яңгырлар да теләсә ничек кенә җиргә таммый. Һәр нәрсәнең юлы инде билгеләнгән. Без хаос дип күзәткән ком буранында да билгеле бер тәртип бар. Һәр ком бөртегенең оча торган үз траекториясе булдырылган. Бу дөньяны исәп-хисап ясап кына киметеп тә, арттырып та булмый.

## Бар Ул, бар!

Бармы Алла дип сорыйсың. Сәер сорау. Син үзеңне бар дип саныйсыңмы? Әлбәттә, саныйсың. Бу дөньяда инде синең белән мин дә булгач, Ходай кадәр Ходай ничек булмасын?

## Чиксезлек категориясе

Хак Тәгаләдән ерагаюның чиге булса, аңа якынаюның чиге юк.

## Лотерея уены

Адәм баласы лотереягә машина отса, сөенеченнән үләр дәрәҗәгә җитә. Ә дөньяга туу шул ук лотерея уены түгелмени? Бер миллион сперманы (конкурентны) җиңеп чыгу бөек казаныш түгелмени? Бер миллионлы халык яшәгән шәһәрдән нәкъ менә синең бердәнбер лидер булып чыгуың кебек бит бу. Бер миллион кеше арасыннан яшәүгә хокук алган бердәнбер сперма син! Шуны һәрвакыт исеңдә тот.

## Чагыштырмача мәңгелек тәгәрмәч

Ул авыл җирендә һәрбер йортта бар. Мич морҗасы тартамы? Тарта. Бу һичбер энергиясез һава агымын хәрәкәткә китерә торган «мәңгелек тәгәрмәч» түгелмени?

## Кызлар нигә матур киенә?

Матур булып күренер өчен... Ә нигә матур булып күренер өчен? Егетләргә ошар өчен... Нигә ошар өчен?.. Кызыксыннар өчен... Нигә кызыксыннар өчен?.. Шушында туктыйк инде.

## Без табигатьне баетабызмы?

Адәм баласы миллион еллар буена шул ук мәхәббәт, шул ук нәфрәт, шул ук байлык һәм хәерчелек, фаҗигаләр аша узган. Бездән соң да яратырлар, нәфрәтләнерләр, алдашырлар, үтерерләр, таларлар. Димәк, һичбер яңалык юк. Адәм баласы таныш белмәгән яңа хисләр, кичерешләр инде калмаган. Моңсу бит, төрлелек юк. Очраклы хәлме бу?.. Юктыр. Табигать миллиардлаган кешеләрне бер үк хисләр, кичерешләр, хәлләр, күренешләр, вакыйгалар, очраклыклар аша үткәреп, адәм баласы психологиясенең барча нечкәлекләрен, рухи байлыкның иң күренмәс төсмерләрен өйрәнергә тырыша кебек.

## Мин барыбер изге

Сүгәсең мине. Ә аракы эчкән бәндәнең изге кеше булуын беләсеңме син? Бик беләсең килсә, ул әче нәрсәне эчеп, мин дәүләт бюджетына акча кертәм, пенсионерларга, ятимнәргә, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтәм. Миңа шәһәрнең иң тырыш алкоголигы дигән медаль бирергә вакыт. Сәламәтлегем, хәерче хәлем, авыр язмышым белән исәпләшмичә, әҗәтләргә керә-керә, мескеннәрнең тамагы турында кайгырта торган изгеләрнең дә изгесе мин. Шуның өчен кызган мине һәм... ярат.

## Бер ачыш уңаеннан

Физика-математика фәннәре кандидаты Ким Шакиров Ньютон законын шик астына куйды. Моның барысына да үлчәү сатып алу сәбәпче булды. Башта ул бу үлчәүгә улын бастыра. 70 кг, сөбханалла! Аннары ул аны үлчәүгә башы белән бастыра. Бу ни тагын?.. Ничәдер грамм җитми! Ишегалдыннан бүкән алып керәләр. Болай куйсаң, барысы да тәртип, астын өскә куйсаң, бүкән берничә граммга җиңеләя. Шулай итеп, Ньютонның җир тарту көченә ия дигән законы шик астында кала. Хәзер Ким Шакиров үзенең ачышы өчен патент артыннан чаба. Тик миндә бу ачышка карата кечкенә генә бер шик бар. Үлчәүдә түгел микән хикмәт? Әйтик, үлчәүнең үзен дә аслы-өсле үлчәп карарга кирәктер? Әгәр үлчәүнең авырлыгында үзгәреш булса, иң беренче эш итеп, аңа да патент алу мәслихәтле.

## Җавабым шул гына

Тозсыз әсәр язгансың, дидең. Ә нигә моңа гаҗәпләнергә? Мин дә бит синең кебек үк сиксән процент судан торам.

## Үлгән чебенгә мәдхия

Иң зур ихтирамга лаек бөҗәк син. Соңгы сулышыңа кадәр үз табигатеңә хыянәт итмисең. Ачуың чыкса, үлем куркынычы янавын онытып, һичбер икеләнмичә, президентны да, ФСБ башлыгын да тешлисең. Ә кеше һәр очракта да КЕШЕ булып кала алмый. Дөрес, дөньяга без барыбыз да кеше булып туабыз. Әмма үсә төшкәч, табигать кануннарына каршы килеп, берәүләребез үрдәккә, икенчеләребез төлкегә, өченчеләребез юха еланга әверелә. Һәм гел шулай, елдан елга, гасырдан гасырга дәвам итә.

## Сүз — матди категория

Изге китапларда, дөнья яралуны күздә тотып, иң әүвәле Сүз булган, диелә. Хәзер һәркемгә мәгълүм, Коръән — ул өстен көч тарафыннан кешелек дөньясына иңдерелгән иң камил вә иң изге космик документ. Анда галимнәр биология, математика, медицина, география, астрономия һәм фәннең башка өлкәләренә кагылышлы искиткеч кыйммәтле мәгълүмат таптылар. Ләкин бу мәгълүмат изге китапларда табышмак рәвешендә бирелә, аларның күбесен әле чишәргә кирәк булачак.

Иң әүвәле Сүз булган, дидек. Изге китапларга ышансак, Аллаһы яктылыкны караңгылыктан Сүз белән аера алган икән, Сүз — матди категория булып чыга. Ни өчен без, язучылар һәм журналистлар, җөмләне редакциялибез, төзәтәбез, сүзләрнең урыннарын алыштырабыз? Материяне тәртипкә китерү өченме? Мөгаен, шулайдыр. Мисал өчен, төштем мин чишмәгә, димибез бит, мин чишмәгә төштем, дип әйтәбез. Сүзләрне билгеле бер тәртипкә китереп, без аһәңле җөмлә, ягъни материядәге гармонияне (аһәңне) булдырабыз. Ә сүз уйнатканда без, пластилинны изеп-бөгеп төрле сурәтләр ясаган кебек, материя белән төрле тәҗрибәләр ясыйбыз.

## Әйләнә торсын шунда

Аһ, бүген никтер баш әйләнә. Әйләнә бирсен! Бүген дөнья бетә дигәннәр иде. Бетмәс, ахры. Баш әйләнгәч, Җир дә әйләнә, димәк. Шулай гына була күрсен. Амин!

## Наданлык турында

Надан дигән сүзне тегеләй укысаң да, болай укысаң да, барыбер надан дип укыла. Наданны иң абруйлы академиядә укытсаң да, Африкага алып барсаң да, Америкага китереп куйсаң да, һәрвакыт Надан булып калачак.

## Даһилыкка ерак әле

«Мәдәни җомга» гәзитендә Русия тиленләре турында мәкалә дөнья күргән иде. Тиленләр арасында «Ельцин»нар меңнән артып киткән. Арада «Мавроди»лар, Наполеон»нар, «Брежнев»лар һәм «Ленин»нар да шактый. Әмма бу озын исемлектә мин үземне тапмадым. Димәк, даһилыкка ераграк әле.

## Яшик әле

Күп шикәр ашау зыянлы, дидең. Соң, дустым, яшәү үзе дә бик зыянлы нәрсә ул. Зарарлы булса да, яшик әйдә!

## Тагын Алла турында

Бармы ул Алла, дисең. Сәер сорау... Син үзеңне бар дип саныйсыңмы? Әлбәттә, бар дип саныйсың. Минем белән бәхәскә кергәнсең икән, димәк, син — бар. Синең белән бәхәсләшәм икән, мин дә бар. Без икебез дә бар. Алла да безнең белән бәхәстә. Шулай булгач, ул бар! Аны күргәнем дә, аның белән бәхәсләшкәнем дә юк, дисеңме? Ялган бу, чеп-чи ялган! Без, имансызлар, аның белән гел бәхәстә. Син завод-фабрикалар салып, һаваны агулыйсың, ул сиңа йөз төрле чир җибәрә. Син җирнең кара канын — нефтьне суыртасың, ул кайдадыр коточкыч җир тетрәү булдыра. Бу бәхәс түгелмени? Бу Илаһы белән бәхәсләшү түгелмени?

## Гөрләвекләр ни турында сөйләшә?

— Әй, яшьти, син кая агасың?
— Инешкә. Инештән — елгага, елгадан — диңгезгә.
— Ә син?
— Мин — канауга, канаудан — дуңгыз абзарына. Миңа инде тумас борын чокыр казып куелган.

Адәм баласының да язмышы шундый — һәркемнең үз юлы.

## Мәҗлестән соң туган фикер

Бәйрәм бара. Зарланышалар:

— Бетә татар, бетә...

— Ну бу урысны!

— Бәйсезлек өчен күтәр!

— Милләт өчен!

— Яшәсен милләт!

— Без — көчле халык! Без көчлерәк!

...Тынлык. Нәрсә булды? Йа Ходай, «Распутин» — өстәлдә, татарлар — идәндә. Татарны егып салу өчен, урысның үзе булуы кирәк тә түгел икән?

## Кем син, КЕШЕ?

Бүре ач булганда яман, кеше тук булганда куркыныч. Тук аучы! Тук үтерүче! Тук ялган! Яман аучы! Яман ялган!

## Тулай торакта

Син таракан үтереп йөрисең. Тимә аларга, бетләр һәм тараканнар Рәсәйнең бердәнбер байлыгы ул.

## Хәреф гаепле түгел

Һәр телдә оятсыз сүз бар. Аларның кайберләрен без, әдәплерәк яңгырасын өчен, башка хәрефләр тезмәсен кулланып, йомшартыбрак әйтергә тырышабыз. Мисал өчен, күтне арт саны дип атыйбыз икән, ул йомшаграк әйтелә, ә мәгънә барыбер шул ук. Букны — тизәк, сидекне бәвел дию белән дә шул ук хәл. Димәк, авызыннан хәрефләре без теләгән тәртиптә урнашмаган сүзләр ычкындыргалаучы кешеләрне культурасызлыкта гаепләү дөрес түгел.

## Тараканнар хакында

Йомычка өстенә йомычка менә башлаган чорда, ата таракан, ана тараканның мәхәббәтен яулау өчен, иллә дә тәмсез ис чыгара башлый икән. Галимнәр адәм баласының да ис аша яратуын, гашыйк булуын инде күптән ачыкладылар. Моны дәлилләве әллә ни кыен түгел. Мисал өчен, берәүләрне күрүгә үк хөрмәт итә башлыйсың, ә кайбер бәндәләргә шундук нәфрәт хисе уяна. Димәк ки, без үзебез дә сизмәстән, ягъни инстинктив рәвештә, кешенең

исен йә яратабыз, йә яратмыйбыз. Ата тараканның ис чыгаруында туктадык бит әле. Ни гаҗәп, начальство тирәсендә ис таратырга күнеккән бәндәләр дә, гадәттә, баш әйләндергеч карьера ясый.

### Җавап

Нигә уйга калдың, дисең... Тере кеше уйланыр да, моңланыр да инде. Тере булуның бөтен өстенлеге менә шунда.

### Үзебез гаепле

Булдыксыз кешедә яшәеш өчен көрәш инстинкты нык үскән була, дип уйлыйм мин. Андыйлар власть ярата. Төп кораллары — әләк, мәкер, ялагайлык. Никадәр югарырак — шуның кадәр ахмаграк. Хәер, андыйларның бик тә уңышлы рәвештә югарыга үрмәләүләренә без үзебез гаепле. Әйдә, шулай булсын, андыйлар никадәр югарыдарак булса, аяк асты шуның кадәр чистарак булыр.

### Бәхет турында

Һәр тарафта кансызлык, монафикълык, куштанлык, ялагайлык хөкем сөргән бу гөнаһлы җирдә, һаман саен тере вә чын мәетләр өелә барган бу зур чүп өемендә фәкать тиленләр, каргалар, тараканнар һәм чебеннәр генә бәхетле була ала.

# ЭЧТӘЛЕК

Бер урамның ике очы. *Р.Зәйдулла* . . . . . . . . . . 5
Әче балан *(кыйсса)* . . . . . . . . . . 9
Чокыр да такыр *(кыйсса)* . . . . . . . . . . 64

## Хыялый хикәяләр

Йолдызларга — йодрык . . . . . . . . . . 131
Җиңелү . . . . . . . . . . 133
Соңгы роман . . . . . . . . . . 136
Серле кеше . . . . . . . . . . 141
Шомлы гасыр . . . . . . . . . . 147
Яхшыга юрыйк, Мингол . . . . . . . . . . 149
Мунча . . . . . . . . . . 155
Мәхмүдиләр . . . . . . . . . . 179
Фәлсәфә дәфтәреннән . . . . . . . . . . 196

Литературно-художественное издание

Захид Махмуди
(Махмудов Захид Бариевич)

**Горькая калина**

***Повести, рассказы, философские размышления***

(на татарском языке)

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Л.Ш.Шәфыйкова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 20.08.2003. Форматы 84×108 1/32.
Офсет кәгазе. «Times» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 10,92+фор.0,21. Шартлы буяу-оттиск 11,76.
Нәшер-хисап табагы 12,24+фор.0,36. Тиражы 3000 д. Заказ Я-567.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.

**Кадерле укучыбыз!**

Татарстан китап нәшрияты 2003 елда сезгә түбәндәге китапларны тәкъдим итә:

| | |
|---|---|
| *Нәбирә Гыйматдинова* | Парлы ялгыз |
| *Рәдиф Сәгъди* | Канга буялган алтыннар |
| *Кояш Тимбикова* | Уртак яр |
| *Марсель Галиев* | Арслан йокысы |
| *Зәки Зәйнуллин* | Һаваларда ялгыз торна… |
| *Галимҗан Гыйльманов* | Албастылар |
| *Марат Әмирханов* | Тәкъдир |
| *Тәлгат Галиуллин* | Шәхесне гасырлар тудыра |